ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№01 (396)
ГЫЙНВАР 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

«ТУГАН БАТЫР»: КАҺАРМАННАР ЗАМАНЫ ҖИТТЕ

№01 (396)
ГЫЙНВАР 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илдус Заһидуллин, Сөмбел Могыйнова, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Рамил Гали, Айдар Мөшәрәпов, Александра Живушкина
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Туган Батыр» мультфильмы күренеше

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-0017
Басарга кул куелды: 17.01.2025
Чыгу көне: 23.01.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ҖЫЛЫ ГЫЙНВАР МАҖАРАЛАРЫ

Гыйнвар башы яз сыман җылы булды быел. Карлар эри, тамчы тама, я коеп яңгыр ява, язмы әллә дип саташкан песнәкләр сөенеп сайрый башлады хәтта...

Ә тәрәзә төбендә чәчәк атып утырган декабрист гөлләре арасында кинәт... кычыткан үсеп чыкты. Чын мәгәр – ямь-яшел һәм чагарга да әп-әзер. Кыскасы, табигать гамәлләре бер дә гыйнварча түгел әле. Фатирга нинди җилләр китереп ташлагандыр үзен – анысын да белеп булмый. Аңа карауга, шунда ук җәй, кояшлы көннәр һәм әбиләр оныкларына «файдалы» вә «тәмле» дия-дия пешереп ашатырга тырышкан кычыткан ашы искә төшә. Әле тагын әбиләр кычыткан өйне – яманнан, түтәлләрне – уңдырышсызлыктан, ә балаларны күз тиюдән саклый дияргә дә ярата.

Кычытканнан яланкул теккән күлмәкләр хәтта сихерне кайтарып, кыргый аккошларны яңадан әкияти принцка әверелдергән. Моны әле Андерсен ук язып калдырган.

Менә шундый гади генә, әмма гаҗәеп көчкә ия чүп үләне – тәрәзә төбендә. Шунысы гына кызганыч: бу бәләкәй үсенте ни ашка, ни принц өчен күлмәк тегәргә җитмәячәк. Әмма безне бит алда барыбер яз көткәнен беләбез. Димәк, кычыткан чытырманнары әле булачак, кинәнәчәкбез. Иң мөһиме – майга кадәр аның тылсымлы сыйфатларын гына онытып бетермәскә!

Сезнең гыйнвар редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» 104 ЯШЬ ЖУРНАЛЫНА

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

ЯҢА ЕЛ ГҮЗӘЛЛӘРЕ ПАРАДЫ

Яңа ел бәйрәмнәрендә киенергә-бизәнергә ярата торган агачлар арасында иң киң таралганы һәм затлы саналганы – Фразер пихтасы, аны без ак чыршы дибез. Раштуага да Ак йорттагы Зәңгәр бүлмәне нәкъ менә аның белән бизиләр. Быел алты метрлы ак чыршыны бәйрәмгә Төньяк Каролинадан китергәннәр. Татарстанда да бар андый гүзәлләр, һич кенә дә күршегә кереп торасы юк. Егерме яшьлек Фразер ак чыршысы, мәсәлән, Идел-Кама тыюлыгын бизәп утыра. Кеше кулы тимәгән – теп-тере! Гаҗәеп куе, идеаль симметриягә ия ябалдаш, йомшак ылыс, хуш ис... Бу агачка, күрәсең, безнең Раифада да ватаны – Төньяк Америка тауларындагы шикелле уңайлы. Хәер, дендрарийда ул гына түгел, башка пихталар да рәхәтләнеп үсә. Биредә аларның 11 төре бар: япон себер ак чыршысы, Кореядән, Альп тауларыннан китерелгән чыршылар, ак кайрылысы, бальзамик пихта һәм Майер агачы... Берсеннән-берсе күркәм вә гүзәл үзләре!

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Цифрлы трансформация могҗизалары
Ясалма интеллект ничек савым һәм артымны күтәрә

14. Иделдән Свислочь елгасына кадәр
Минск белән Казан ничек «туганлашты»

20. «Здравствуйте! Исәнмесез! Добрый дзень, сябры!»
Кайсы музейда өч телдә сәламлиләр

24. Ферма кайчан шатлык китерә,
яисә Ничек кәҗә үстерергә

32. БРИКС саммитыннан яңа автобанга кадәр
2024 елның 12 мизгеле

игелекле эшләр

44. Гамьле әңгәмә
Замана табибы нинди була

50. Галәмгә очу һәм исән калу
Африка черкиен үлгәннән соң ничек терелтергә

54. Без белмәгән дөнья
Адвокаттан ничек биолокация белгеченә әйләнергә

56. Гаилә кыйммәтләре
Алтын туйга илткән юл

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

мәңгелек кыйммәтләр

60. Тарихи сәхифә
Кем ул Исмәгыйль Рәмиев?

64. Шәехзадә Бабичны искә алып...
«Мендем кояшка ашкынып»

70. Бэтменны алыштыра алырбызмы?
Туган Батырның бөтен мөмкинлекләре дә бар

76. Айдар Фәйзрахмановның тормыш җырлары
Беренче бөтендөнья сугышындагы татар әсирләре нинди җырлар җырлаган

80. Татарстан авыллары
Урта Бирәзә: яңарыш юлында

88. Җылы, уңайлы, үзебезнеке
Кукмара итекләре кәефне ничек күтәрә

Фото: vkgz.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР



22.12

Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты, – юл һәм транспорт инфраструктурасы объектларын ачу вакытында (видеоконференция элемтәсе режимында):

– Казан башка бик күп илләрне көнләштерерлек тизлек белән үсә. Мин моңа зур канәгатьлек белән карыйм. Соңгы елларда республикада сезнең җитәкчелектә ирешелгән уңышлар өчен бу очракта Татарстанның бөтен төзелеш комплексына һәм төзүчеләргә рәхмәтемне җиткерәм. Рәхмәт һәм алга таба да уңышлар сезгә!

12.12

Роман Старовойт, Россия транспорт министры, – Татарстанда берьюлы өч юл объектын реконструкцияләгәннән соң:

– «Волга» М-7 юлын реконструкцияләү ышанычлы транспорт элемтәсен тәэмин итәчәк, республикада сәнәгать җитештерүенең һәм авыл хуҗалыгының тотрыклы үсешенә булышачак, кара-каршы килә торган транспорт агымын бүлү нәтиҗәсендә, әлеге участокларда юл-транспорт һәлакәтләренең кимүенә китерәчәк. Болар барысы да – безнең җиңүгә керткән өлеш, чөнки бүген төп бурыч – махсус хәрби операциядә җиңүне тәэмин итү. Һәм Татарстан бу юнәлештә шактый зур уңышларга ирешә, уртак эшкә үз өлешен кертә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

11.12

Әнвәр Ибраһим, Малайзия Премьер-министры, – «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик караш төркеменең Куала-Лумпурда узган күчмә утырышында:

– Малайзия – ислам финанслары буенча дөньяда лидер. Без шәригать таләпләренә җавап бирә һәм финанс инновацияләренә этәргеч ясый торган институтларның ышанычлы экосистемасын төзедек. Шактый күп мөселман халкына ия Россия ислам банкингы өстенлекләреннән файдаланырга әзер. Бу уртак проектларны гамәлгә ашырырга һәм күпчелек халкы мөселман булган илләрдән инвестицияләр җәлеп итәргә булыша.

Фото: РФ Президенты матбугат хезмәте, kremlin.ru, er.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ясалма интеллект фермада савымны **ничек** арттыра

Минск белән Казан **ничек** «туганлашты»

Кайсы музейда өч телдә сәламлиләр

Ферма **кайчан** шатлык китерә

Фото: Дмитрий Сивков, agro.tatarstan.ru, nurlat-tat.ru

ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ – БАСУДА ҺӘМ ФЕРМАДА

Әхмәт Шакиров

Бер генә сөт савучы да булмаган сыер саву залларындагы «карусельләр», югары уңыш җыеп алыр өчен, агрономга аерым бер басуга кайсы ашламаны күпме кертәсен әйтә торган ясалма интеллект... Цифрлы трансформациянең әнә шундый могҗизалары асылда инде күптәннән беркемне дә гаҗәпләндерми. Һәрхәлдә, Татарстанда. Агросәнәгать комплексын цифрлаштыру динамикасы рейтингында* Россия Федерациясе төбәкләре арасында республика беренче урында тора.

Әтнә районы. «Тукай» ҖЧҖ терлек үрчетү комплексы. 2 400 баш савым сыеры һәм «карусель» тибындагы савым залы. Биредә сөтлебикәләрне роботлар тәэмин итә. Моңа өстәп, тагын 400 һәм 600 баш бозау өчен каралган корылмалар. Саллы гына комплекс, гәрчә республикада иң зурысы булмаса да. Әмма эш аның зурлыгында түгел. «Тукай» ҖЧҖ – цифрлы технологияләр һәм яңалык-

* *Рейтинг РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төзелгән.*

«Карусель»дән сөт 4 градуска кадәр суыту, саклау һәм алга таба тапшыру өчен махсус савытларга килә.

лар кертү буенча районның үзендә генә түгел, ә республикада да иң алдынгылардан санала. Күптән түгел генә биредә узган семинарда хуҗалык җитәкчесе Илфат Хәкимов коллегаларына алдынгылыкка ирешергә ярдәм итә торган заманча технологияләрнең, ясалма интеллект белән цифрлаштыру ысуллары һәм процессларны автоматлаштыру нәтиҗәләре турында сөйләде. Савым көтүенең яхшы күрсәткечләр бирүен тәэмин итә торган сөт саву «каруселе» – җайга салынган системаның бер өлеше генә.

«Тукай» комплексының көтү белән идарә итү программасы белгечләргә хайваннар турында объектив мәгълүмат биреп бара: тулаем да, һәр сыер турында аерым-аерым да. Ясалма интеллект ничек соң шулай бер сөтлебикәне икенчесеннән аера ала, диярсез. Бу бик гади: һәр сыерга аерым датчик беркетелгән, ягъни һәркайсының «электрон паспорты» бар. Сыер савым залына кергәч, ясалма интеллект аны «танып» ала. Оператор да кайсы сыерның «карусель»дә нинди урынга савылырга басуын күреп тора.

Һәр сөтлебикә биргән сөт күләме, сөтнең сыйфаты, малның актив вакыты, ял иткән чагы, сәламәтлеге, булган диагнозлары – бөтен мәгълүмат теркәлеп бара. Теркәлеп кенә калмый, ә операторларга, ферма белән идарә итүчегә, зоотехникка, ветеринарга анализларга, уйланырга, кулай ысуллар сайларга ярдәм итә. Тупланган мәгълүматка таянып, программа башкарылырга тиешле эшләрнең сроклары һәм күләмнәре турында да хәбәр итә.

ПРОГРАММА ПРОДУКТЛАРЫ? ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!

Билгеле булганча, Татарстан – Россия Федерациясендә сөт җитештерү буенча лидер. Терлекчеләрнең югары нәтиҗәләре цифрлаштыруга ни дәрәҗәдә бәйле икән? Бер генә мисалга тукталыйк: Балтач муниципаль районындагы «Дуслык» хуҗалыгында заманча технологияләрне, шул исәптән цифрлы идарә итү программаларын кертү 2023 елда сөт җитештерү күләмен 500 тоннага арттырырга ярдәм иткән. Тагын бер факт: цифрлы система кулланыла торган 188 хуҗалыкта ТР авыл хуҗалыгы оешмаларындагы савым терлегенең 76 проценты тупланган. Шул ук вакытта биредә Татарстан сөтенең 79 проценты савыла, ә узган елның беренче яртыеллыгында әлеге продуктның күләме 69,8 мең тоннага арткан! Өстәмә керем дә ике миллиард сумнан артып киткән.

Аңлашыла ки, бүгенге шартларда цифрлы трансформация бурычларын уңышлы хәл итүдә мөһим факторларның берсе – авыл хуҗалыгы өчен үзебезнең программаларны эшләү. Алар ни дәрәҗәдә көндәшлеккә сәләтле соң? Бүгенге көндә көтү белән идарә итү системалары үзебезнеке, алар чит ил аналогларыннан сыйфатлырак та, шуның өстенә арзанрак та. Димәк, аграрийлар, бигрәк тә кече предприятиеләр аларны сатып ала алачак, дигән сүз.

«Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» («РМИҮ») АҖ генераль директоры Нияз Хәлиуллин көтү белән идарә итүнең үзебездә эшләнгән системасының нәтиҗәлелегенә ачык мисаллар китерде. Татарстан хуҗалыкларының берсендә өч елда бу система ярдәмендә

тәүлеклек савып алынган сөт күләме һәр сыердан 6,5 литрга арткан: төркемнәрне дөрес туплап ашату, ветеринария чараларын саклауга контроль, шулай ук үрчетү буенча комплекслы эш алып бару да үз нәтиҗәсен биргән. Тагын бер игътибарга лаек факт: җитештерүнең нәтиҗәлелеге арту белән беррәттән, оешманың менеджмент буенча чыгымнары да кимегән – болары да шул ук цифрлы чишелешләр, ясалма интеллект куллану аркасында.

КУЛ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ УРЫНЫНА

«РМИҮ» белгечләре бер сан китерә: 99,5%. Көтү белән идарә итү системасы, ясалма интеллектка таянып, сыерларны бер-берсеннән нәкъ шул төгәллектә аера ала. Бу ни дәрәҗәдә мөһим һәм нәрсә бирә? Беренче чиратта, көтү белән дөрес идарә итүнең яңа мөмкинлекләре барлыкка килә. Малларны аерым сыйфатлары буенча берләштерү, һәр сыерның сәламәтлегенә көн саен мониторинг ясау – эшләрне әллә ни зур көч һәм чыгымнар сарыф итмичә генә башкарып чыгарга мөмкинлек бирә. Кичә генә хыял булып тоелган нәрсәләр бүген чынга аша.

– Ясалма интеллект көндәлек мәшәкатьләрне үз өстенә алуы белән яхшы да, – дип аңлата «РМИҮ» АҖ генераль директоры. – Терлекченең көн саен күпме көче һәм вакыты малларны карап-тикшереп чыгу, хәлләрен күзәтеп тору өчен китә иде. Меңәр, икешәр-өчәр мең, хәтта бишәр, унышар мең баш терлек тоткан хуҗалыклар өчен бу – гаять катлаулы бурыч, аны тиешле дәрәҗәдә башкарып чыгу мөмкин дә түгел дияргә була. Хәзер исә техник күзәтеп тору һәм ясалма интеллект әлеге көндәлек мәшәкатьне үз өстенә ала. Ул савым көтүенең нинди хәлдә булуын теләсә кайсы белгечтән дә яхшырак күрә.

Аңлашыла ки, ясалма интеллектка ия теләсә кайсы система арзан тормый. «Тимер» үзе, программасы, системаның көйләнеше, аны карап тору шактый акча таләп итә. Әмма бу чыгымнар үзләрен аклый да. Менә гамәлдә расланган хисаплар. 1000 баш сыер асралган фермада хайваннарның аксавын исәпләп чыгару буенча ясалма интеллект системасын кертү чыгымнарны 13 ай эчендә аклаган – система җиде миллионнан артык өстәмә еллык керем алырга мөмкинлек биргән.

Тагын бер ясалма интеллектлы системага ихтыяҗ зур. Сүз савым залында сыер саву регламентын контрольдә тоту турында бара. Һәр этапта регламентның төгәл үтәлеше тәэмин ителә. Нәтиҗәдә, сөтлебикәләр мастит белән сирәгрәк авырый, аларның сөте категория ягыннан югарырак исәптә йөри, димәк, сату бәясе дә арта. Әлеге система үз чыгымнарын ун ай эчендә аклаган. Системаны кертү чыгымнары елга өстәмә 5 миллион сум керем булып әйләнеп кайта.

КАДРЛАР КЫТЛЫГЫНА КАРШЫ – АКЫЛЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Акыллы системалар кулланылышта гади, әмма аларны үзләштерү, һәр яңа технология кебек үк, һөнәри яктан әзерлек таләп итә. Цифрлаштыру аграр өлкәне шулкадәр тиз үзгәртә ки, хәтта югары уку йортлары да өлгерешә алмый. Шуңа күрә яшь белгечләрне эшкә урнашуга ук өйрәтергә туры килә. Махсус семинарлар, квалификацияне күтәрү курслары булыша. Татарстанда бүген АСК җитәкчеләре һәм белгечләре өчен каралган «Нәтиҗәле агропредприятие: автоматлаштыру һәм цифрлаштыру» дип аталган махсус программа бар. Ул бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Өйрәнү процессында яңа белем һәм күнекмәләр генә алып калмыйсың, югары квалификацияле белгечләр белән бергә үз предприятиең өчен цифрлы трансформация буенча юл картасын да эшлисең. Аннары инде аны гамәлдә кулланырга гына кирәк булачак.

Күптән түгел генә булып узган Kazan Digital Week – 2024 форумы кысаларында ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Ленар Гарипов бик әһәмиятле бер нәрсәгә игътибар итеп узды. «Ясалма интеллект куллану хезмәткәрләрнең квалификациясенә булган таләпләрне бераз йомшарта, кайбер очракларда хәтта көндәлек бурычларны үтәр өчен кирәкле кадрлар кытлыгын капларга да ярдәм итә», – диде ул. Елдан-ел күбрәк кадрларга мохтаҗлык кичергән авыл хуҗалыгы тармагы өчен бу гаять актуаль мәсьәлә.

КОСМОСТАН КАРАШ ҺӘМ ИСӘПКӘ АЛЫНМАГАН ҖИРЛӘР

Республика АСК белән идарә итү системасын тулаем үзгәртмичә, аерым бер предприятиеләргә цифрлы технологияләр кертү белән генә чикләнеп калса, Татарстан, әлбәттә, агросәнәгать комплексын цифрлаштыру рейтингында алдынгылыкка ирешә алмас иде. Бүген ул заман таләпләренә җавап бирә торган цифрлы модель үрнәге исәпләнә. Бу – ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Агросәнәгать комплексының бердәм дәүләт мәгълүмат системасы. Ул 2022 елдан дәүләт статусына ия. Система өч меңнән артык кулланучыны берләштерә, анда теркәлгән авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр республика тулай авыл хуҗалыгы продукциясенең 80 процентын җитештерә.



Бердәм мәгълүмат системасының тугыз төп модуле бар, аларның һәркайсы аерым бер бурычны үтәргә булыша. Аерым алганда, «Мәгълүмат туплау» модуле авыл хуҗалыгы товары җитештерүченең үзеннән, турыдан-туры аның исәп-хисап системасыннан мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә. Бу нәрсә бирә соң? Беренче чиратта, алынган мәгълүматның төгәллеген тәэмин итә, аерым бер этапларда алынганындагы ихтимал ялгышлыкларга юл калдырмый. Мәсәлән, модуль кулланыла башлагач, сөт буенча алынган хисапларның төгәллеге өч мәртәбә арткан.

Үсемлекчелек тармагы өчен нигез саналган «Геомәгълүмат системасы» модуленең дә бик әһәмиятле үз бурычлары бар. Биредә өч миллион гектарга якын басу буенча мәгълүмат тупланган. Бу тулаем статистик мәгълүматның 92% ын тәшкил итә (калган 8%ы – системага кертелмәгән хуҗалык итүнең кече формаларына карый). Модуль агымдагы елгы чәчү җирләрен барларга, басу культураларын җыю, формалаштыру, саклау, кырларның чикләре турындагы мәгълүматны структурлаштырырга, кайчан нинди культура үстерелүен белергә мөмкинлек бирә. Әлеге мәгълүмат, мисал өчен, үсемлекчелек тармагында субсидияләр бүлгәндә бик кирәк.

«Кулланылмаган җирләр» модуле агропредприятиеләргә керемнәрен өч миллиард ярым сумга арттырырга булышкан. Аның бурычы – спутник аша басуларны мониторинглау һәм теркәү. Космостан күзәтү нәтиҗәсендә 4 ел эчендә кулланылмаган 125 мең гектардан артык чәчү җирләре барлыгы ачыкланган. Аларны әйләнешкә кертү агропредприятиеләрнең керемен дә 3,5 миллиард сумга арттырырга ярдәм иткән.

«MADE IN TATARSTAN» ЦИФРЛЫ ИНСТРУМЕНТЛАРЫ

Цифрлаштырудагы казанышлар – ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән «Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» АҖнең үзара килешеп эшләвенең уңышлы нәтиҗәсе ул. Монда иң мөһиме – Татарстанның файдалы, үтемле цифрлы инструментларын республика аграр тармагындагы аерым ихтыяҗларны исәптә тотып үстерү һәм кулланышка кертү. Шундыйлардан, мәсәлән, авыл хуҗалыгы җирләрен мониторинглауны атарга була. Бу система туфракның халәтен, сугаруга һәм ашламаларга мохтаҗлыгын белеп торырга мөмкинлек бирә.

Үзенең нәтиҗәле булуын югарыда аталган ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы да күп тапкырлар исбатлады. «РМИҮ» АҖ генераль директоры Нияз Хәлиуллин әйтүенчә, «системаны кертү һәм хисапларны визуальләштерү ысулларын эшләп чыгу оператив хисапның төгәллеген 83% ка кадәр арттыра, ә менә идарә итү оешмалары белән министрлыкның эш чыгымнарын елына 99 мең сәгатькә кыскарта».

Йомгак ясап, ясалма интеллектны һәм цифрлаштыруны куллануның нинди нәтиҗәләр бирүенә тагын бер ачык мисал китерик. Республикада бүгенге көндә әче туфракны известьләштерү буенча контроль электрон форматта алып барыла. Шуннан нәрсә, дисезме? Янәсе, вак мәсьәлә. Алай димәс идек. Белгечләр мәгълүмат һәм нәтиҗәләрне элеккечә кәгазьдә теркәп барганда, хаталардан саклану кыенга килә иде. Шуңа да мәйданнарның кайбер өлешләрендә известьләштерү – артыграк, кайберләрендә күбрәк башкарылырга мөмкин. Әлеге дә баягы кеше факторы, ни кызганыч, финанс ягыннан югалтуларга китерә: кайдадыр күбрәк известьле ашлама кертеп, өстәмә, хәтта артык эш эшләп ташлыйлар, кайдадыр, киресенчә, известь күләме җитмәгәнгә, уңыш та мактанырлык булмый. Контрольдә тотуның цифрлы системасы кертелгәннән соң, 12% мәйданда известьләштерүнең проект буенча эшләнмәгәнлеген ачыклау финанс югалтуларының шактый булуын дәлилли...

КУКМАРА МИКСЕРЛАРЫ – БЕРЕНЧЕ

Руфия Фазылова

Сер түгел, Россиягә карата кертелгән санкцияләр аерым төр бизнесны үстерү өчен этәргеч бирде. Кукмара районының терлек азыгы миксерлары җитештерә торган «Лидер» җәмгыятенә дә кагыла бу. Илдә барган үзгәрешләрдән курыкмыйча, зур эш башлаганнар. Нәтиҗәдә, бүген республикада алар – беренчеләр рәтендә!

Стационар азык миксерлары җитештерү буенча беренчеләр, диюем. Татарстанда әлегә аларның конкурентлары юк. Укытучылар гаиләсендә туып-үскән, үзе дә Алабуга дәүләт педагогика университетын тәмамлаган Азат Нәбиев шушы юнәлештә эшли башлар дип кем уйлаган?

– Төзелеш өлкәсендә үз эшемне башлаган идем, – дип сөйләде «Лидер» җәмгыяте җитәкчесе Азат Нәбиев. – Кукмара районында йортлар төзедек. Мин хәзер дә «Домострой» компаниясенең директоры вазыйфасында. Соңрак Кукмара һәм күрше районнарда бюджет оешмаларын төзекләндерү эшен дә алып бардык. Аннары металл конструкцияләр һәм авыл хуҗалыгы корылмалары төзү эшенә керештек. Менә шул вакытта ныклап торып терлекчелек базарын өйрәндем. Һәм терлек азыгы катнаштыра торган стационар миксерлар ясап карарга уйладым, чөнки аңа ихтыяҗ зур икәненә инандым.

Шулай итеп, «Домострой» компаниясендә эшләүче эретеп ябыштыручыларның ярдәме белән беренче миксер ясала. Аны Кукмараның бер колхозында сынап карыйлар. Нәтиҗә озак көттерми.

– Кукмараның «Рассвет» хуҗалыгы рәисе белән сөйләшеп тордык, – дип дәвам итте Азат Нәбиев. – Безнең стационар миксерны сатып алганнан соң тәүлегенә бер сыердан савылган сөт 4,5 литрга арткан, ә бит алар рационны үзгәртмәгән. 1 200 башка исәпләнгән комплекстагы сыерлардан савылган сөтне 4,5 литрга тапкырласак, көнгә өстәмә рәвештә 5,4 мең литр сөт алына, дигән сүз. Аена бу 162 мең литр килеп чыга. Ул чакта сөтнең литры 30 сум тора иде, нәтиҗәдә, «Рассвет» хуҗалыгы бер ай эчендә 4,8 миллион сум керем алды.

Әгәр Кукмараның шушы хуҗалыгы мисалында карасак, стационар миксер чыгымын алар ике ай эчендә аклаган. Чөнки җайланма бүген якынча 9 миллион 400 мең сум тора икән.

– Тугыз миллион ярым сумга якын аз акча түгел, хуҗалыклар сез эшләгән миксерны кредитка аламы? – дим.

– Без «Росагролизинг» компаниясендә аккредитация уздык, бу исә хуҗалыкларга өч процентлы кредит алырга мөмкинлек бирә. Монысы бер. Икенчесе. Күп хуҗалыклар республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы программасы ярдәме белән дә ала.

«Лидер» җәмгыяте шулай ук «КАМАЗ» машинасына көйләнгән азык өләшү, вакуумлы төргәкләү җайланмалары да эшләп чыгара. Тагын авыл хуҗалыгында ашлама эретү җайланмасы да җитештерә. Аларына да сорау зур икән. Шулай да төп юнәлеш – стационар миксерлар ясау. Шулай ук миксерлар өчен бина корып бирү мөмкинлеге дә бар.

– Сез бит Татарстанда беренче. Бер тәҗрибә булмаган килеш ничек бу эшкә өйрәндегез?

– Россиядә безнеке кебек стационар миксер ясый торган оешмалар бар, алардан да карадык. Чит илләр тәҗрибәсен дә анализладык, аларның өстенлекләрен, кимчелекләрен өйрәндек. Аннары, бездән сатып алуның тагын бер уңай ягы бар: үзебезнең сервис үзеге эшли. Кирәк икән, хуҗалыкларга да барабыз. Ә болай стационар миксерларга 12 айлык яки 700 мотосәгатьлек гарантия каралган.

«Лидер» җәмгыятендә бүген 12 кеше хезмәт куя. Бер стационар миксерны ясау өчен егерме көнләп вакыт кирәк икән. 2020 елдан бирле оешма кырыкка якын шундый заманча җиһаз эшләгән.

Алдан күрү сәләте, тәвәккәллек, кыюлык... Күргәнебезчә, шушы сыйфатлар булганда, юктан бар итәргә һәм уңышлы эшкуарга әйләнергә мөмкин.

+7 (937) 573-21-73
+7 (965) 581-09-02
lider_kuk@mail.ru
kukmaragro.ru

Фото «Лидер» ҖЧҖнән алынды. РЕКЛАМА

РОБОТЛАР СЫЕР САВА?

Сөмбел Могыйнова

Замана диген: сыерларны роботлар сава. Гаҗәп, барысы өчен дә ул җавап бирә: сыерның күпме ашаганын, күпме сөт биргәнен күрсәтә, кайчан бозаулыйсын, авырулары турында да әйтә... Тик робот белән эшләүнең дә үз проблемалары бар. Аксубай районының Яңа Ибрай авылы фермеры Ильяс Сөләйманов мисалында әнә шундый ферманың нечкәлекләрен өйрәндек.

Роботлашкан фермалар чынлап та башка. Биредә һәр сөтлебикәнең муенында махсус чипы бар, менә шул бар мәгълүматны җиткереп тора. Сыерны да робот сава, көненә ике түгел, өч-дүрт тапкыр. Саву аппараты шулай көйләнгән: сыер килеп баса, робот башта сөтлебикәнен җиленен юа, аннары сава. Экранда бу малкайның күпме сөт биргәне күренеп тора. Эш беткәч, саву аппараты җиленнән үзе алына, һәм сыер чыгып китә. Чират буенча икенчесе килә. Һәм бу тәүлек буена шулай, ягъни сыерлар төнлә дә килеп җиленнәрен бушатып китә. Гаҗәп бит.

Аксубайның атаклы фермеры Ильяс Сөләйманов роботлар белән 2020 елдан бирле эшли. Ул чагында 50 миллион сумга ике робот һәм 140 нәселле савым сыеры да алып кайта. Шуның 20 миллион сумын фермерга ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы күчерә, ягъни грант бирелә.

– Робот сава башлагач, сыерларның продуктлылыгы өч атнада 6 литрга кадәр күтәрелде, – диде Ильяс Сөләйманов. – Шул ук карау, шул ук ашату югыйсә, әмма роботлар тиешенчә сава, дөрес технология белән эшли. Аннары роботлар белән саву эшне бермә-бермә җиңеләйтте дә. Бүгенге көндә 180 баш савым сыеры бар. Аларны саварга каян кеше аласың? Авылда бит хәзер сыер савучы, механизатор табу бик авыр.

– Сезнең авыл зур бит, ничек инде кеше юк? – дим, аптырап.

– Менә шулай, юк. Авылда яшьләр калмый, бөтен бәла шунда. Калыр иде, аларга бернинди ярдәм каралмаган. Мисал өчен, үзебезнең авылны гына алыйк: асфальт юл юк, үзәккә кадәр генә булса да. Үз акчабызга җыелып юл салабыз, чишмәсен дә карыйбыз. Ә бит район үзәгенең һәр урамында асфальт юл, шәһәрне әйтсәң дә юк. Авыл кешесе икенче сорт булып чыгамы? Югыйсә без дә – шул ил гражданнары, салымын түлибез, иртә таңнан кичкә кадәр эшлибез.

Фермер шулай диде дә туктап калды. Бу аның җан авазы бит. Азрак тынычлангач, Ильяс Сөләйманов дәвам итте:

– Бүген, мисал өчен, техниканы, компьютерны белә торган мал табибы кирәк. 100 мең сум хезмәт хакы түләргә дә риза, тик кеше табып булмый. Олы кеше яңалыкны авыр кабул итә, өйрәнә алмый. Яшь кеше булса, хәзер эләктереп алыр иде, ә алар юк. Әйткәнемчә, яшьләргә авылда калу өчен кызыксындыру чаралары, шартлар җитми. Әле ярый ике улым бар, фермерлык эшен алар белән бергәләп алып барабыз.

Ильяс Сөләймановның фермерлык юлы кызык кына. Башта ул биш-алты ел Алабуга шәһәрендә яшәгән, эшләгән. 2000 нче елда исә туган авылына кайтып, үз эшен булдырган.

– Эшне бер сыер белән 50 гектар җирдән башладым, – диде тәҗрибәле фермер. – Колхоздан әти-әнинең пай җирләрен алып, иген, печән чәчтем. Акрынлап мал саны да, җирләр дә арта торды. 2010 елда «Гаилә фермасы» программасына кереп, беренче зур ферма төзедем. 2021 елда тагын бер грант отып, яңа ферма бинасы салып чыктык. Тәвәккәл булсаң, барысы да мөмкин икән.

Кама аръягы зонасында беренчеләрдән булып фермасын роботлаштырган фермерның бүген 300 гектардан артык җире бар. Һәм инде бөтен техникасын да табып, эшне оештырган, җайга салган ул. Иң сөенечлесе – дәвамчылары бар. Олы улы Илһам Казан дәүләт энергетика университетын тәмамлаган, бүген Чаллыда яши. Кече улы Сәет исә нәкъ менә роботлаштырган җайланмалар юнәлешендә белем ала. Югары белем алганнан соң, этисенең эшен дәвам итәргә ниятли.

– Чакырсаң, ике улым да бүген үк авылга кайтачак, – ди Ильяс Сөләйманов. – Тик әле үзем дә җитешәм, шөкер. Хәер, улларым болай да атна саен авылда. Техниканы яшьләр яхшырак аңлый бит. Киңәшләшеп эшлибез. Роботлар көйсезләнә башласа, үзебез төзәтәбез. Компьютерда кимчелекләр килеп чыкканда гына аерым белгечләрне чакыртабыз, чөнки тәртибе шундый.

Тәвәккәллек. Эш сөючәнлек. Ильяс Сөләймановның төп уңыш сере шулдыр кебек тоелды.

Фото Ильяс Сөләйманов архивыннан. РЕКЛАМА

AGROMASTER
ҖИТЕШТЕРҮ КОМПАНИЯСЕ
TILLERMASTER
УРТАЧА ТИЗЛЕКЛЕ КУЛЬТИВАТОР
CLASSICMASTER
ЧӘЧҮ АЛДЫ КУЛЬТИВАТОРЫ
MEGADISK
КИҢ ЙӨРЕШЛЕ ДИСКЛЫ АГРЕГАТ
TILLERDISK
КОМБИНАЦИЯЛЕ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGRATOR ANCER
АНКЕРЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGRATOR DISK
ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
Реклама
тел.: 8(85556) 2-39-08
тел.: 8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru
Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай урамы, 33 а
AGROMASTER
Европа сыйфаты – Россия бәясе!

КАЗАН АГРО 2025

Агросәнәгать комплексы казанышларының махсуслаштырылган авыл хуҗалыгы күргәзмәсе

12-14 февраль, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге

300+ катнашучы оешма

12 000+ кунак

35 га экспозиция

ЯҢАРЫШЛАР ЗАМАНЫ
КАЗАН АГРО ЗАМАНЫ

+7 (927) 048-94-51 info@project-16.ru

Минск. Яр буе.

ТУГАНДАШЛЫК ДУЛКЫНЫНДА

Күңелле хәбәр. Минск белән Казан – хәзер тугандаш шәһәрләр. Безне киләчәктә файдалы хезмәттәшлек, тәҗрибә уртаклашу, мәдәни алмашулар көтә... Ә шәһәр мэрлары Минскида – Казан көннәрен һәм Казанда Минск көннәрен уздыру ниятен дә җиткерделәр. Хәер, «Татарстан», әлеге гамәлләрнең тормышка ашуын көтеп тормыйча, дилбегәне үз кулына алырга булды. Белоруссия башкаласы Минск турында «Татарстан» укучылары махсус хәбәрчебезнең язмаларында укый ала.

Айдар Мөшәрәпов фотолары

Минск шәһәре.

МИНСК. ЛӘКЛӘКЛӘР КАЛАСЫ

Әскәр Сабиров

«Чыгуначны вакзал» бинасына беркетелгән футуристик элмә такта аның вокзал булуын хәбәр итә. «Паштамт» дип раслый икенчесенә эленгәне. «Прычыненне шкоды караецца па закону» дип, кырыс кына кисәтә өченчесенә беркетелгән такта. «Ни дисәң дә чит ил шул», – ди баш миенең кайсыдыр бер өлеше. «Юк инде, барысы да бездәге кебек бит», – дип төзәтә шунда ук икенче бер чите. Ләкин икесе дә дөрес шикелле: «Чит илдә, ләкин үз өеңдәге кебек… ». Мин – Белоруссия башкаласы Минскида!

«Чит илдә, ләкин үз өеңдәге кебек…» тойгысы Минск вокзалы эскалаторына аяк басуга ук пәйда була. Элмә такталар һәм юл күрсәткечләре – белорус телендә, әмма барысы да бик яхшы аңлашыла. Тимер юлны рус телендә кайчандыр чугунка дип йөрткәннәр, шуңа күрә «чыгуначны вакзал». «Слава пераможцам» лозунгының мәгънәсен шулай ук тәрҗемәсез дә аңлап була – җиңүчеләргә дан, ә инде «прадукты», «паштамт» яки «цырк» турында әйтеп тә торасы юк. «Цырк»ны укыгач, фәнни ачыш ясыйм: белорусларның табигый прагматизмы язуда да чагыла икән. Рус грамматикасында – кагыйдә һәм һәртөрле чыгармалар диктаты, ә тугандаш славяннарда аек акыл иреге – ничек ишетәбез, шулай язабыз…

ТРОИЦК БИСТӘСЕНЕҢ АЛТЫН ГАСЫРЫ

Гасырлар буена шомарып беткән таш урам. Очлы чирәп түбәләр. Агач капкачлы, челтәр рамлы тәрәзәләр. Таш аркалы капкалар артында җыйнак кына ишегаллары яшеренгән. Үзеңне урта гасыр шәһәрендә, кайдадыр Польшада яки Литвада кебек хис итәсең…

Чынлыкта бу – Троицк бистәсе, Минск шәһәре шушы урыннан башланган, дип фаразлана. Кайчан нигез салынгандыр – тарихта әле ахыргача ачыкланып бетмәгән, әмма XIV гасырда биредә шәһәр үзәге булганлыгы төгәл билгеле.

– XVI гасыр ахыры – XVI гасыр башына караган язма чыганакларда әлеге районны «Старое место» дип атаганнар, – дип аңлатты экскурсовод Николай, җирле кавярняда каһвә эчеп утырганда. – Гаҗәп түгел. Биредә, Свислочь елгасының сул як ярында, Вильня белән Полоцк, Смоленск белән Могилев юллары тоташа… Сәүдә өчен – оҗмах. Хәер, сәүдә өчен генә дә түгел. Мәдәниятләр, гореф-гадәтләр, телләр очрашып, катнашкан-укмашкан урын. Ә сез белорусча кофейняның поляк һәм литва телләрендәге кебек яңгыравына гаҗәпләнәсез! Безнеңчә – кавярня, поляклар – kawiarni, литвалылар kavine диләр.

Троицк бистәсенең тар урамнары буйлап йөргәндә, элек монда нинди тормыш кайнаганын күз алдына китерергә тырышам. Якында гына Троицк базары шаулый, анда бөтен Ев-

1906 елгы костёл.

ропадан сәүдәгәрләр килә. Ә менә монда князь Ягайло төзегән Троица костёлы тора. Әнә католик мариавитлар ордены торагы, аның артында бай шәһәр кешеләренең йортлары, һөнәрчеләрнең кибетләре урнашкан...

Кызганыч, ул вакыттагы йортлардан һәм костёллардан бик аз нәрсә калган – барысы да 1809 елгы көчле янгында күмергә әйләнә. Шуннан соң Троицк бистәсен сакланып калган элеккеге планы буенча яңадан төзиләр, әмма вакыт зилзиләсе бу җирләрне тагын берничә мәртәбә йөреп чыга: сугышлар һәм революцияләр бер дә эзсез үтми.

Ә Троицк бистәсен яңадан чагыштырмача күптән түгел генә торгызалар. XIX гасырдагы кыяфәтен кире кайтаралар. Җирле халык сөйләгәнчә, объектлар бүген дә урта гасыр биналары нигезендә тора. Иң мөһиме – реставраторлар иске шәһәрнең атмосферасын саклап кала алган.

ӨСКЕ ШӘҺӘР ТАРИХЫ

Кулына зур ачкыч тоткан, аяк астына урта гасыр шәһәре картасы салынган кәттә вельможа хуҗаларча Минск мәйданын күзәтә. Мэр, яки ул чагында бургомистрдыр, дип фаразлый бирегә беренче тапкыр килүче турист, шактый гәүдәле бронза сынга карап.

– Бу войт, – дип йомшак кына төзәтә аны экскурсовод. – Войт – магистрат, ягъни шәһәр җитәкчелеген гамәлгә ашыра торган бәйсез үзидарә органы башлыгы. Эш шунда ки, Минск өстенлекле статуска ия була, чөнки король галиҗәнаплары аңа Магдебург хокукын – шәһәр үзидарәсе системасы хокукын тапшыра....

Бу биредә демократия шаукымы хөкем сөрә, дигән сүз. Һәм бу – караңгы урта гасырларда... Чөнки мондый мәрхәмәтне король 1499 елда ук бүләк итә. Әлеге өстенлек шәһәр халкын феодаль йөкләмәләрдән

дә коткара (аның урынына бердәм салым түлиләр), шәһәрлеләр шәхси ирекә ия дип игълан ителә, җир милегенә хосусый хокук ала һ. б. Мондый шаккаткыч хөрлек бары тик 1831 елда император Николай I указы нигезендә генә бетерелә...

Бронза войтны Минскига 2009 елда гына кайтаралар. Сын артында – шәһәр Ратушасы, ул Магдебург хокукы тапшырылган калага рөхсәт ителә. XIX гасырда Ратушаны шулай ук җимерергә мәҗбүр итәләр (боерыкны Николай I үз кулы белән имзалый). Ләкин шәһәрлеләр арасында аның үлчәмнәрен алып калырга өлгерүчеләр табыла. Һәм инде ике гасырдан соң аны яңадан торгызганда, сакланып калган бу сызымнар бик кирәк булып чыга.

Үткән гасырлардагы кебек үк, Ратуша яңадан Ирек мәйданын (элеккеге Собор мәйданын) бизәп тора. Аның белән бергә, шәһәрлеләр раславынча, хәтта... өрәк тә кайткан, ди. Анысы тагын нинди әкият инде, дисезме? Имеш, таң алдыннан берәдә шляхтич Михал Володковичның рухын күрергә була, диләр. Шляхтич кайнар холкы белән аерылып торган. Һәм бервакыт, шәһәр советы әгъзасы булып торганда, ниндидер бер низаг вакытында тыелып кала алмый: кылычын суырып чыгара да Иисус Христос статуясы колагының бер өлешен чабып өзә. Володковичны үлемгә хөкем итәләр. Ратуша төрмәсендә җәзасын көткәндә, ул, тәүбә итүдән баш тартып, үзе янына китерелгән руханины куып чыгара. Тәүбәгә килмичә үлгән шляхтичның тынгысыз җаны өрәккә әверелә һәм Ратуша тирәсендә йөри, ди...

Изге Ана костёлы (XVIII гасыр башы) да Ратуша янында, бернардиннар монастыре, Кунак йорты, Пшездецкийлар дворян нәселенең элеккеге утары һәм сәүдә рәтләре дә шул тирәдә. Шулай булгач, XIV гасырда Минскиның үзәге булган Өске шәһәрнең нинди булуын күз алдына китерү артык зур кыенлык тудырмый: нәрсәдер сакланып калган, нәрсәнедер иске сызымнар һәм рәсемнәр буенча торгызганнар.

Әйе, мәйданда булырга туры килсә, бер сынамышны тикшерү мөмкинлеген кулдан ычкындырмагыз. Урта гасыр шәһәр тормышы күренешен мәңгеләштергән скульптура композициясен эзләп табыгыз: сатучы һәм сатып алучы товар тутырылган капчыкны үлчи, өченче берәү – магистрат түрәсе – эшнең дөрес башкарылуын игътибар белән күзәтә. Әнә шул капчыкны сыйпап карау – байлыкка, диләр...

Ышкылудан ялтырап беткән әлеге капчыкка карагач, без барыбыз да һәртөрле ырым-шырымнарга ышанабыз, ахры, дип уйлап куясың.

Ә скульптура, сүз уңаеннан, бернинди дә фантазия түгел. Элек Ратушада шәһәр үлчәүләре* – Европа метрик системасы эталоны урнашкан була. Әгәр дә сәүдәгәрдә сатучының намуслы булуы шик уята икән, ул һәрвакыт товарны войтка алып килә ала. Аның белән бергә товарны яңадан үлчәп, хакыйкатьне ачыклап булган.

Кулына зур ачкыч тоткан кәттә вельможа хуҗаларча Минск мәйданын күзәтә. Аның артында – шәһәр Ратушасы.
Янәшәдә – Изге Ана костёлы, бернардиннар монастыре...

Өске шәһәр, Ирек мәйданы.

Урта гасыр шәһәр тормышы күренешен мәңгеләштергән скульптура композициясе.

* Мондый үлчәүләр бары тик Магдебург хокукына ия шәһәрләрдә генә була.

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

«БУДЫНАК XIX ст. Прычыненне школы караецца па закону», – дип хәбәр итә кызыл кирпеч диварга беркетелгән язу. Бу Раково бистәсендә сакланган биналарның берсе.

Сугышка кадәр биредә яһүд гаиләләре яшәгән. Кырык беренченең июнендә немецлар шәһәргә керә һәм нәкъ менә шушында, Раково бистәсендә, гетто оештыра. Өйләренә тимиләр, ә аларда яшәүче хатын-кызларны, бала-чагаларны, карт-корыны ачтан интектерәләр, немецларга хас төгәллек белән үтерергә керешәләр. Геттога керү урыннарының берсенә беркетелгән мемориаль тактада язылганча, монда йөз меңнән артык яһүднең җаны кыелган.

Ул сугыш вакыйгалары – мәңге төзәлмәс яра. Быел БР Прокуратурасының Законлылык һәм хокук тәртибен ныгыту проблемалары фәнни-гамәли үзәге директоры Игорь Мороз атаган саннарга күз салыйк: Белоруссия сугыш елларында 3 миллионлап кешесен югалткан. «Демографлар исәпләвенчә, әгәр сугыш башланмаса, бүген безнең халыкның саны 17 миллионга якын булыр иде, – дип хәбәр итә Мороз. – Чөнки без тереләре белән бергә, туарга өлгермәгән күпме кешене дә югалттык». Белешмә өчен: бүген дөньяда 10 миллионга якын белорус яши.

Ул коточкыч сугышны Минскида күп нәрсә хәтерләтә. Толбухин бульварындагы кара гранит плитәдә: «Тут пахавана больш 10 тысяч савецкіх воінау, партызан и мірных грамадзян...», дип язылган. Челюскинчылар паркындагы, Дзержинский проспектындагы туганнар каберлекләре... Хәтта Коммунистлар урамында сугыштан соң төзелгән гади генә «сталинка» йорт та. Фасадына «1952 елның июнендә бу йортны төзегәндә бина нигезенә герой-шәһәр Волгоградтагы легендар Павлов йорты кирпечләре салынды» дигән язу эленгән. Сугыш кына булмасын... Бүген Минск халкы шуны тели. Нагасаки чаңы да – моңа чын дәлил.

Раково бистәсендә.

Ләкләкләр – Белоруссия символы.

«ФӘРЕШТӘ» КҮЛӘГӘСЕ

Күмер кебек кара диварлар, алар арасында тын гына чаң утыра. Мин, сез, гомумән теләсә кайсыбыз, янына килеп, аны уята ала. Мин дә акрын гына якынрак килдем: чаң җавап бирә – аның кайгылы, моңсу тавышы күкне яра. Мемориал «Нагасаки чаңы» дип атала. Бу – хәтер. Һәм кисәтү.

Чаң илгә Нагасаки католиклар епархиясе тарафыннан бүләк ителә. Ул – 1945 елның 9 августында атом җәһәннәмендә могҗиза белән генә исән калган «Фәрештә» чаңының төгәл күчермәсе. Ә мемориал нигезенә туфрак тутырылган капсулалар салынган. Хиросимадан. Нагасакидан. Чернобыль АЭС зонасыннан. Яңа Җирдәге һәм Семипалатинск янындагы атом полигоннарыннан. Дөньяда беренче атом бомбасы шартлаган Нью-Мексико штаты (АКШ) полигонынннан. Кешенең акылына һәм хисләренә мөрәҗәгать бу. Сугыш кына булмасын…

Бу мемориал Минскидагы Бәйсезлек мәйданында урнашкан. Янәшәдә, шул ук мәйданда, – революциягә кадәрге Изге Симеон һәм Еленаның католиклар костёлы, Хөкүмәт йорты, совет чорын хәтерләтүче җиде метрлы бронза Ленин, тагын бер ядкәр – плебания, католик рухани йорты. Бу каршылыклы төрлелек тыныч кына янәшә яши, һәм барысы да искиткеч дәрәҗәдә бер-берсенә туры килә.

Нагасаки чаңы. Мемориал нигезенә туфрак тутырылган капсулалар салып калдырылган.

Бәлки, чишелеш тә биредә – Бәйсезлек мәйданы үзәгендәдер. Аны «Ләкләкләр» скульптура композициясе бизи. Ә ләкләк, исегезгә төшерәм, – тынычлык һәм зирәклек символы, явыз көчләрдән яклаучы һәм саклаучы. Һәм Белоруссия символы. Барысы да дөрес: дин, карашлар, мәнфәгатьләр, тарих, телләр һәм милләтләр – каршылыкларга сәбәп түгел. Ә капма-каршылыклар кайвакыт хәтта якынайта да ала әле.



Музей өч катлы кирпеч йортта урнашкан. Биредә 1891 елдан, он тарттыру заводына нигез салынганнан башлап, завод җитәкчелеге яшәгән.

Автор фотолары

ПЕЧИЩИ АВЫЛЫНА, ЯНКА КУПАЛА ЯНЫНА

Дмитрий Сивков

Югары Ослан районының Печищи авылындагы Янка Купала музее, Белоруссия халык шагыйренең «Здравствуйте! Исәнмесез! Добрый дзень, сябры!» дип, берьюлы өч телдә сәламләп каршылый торган Россиядәге бердәнбер мемориаль музей-фатиры булуы белән генә түгел, бәлки гайре табигыйлеге белән дә тиңдәшсез – чөнки ул анда бөтенләй ачылырга тиеш булмаган.

Татарстан һәм Казан үзе сугыш елларында күп кенә иҗат әһелләренең сыену урыны була. Аерым алганда, бирегә СССР һәм Белоруссия ССР язучылар берлекләре эвакуацияләнә. Мәскәүдә эвакуация пункты итеп Казанны билгеләгәннәр, әмма шәһәр барысын да сыйдыра алмый. Шуңа күрә язучыларны, шагыйрьләрне республика буенча таратып урнаштыралар: күпчелеген – Чистайга, калганнарын – Яр Чаллыга, Алабугага.

Янка Купала тәхәллүсе белән күбрәк танылган Иван Доминикович Луцевич музее, бәлки, соңрак нәкъ менә бу шәһәрләрнең берсендә ачылган булыр иде. Әмма язмыш язучыны эвакуация маршрутында бөтенләй каралмаган Печищи авылына китерә, һәм вазгыять көтмәгәндә үзгәреп куя...

ТЕГЕРМӘНДӘ ЧӘЙЛӘҮ ФАЙДАСЫ

1941 елның 11 ноябрендә Печищидан Казанга кадәр паром кичүе янында бетмәс-төкәнмәс чират пәйда була. Килбәтсезрәк йөк машиналары арасындагы затлы кара Chevrolet Master Deluxe GA бөтен кешенең игътибарын үзенә җәлеп итә. Кизү торучы комендант чит ил машинасы пассажирларының документларын тикшерә һәм анда шагыйрь, академик, Белоруссия ССР Югары Советы депутаты Иван Луцевич булуын ачыклый. Ул хатыны Владислава Станкевич һәм машина йөртүчесе белән Казанга үз автомобилендә килергә уйлый. Ә Белоруссия Язучылар берлеге һәм Фәннәр академиясенең башка әгъзалары республика башкаласына махсус эшелон белән алданрак эвакуацияләнгән була.

Комендант, ил күләмендә танылган шагыйрьне күргәч, паромга чиратсыз керергә тәкъдим итә. Ләкин Луцевич баш тарта, телефоннан ничек шалтыратып булуын гына сорый. Шулай итеп, Янка Купала җирле икмәк заводы, яисә халык арасында тегермән дип йөртелгән заводның директоры Иван Наякшин йортына килеп эләгә. Мондый атаклы кешеләрне бер чынаяк чәй дә эчертмичә җибәреп булмый бит инде. Ә табында утырганда кунакларның төгәл кайда тукталачаклары билгесез булуы ачыклана. Менә шуңа күрә Наякшин аларга фронтка киткән баш инженерның күршедәге буш фатирын тәкъдим итә.

Янка Купала Печищига кадәр утырып килгән Chevrolet Master Deluxe GA. 1937 елда чыгарылган автомобиль 1939 елдан 1942 елга кадәр шагыйрьнеке була. Минскида Янка Купаланың Дәүләт әдәби музеенда саклана. Хәзерге вакытта автомобиль 100 000 евродан да кыйммәтрәк бәяләнә.

КОМАНДИРОВКАДАН КИРЕ КАЙТМЫЙ

Луцевич белән хатыны, озак уйлап тормыйча, әлеге тәкъдимне кабул итә. Фатир да яхшы, Иделнең текә ярыннан искиткеч манзара ачыла. Иртәгесен, пароходка утырып, Казанга барып кайтасы гына кала – килеп җитүне һәм нинди фатирда тукталуны хөкүмәткә хәбәр итәсе мәҗбүри була. Анда, мөгаен, мондый катлаулы мәсьәләнең үзеннән-үзе хәл ителүенә шатланганнар гынадыр.

Завод җитәкчеләре яшәгән өч катлы кирпеч йорттагы фатир, кызганычка каршы, шагыйрь үзе ниятләгәнчә, аның вакытлы почмагы түгел, соңгы тукталышы була. Моннан ул 1942 елның 18 июнендә башка-

Янка Купала музее элеккеге Печищи икмәк продуктлары комбинаты территориясендә урнашкан.



«Хлопчык і летчык» шигыренә кертелгән төзәтмәләр белән автограф күчермәсе. Янка Купаланың гади һәм җиңел шигырь юллары меңләгән совет баласын авиатор шлемын киеп карарга рухландырган.

Янка Купала тәмәкене күп тарта, үзе белән һәрвакыт трубка яки тәмәке кәгазе йөртә, янчыгы гел тәмәке белән тулы була, тегермән эшчеләрен дә бик теләп сыйлый.

Репродукторның легендар «кара тәлинкәсе». Янка Купала иртәләрен, икмәк заводы эшчеләре Совинформбюро хәбәрләрен тыңласын өчен, аны тәрәзәгә таба каратып куя торган була, диләр.

лага иҗат командировкасына китә, анда 10 көннән соң «Мәскәү» кунакханәсендә фаҗигале төстә һәлак була.

Алар Мәскәүгә вакытлыча дип китә, шуңа күрә фатирда Янка Купаланың шәхси әйберләре – пиджагы, күлмәге, чемоданы, таягы, тәмәке янчыгы, тәмәке кәгазе, трубкасы, медикаментлар тулы контейнеры кала. Купаланың әйберләрен чормага менгерәләр. Анда барысы да бик яхшы саклана, ә инде 1975 елның 28 маенда нәкъ шулар яңа ачылган музей экспозициясенең нигезен тәшкил итә. Татарстанга эвакуацияләнгән күренекле әдәби шәхесләр белән бәйле башка бер генә музейга да мондый бәхет тәтеми.

ГАГАРИННЫ ОЧАРГА ИЛҺАМЛАНДЫРГАН

Янка Купаланың «вакытлы фатиры» ике бүлмәдән – гомуми һәм эш кабинетыннан тора. Беренчесендә шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын тасвирлый торган экспозиция булдырыла. Икенчесендә 1942 елдагы кебек мохит тудырыла: китап шкафлары, диварда – репродукторның «кара тәлинкәсе», язу өстәлендә – эре хәрефләр белән язып тутырылган кулъязмалар.

Белорус әдәбияты классигының караламалары арасында ул чорда Советлар Союзында күп бала яттан белгән «Хлопчик-лётчик» шигыре дә бар. Юрий Гагарин әйтүенчә, нәкъ менә «Возьми меня, лётчик отважный,/В полёт по Советской стране:/Я смелый, и мне не однажды/Летать приходилось во сне» (Михаил Исаковский тәрҗемәсе) дигән юллар аңарда күккә мәхәббәт уяткан.

Гомумән, кабинет хуҗасы тегермән эшчеләрен тәмәке белән сыйларга һәм, көйрә-

ТР Милли музееның филиалы – Печищи авылындагы Янка Купала музее директоры Римма Абызова.

Минскида Янка Купала һәйкәле.

теп торганда, фронт яңалыклары турында сөйләшергә беразга гына урамга чыккан, тиздән кереп җитәчәк кебек тоела.

СЫНГАН ҮКЧӘ ҺӘМ ИВАН КУПАЛА ТӨНЕ

Мондый мохитне музейның директоры да, экскурсияләр үткәрүчесе дә үзе булган Римма Абызованың мавыгып сөйләве дә тудырадыр. Музей – аның язмышының аерылгысыз өлеше.

Үзегез уйлап карагыз: Югары Ослан мәктәбенең икенче сыйныфында укыганда, ул әти-әнисе белән музей ачылышында була. Соңрак, 1983 елда, музей экспозициясен яңарту тантанасында, инде унынчы сыйныф укучысы сыйфатында яшьләр исеменнән чыгыш ясый. Шул ук көнне икенче катка менә торган текә баскычта Римма бәйрәм хөрмәтенә генә кигән әнисе туфлиенең үкчәсен сындыра. Комсомол башлыгының кайгысын уртаклашасы урында, сыйныфташлары: «Димәк, син монда калачаксың!» – дип үрти. Бу «күрәзә» нәкъ егерме елдан соң, башлангыч сыйныфлар укытучысына музейны җитәкләргә тәкъдим килеп төшкәч, тормышка аша.

Мәҗүсилеккә караган бәйрәм исемен үзенә тәхәллүс итеп алган шагыйрь шәхесе, әлбәттә, серле булырга тиеш. Шуңа күрә монда Иван Купала төнен дә үзенчәлекле итеп үткәрәләр: кичен музейда шигырьләр укыйлар, аннары яр буенда җырлар җырлыйлар, учак ягалар, кыр чәчәкләреннән такыялар үрәләр, ә төн уртасында аларны елгага агызалар.

Печищидагы музей – Россия - Белоруссия дуслыгының мәдәни-агарту үзәге дә ул. 2024 елның апрелендә милли стильдә бизәлгән кунак бүлмәсе ачылганнан соң, моның өчен күбрәк мөмкинлекләр туган.

Тагын бер яхшы гадәт - Янка Купала музеенда кадерле кунакларны чәй эчертми җибәрмиләр. Бу традициягә 1941 елның 11 ноябрендәге истәлекле чәй эчү вакыйгасына хөрмәт йөзеннән нигез салынган.



XX йөз әдәбиятының күп төсләр бәйләмендә мәшһүр белорус шагыйре, әле үзе исән чакта ук дөньякүләм танылуга ирешкән Янка Купаланың тавышы югалып калмаган, вакыт агышына уярп юылмаган.

Һәр халыкның җанын, холкын һәм хис-омтылышларын чагылдырган шигъри даһие була. Русларда — Александр Пушкин, украинлыларда — Тарас Шевченко, татарларда — Габдулла Тукай. Белоруслар да исә — Янка Купала (Иван Доминикович Луцевич). Беларусьның халык шагыйре исеме белән, гәрчә башка югары бүләкләргә дә ия зат булса да, иң дәрәҗәле титул санап

В многоцветной палитре литературы XX столетия не смыт потоком времени и не затерялся голос выдающегося белорусского поэта Янки Купалы, уже при жизни получившего мировое признание.

У каждого народа свой поэтический гений, отразивший его душу, его характер и чаяния. У русских — Александр Пушкин, украинцев — Тарас Шевченко, у татар — Габдулла Тукай. У белорусов — Янка Купала (Иван Доминикович Луцевич). Как самым высоким титулом дорожил он званием народного поэта Беларуси, хотя не был обойден иными высокими наградами.

Белоруссия Республикасы Президенты Александр Лукашенконың музейга рәхмәт сүзләре язылган автографы.

ҖИНАЯТЬЧЕГӘ ӘЙЛӘНМӘС ӨЧЕН...

«Татарстан» журналында түгәрәк өстәлне безгә инде моңарчы басылып чыккан язмалар аша яхшы таныш фермер Рыжов оештырды. Юрий Павлович күп еллар дәвамында органик туклану идеясе белән янып йөри. Ул, хуторында «тормыш империясе» оештырып, авыл хуҗалыгындагы казанышлары белән Татарстан мәктәпләрендәге укучыларны да таныштырырга әзер. Очрашуга бу идея белән чын-чынлап кызыксынучылар җыелды.

- **Айдар Шәмсетдинов**, «Адымнар» полилингваль комплексы директоры;
- **Гөлнара Галиева**, «Ритм» 187 нче күппрофильле лицей директоры;
- **Инназар Хөсәенов**, авыл хуҗалыгында консалтинг өлкәсендәге индивидуаль эшкуар;
- **Динара һәм Ринат Рәхмәтуллиннар**, «НатурПродукт» компаниясе хуҗалары;
- **Татьяна Вафина**, **Әскәр Сабиров, Рәшит Хәйретдинов**, «Татарстан» журналы вәкилләре.

Фото: Александр Ефремов

ШӘҺӘР КЕШЕЛӘРЕНӘ АВЫЛ ҖИТЕШМИ

ЮРИЙ РЫЖОВ, фермер:

– Шәһәр кешеләренә авыл җитешми. Кемдер зур энтузиазм белән Горки-Әмәт паркындагы уртак бакчада яшелчәләр үстерә, кемдер дачасында тавыклар үрчетә. Яшелчә белән җиләк-җимеш үстерергә теләгән, йорт хайваннары яраткан балаларга мин дә 30 гектар җир бирер идем. Хайваннар да бар: дорпер токымлы бәрәннәрдән алып, цесарка тавыкларына кадәр. Үзе өчен генә тырыша, дип уйламагыз. Аллага шөкер, Казанда өем бар, 19 сутый җирем, теплицаларым. Әнә күркәләр, казлар, тавыклар йомырка салып тора... Тормыш итәр өчен бөтен нәрсәм дә җитә.

Ә менә хутор – бөтенләй башка. Урман эчендәге гаҗәеп урын. Атлар, кәҗәләр, сарыклар рәхәтләнеп иркендә йөри... Кош асрар өчен генә дә 11 бүлем каралган... Йорт та бик зур, анда хәзер чын рус миче чыгарып ятабыз. Ипи салырга өйрәнергә була. Балалар шушында кайтып, авыл хезмәтенең асылына төшенсен, җирдә эшләүнең тәмен тойсын, хайваннарны карарга, үзләре өчен яшелчә-җимеш үстерергә өйрәнсен иде, дим. Организм ашаган ризыгыбыздан, эчкән суыбыздан тора бит. Бүген кибетләрдә тәкъдим ителгән продуктларның ниндилеген үзегез күрәсез. Аларда консервантлар, пестицидлар, төрледән-төрле катнашмалар күп. Сәламәтлеккә зыянлылары да шактый.

Мин инде олы кеше, шәхсән үземә әллә ни кирәк түгел, ә менә балаларның киләчәге өчен җан әрни. Аларны сәламәт туклану кагыйдәләренә беркем дә өйрәтми бит. Үз балаларын яңа савылган кәҗә сөте белән генә булса да тәэмин итә алмаучы ата-аналар, әби-бабайларны җинаятьче, дияр идем мин!

Балалар, күтәртелгән түтәл ясап, яшелчә утыртырга һәм, әйтик, кызыл миләш куаклары утыртып, бакча үстерә белергә тиештер. Җирләр инде куак утыртырлык итеп хәстәрләп куелган. Кош-корт карарга, хайваннар белән аралашырга, кәҗә сөте белән сыйланырга бик вакыт. Минем фикер аңлашыламы?

ПРОФЕССИОНАЛЬ ЭЗЛӘНҮЛӘР БАЛАЛАРГА СӘЛӘТЛӘРЕН АЧАРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ

АЙДАР ШӘМСЕТДИНОВ:

– Балаларыбызның киләчәген һәрчак кайгыртабыз. Мин, әлбәттә, аларга белем, тәрбияләү бирү белән шөгыльләнәм, шулай да авыл хезмәте миңа ят түгел. Үземнең бакча участогында яшелчә, җиләк-җимеш үстерергә яратам. Үзем үстергән 13–15 килограммлы карбызлар белән мактана алам. Статусларымны карап баручылар үз күзләре белән күреп беләләрдер. Лимонарийда әфлисун-лимоннар үстерәм. Хәзер дә әфлисун, мандариннар ботакларда эленеп тора, анар җимешләре өлгереп килә. Теплицада исә кыяр, помидорлар чәчәк атып утыра, салат өлгереп килә. Заанен токымлы өч кәҗәбез бар. Һәр иртәм сөт савудан башлана: балаларым җып-җылы кәҗә сөте эчә, шуңа күрә мин җинаятьчеләр рәтенә эләкми каламдыр (*елмая*). Авыл хуҗалыгы тәҗрибәсе туплана. Ике кызым белән улым да авыл хезмәте белән кызыксына: быел, 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, улым «Колос» агропредприятиесендә эшләп карады. Уңыш җыеп алуда катнашу аңа бик ошады, ай ярым шунда яшәп эшләде. Без аны атнага бер генә күрә идек. Кыскасы, егеткә авыл хуҗалыгында эшләрнең ничек барганын күрергә мөмкинлек тудыра алдым. Романтика гына түгел ул, кыр-басулардагы пычрак та, юеш ашлыкны төне буе күз йоммый киптерү дә, машиналарны кабул иткәндә керфек какмый кара төнгәчә тору да. Әнә шулай үз җилкәңдә бу авырлыкларны тоеп карау бик кирәк. Яшьләргә һөнәрне аңлы рәвештә сайларга булыша бу. Татарстанда кадрлар кытлыгы, кешеләрнең авыллардан китүе – зур проблема, авыл мәктәпләрендә укыган балаларны да бармак белән генә санарлык, шуңа да мин Юрий Павловичның идеясен хуплыйм. Сүз уңаеннан, улыбыз Тәтеш районының Жуково авылында эшләде. Хезмәт бригадалары оештырып, балаларны яшьли эшләргә өйрәтеп үстерү киләчәктә һөнәр сайларга зур этәргеч тә булыр иде.

«Адымнар»ның шәһәр читендә үз лагере булуын беләсез. Лагерьда яшь биологлар түгәрәге эшли. Түгәрәккә йөрүчеләр исәбен гел бер тирәдә тотарга тырышабыз. Безнең мәктәптә хәтта микроклонлаштыру лабораториясе дә бар. Мисал өчен, бәрәңгенең сәламәт күзәнәген алып үстереп карыйсың, соңыннан аны теплицада сыныйсың. Шулай итеп, вируслар белән зарарланмаган продукт аласың. Башка культураларны да сынап карап була – гортензиядән, бакча җиләгенә кадәр. Безнең лабораториядә күзәнәктән киткән җиләк минем бакчамда гөрләп үсеп утыра. Шулай итеп, кәҗә сөтендә генә тукталып калмыйбыз, безнең өчен Татарстанда карбыз, әфлисуннар үстерү дә бик кызыклы тема!

Айдар Шәмсетдинов, «Адымнар» полилингваль комплексы директоры

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫКНЫ ҺӘМ ТУКЛАНУ ЯГЫН КАЙГЫРТЫРГА КИРӘК

Гөлнара Галиева,
«Ритм» 187 нче күппрофильле лицей директоры

ГӨЛНАРА ГАЛИЕВА:

– Бүген минем өчен Айдар Илдарович ачыш булды. Мин дә эти-әниләремнең җинаятьче булмавына сөенеп утырдым: алар мине бала вакыттан ук кәҗә сөте эчертеп үстерде. Шуңа да мин бүген сезнең янга тартылганмындыр да инде (*елмая*).

Әлбәттә, килешәм, мин дә балаларыбызның сәламәт туклануы, сәламәт тормыш рәвеше алып баруы яклы. Әгәр Айдар Илдарович җәй көннәрендә безне дә үзләренең мәйданына чакыра ала икән, укучыларыбыз бу сынауларда рәхәтләнеп катнашыр иде. Безнең үзебезнең, мәсәлән, андый мөмкинлегебез юк. Юрий Павлович сүзләрен тыңлап утырганда, шуны уйладым әле: бәлки, бу безнең балалар өчен бик әйбәт булыр иде – табигать кочагы, хайваннар белән тактиль элемтә, хезмәткә өйрәнү һ.б. Ач кына булмыйк, калганына без бишкуллап риза. Бигрәк тә андый ачлык бөтенләй янамаган урында... Моны яхшылап уйларга кирәк: балаларның кайсы категориясен китерергә була, нинди шартлар булачак, ата-аналар белән ничек килешергә, балаларны ничек илтергә... Һәм, әлбәттә инде, иң мөһиме – куркынычсызлыкны һәм балаларның туклануын тәэмин итү сорауларын хәл итү.

АВЫЛ ТУРИЗМЫ БҮГЕН МОДАДА

РИНАТ РӘХМӘТУЛЛИН:

– Дөресен генә әйткәндә, гаҗәпләнеп тыңлап утырам әле – нәкъ менә кирәкле компаниягә эләктем, күптән эзләгән кешеләрне таптым, ахры. Файдалы продуктларны куллану өлкәсен үстерү – безнең хезмәтнең дә үсеш юнәлеше ул. Йогырт җитештерер өчен, без сатучылардан көненә 100–150 литр сөт алабыз. Һәм, беләсезме, андый кечкенә күләмне бирергә әзер кешеләр әз, алар өчен бу кызык түгел, вак. Шуңа без даими рәвештә чимал эзләргә, аның сыйфатын тикшереп торырга мәҗбүр.

Бирегә без, булган бар малыбызны сатып, Казахстаннан күченеп килдек. Сентябрь азагында төрле тәмнәр кушылган йогыртлар җитештерергә керештек: ярма, бал, тары, талкан, сырганак җиләге салып... Йогыртларыбызда кулланылган чималның дөрес шартларда һәм чиста туфракта нәкъ менә сезнең кебек энтузиастлар тарафыннан үстерелгән булуы безнең өчен бик мөһим.

ДИНАРА РӘХМӘТУЛЛИНА:

– Казахстанда яшәгәндә, җае туры килгән саен, ирем мине Казанга алып килергә тырышты (аның тамырлары Татарстаннан). Һәм мин бу шәһәргә гашыйк булдым. Әйе, Татарстанда әле эшебезне башлап кына җибәрдек, ләкин Казахстанда туклану продуктлары җитештерү буенча 10 еллык тәҗрибәбез бар. Анда, Уральскида да, безне балалар өчен сөт кухнясын җайга салырга өндәделәр, әмма инде планда Казан иде, без шуңа да яңа тармакка алынмадык.

РИНАТ РӘХМӘТУЛЛИН:

– Сезнең идея – бик яхшы, әмма без базар икътисады шартларында яшибез, шуңа боларның барысын да акчага әйләндереп карарга кирәк, дип уйлыйм. Ягъни туристларны җәлеп итәргә, аутентик татар көнкүреше шартларын тудырырга, бәлки, рус көнкүрешен дә өстәп җибәрергә... Мич – бик шәп! Авыл туризмы гаять кызык бит! Шулай бервакыт без, дуслар белән, Германиядә җиләк фермасына барып эләктек. Андагы гаҗәеп зур парковканы күреп шаккаттык... Ул туристларны төяп килгән автобуслар белән шыгрым тулы иде. Бөтен Европадан кешеләр ничек итеп җиләк үстергәннәрен карарга килә. Беренчедән, фермер акчасын экологик чиста продукты белән эшли, икенчедән, туризм аша. Әлеге дә баягы немец – дүртенче буын фермер: аның әтисе дә, бабасы да, бабасының әтисе дә җиләк үстергән. Һәм менә бүген ул нәсел бизнесына туризмны да өстәгән. Дөрес эшләгән, чөнки туризм белән берничә мәртәбә күбрәк акча эшләргә була.

Динара һәм Ринат Рәхмәтуллиннар,
«НатурПродукт» компаниясе хуҗалары

ҮРНӘК ФЕРМЕР ХУҖАЛЫГЫ МОДЕЛЕ

ИННАЗАР ХӨСӘЕНОВ:

– Минемчә, биредә, «Татарстан» журналы редакциясендә, безнең уникаль берләшмә төзелде дә инде. Эшкуарлар фикерен, мәгариф, белем бирү өлкәсендә эшләүчеләрнең фикерен ишеттек, фермер, журналистларныкын да тыңладык.

Миңа бу идея шул ягы белән дә кызыклы: фермер булгач, тот та хуҗалыгыңда әвәрә кил, акча эшлә, эшеңне киңәйт, тыныч кына яшә дә ят, югыйсә. Юк, бу гына аз, Юрий Павлович – тынгысыз кеше. Ул әле узган гасырның 60 нчы елларыннан бирле бизнес алып бару, нинди дә булса продукт җитештерү хакында гына түгел, куркынычсыз яшәүне тәэмин итә алырдай фикердәшләр төркеме туплау турында хыяллана. Бәлки монда яңгыраган идеядән фермерлар мәктәбе кебек кызыклы юнәлеш үсеп китәр – үзләрен эштә сынап карарга теләүчеләр табылыр. Монда студентлар да килеп кушыла ала – XXI гасыр бит, цифрлы заман, дистанцион белем алырга да бик мөмкин, ләкин гамәлдә эшләп карамый булмый. Юнәлешләр буенча, мәсәлән, шундый күзаллавым бар: кемнеңдер иртәсе нәкъ менә Айдар Илдаровичныкы кебек башлана – торып чыга да кәҗә сава... Кемдер куян ашата, кемдер – кош-кортларын, ә кемдәдер – мөгезле эре терлек... Белемнәрне өзлексез арттырырга була. Бу әле бер юнәлеш буенча эшли торган 30 гектарлы ферма гына. Ярар, авыл туризмын оештырып, коммерция ягын да кайгыртa алсын, ди. Ә без бүген биредә күпкә колачлырак, кешеләр үзләре дә өйрәнә һәм үсә, балаларын да хезмәткә җәлеп итә алырга сәләтле масштаблырак система турында сөйләшәбез. Балаларына һәм аларның киләчәгенә карата, кем әйтмешли, җинаять кылмаслык итеп эшләргә тиешле берләшмә турында. Әзер рецептлар юк һәм булмаячак, бер генә өлкәдә дә юк ул. Аны үзебезгә уйлап табарга кирәк. Һәм мәктәп балаларына кызыклы булырлык итеп уйлап табарга! Димәк, бу – блогосфера да, цифрлаштыру да, барлык заманча технологияләрне катнаштыру да дигән сүз. Бер үрнәк фермер хуҗалыгы моделен төзү. Уку-өйрәнү хуҗалыгын, кыскасы...

Инназар Хөсәенов, авыл хуҗалыгында консалтинг өлкәсендәге шәхси эшкуар

КӨЧЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРЕР ӨЧЕН

Әскәр Сабиров, «Татарстан» журналының шеф-редакторы

ӘСКӘР САБИРОВ:

– Мин бер нәрсәне аңларга телим: болар барысы да башка очраклардан нәрсә белән аерыла? Мәгънәсе нәрсәдә? Асылда, сез әйткән әйберләр күпмедер дәрәҗәдә совет заманында авыл мәктәпләрендә бар иде. Мәктәп яны бакчаларында эшләү дә – шуның бер үрнәге. Кәҗә дә савалар иде, алма да үстерделәр, кыяр да җыйдылар, бәрәңге чүбен дә утадылар... Бу яңалыклар барысы да күптән онытылган үткәнне кайтарырга омтылумы? Әллә гаилә фермасы юнәлешен үстерергә теләүме? Хәер, монысы да яңа түгел, Татарстанда гаилә фермалары җитәрлек. Ә бәлки, бу нindидер яңа экологик авыл төредер?

ИННАЗАР ХӨСӘЕНОВ:

– Бәлки, формасын инде процесс барышында хәл итәрбез? Монда иң мөһиме – идея, ә аны һичшиксез хупларга кирәк, дип уйлыйм. Балаларда бәләкәйдән туган җиргә мәхәббәт тәрбияләргә кирәк. Үзе эшләп карап, технологияләрне үзләштереп, барлык авырлыкларны, каршылыкларны җиңеп, бала инде, үсә төшкәч, нишләргә кирәген мөстәкыйль хәл итә алачак, шул ук вакытта аның өчен бу берләшмә ят булмаячак. Кызыксыну белдерүчеләрне бөтен дөньядан җыярга була, әлеге дә баягы җиләк үстерү серләре яки сәламәт бәрәңге кузәнәкләрен клонлаштыру тәҗрибәсен уртаклашыр өчен дә. Көчләрне берләштерергә, тармакны үстерергә, яңа өлкәләрне өйрәнергә, базарга эксклюзив, кабатланмас продукт чыгарырга. Өйрәнү ул үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күргәндә үтемле, шулай ук проблемаларны фәнгә таянып хәл итү юлларын да белә аласың. Ягъни берьюлы укыйсың да, фәнни эшчәнлек белән дә шөгыльләнәсең. Тәҗрибәләр уздырырга берни дә комачауламый бит.

Беренче этапта бары тик җәйге вакытны гына алырга мөмкин. Яңгырдан яшеренә торган урын булса, ашау-эчү тәэмин ителсә, бер дигән. Алга таба тиз корыла һәм аннан сүтеп алына торган тору урыннары хәстәрләргә мөмкин, гап-гадиләрен, әйтик, берничә кешелек палаткалар. Бу миллионнарга төшә торган чыгым түгел, глобаль финанслауны таләп итми. Әзер карар көтеп тормый ул, без монда нәкъ менә фикер туплап, берләшеп, ниятне тормышка ашыру юлларын табар өчен җыелдык.

ЮРИЙ РЫЖОВ:

– Ипи салырбыз, каз пешерербез, самовар куеп җибәрербез! Баштарак моны бик күп балалар өчен эшләп булмаячак, билгеле, әмма тора-бара эш җәелер, дип уйлыйм. Бар да булыр. Органик авыл хуҗалыгы – клондайк ул!

РИНАТ РӘХМӘТУЛЛИН:

– Чыннан да, әйдәгез, көчләрне бергә туплыйк. Беренче бурыч – балаларны өйрәтү. Авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүне, сыйфатлы туклану продуктларына өстенлек бирүне тормышыбызга кертү. Бу гади генә итеп әйткәндә. Авылда хәлләрнең нindилеген күреп торабыз. Яшьләр калага омтыла, шәһәрләр үскәннән-үсә, авыллар бушый...

КЕЧКЕНӘ АДЫМНАР ЯСАП, БУ ЯЗДАН УК БАШЛАРГА БУЛА

ЮРИЙ РЫЖОВ:

– Бер-ике генә сүз өстим әле. Минем фермага балалар килде, ә анда дорпер бәрәннәр утлап йөри. «Карагыз әле, нинди зур этләр!» – дип, бик гаҗәпләнде алар. Шәһәрләшүгә гади генә бер мисал бу. Моны кичекмәстән төзәтергә кирәк! Тулы бер буыннан колак какканчы! Шуңа күрә, кечкенә адымнар белән булса да, атлап китү зарур, минемчә. Шушы язда ук. Бүген экоавыл схемасын якынча күз алдына китердек. Андыйлар Россиядә бар, дисез, кайда алар? Татарстанда бар, дисез, алары кайсы районда? Бармак белән генә санарлык бит.

Органик авыл хуҗалыгы – без ирешергә теләгәннәрнең бер өлеше генә. Икенче максат – балаларны өйрәтү, аларны авыл хуҗалыгына җәлеп итү. Эшләгән эшләре белән горурланырлык итеп тәрбияләү. Телефонда утыру түгел, наркотиклар белән тилерү түгел, ә кулыңа тотып эш эшләү модада булсын! Балаларны кызыксындырырга кирәк бит. Ә ничек? Матур атлар белән, мәсәлән, йоннары көмешсыман ялтырап торган күркәләр белән, чуар цесаркалар белән, мөлаем бәрәннәр белән, тиктормас кәҗәләр белән... Болар барысы да – бар. Рәхим итегез!

БҮГЕН ТАТАРСТАНДА:

2 500 крестьян-фермерлык хуҗалыгы;

417 000 шәхси хуҗалык;

20 гә якын экохуҗалык бар.

СЕЗДӘН КИҢӘШЛӘР КӨТӘБЕЗ

Шулай итеп, түгәрәк өстәл нәтиҗәләре:

1. **Үз хутор хуҗалыгын Казан мәктәпләрендә укый торган балаларны җир эшенә һәм яшьләрне авыл хуҗалыгы нигезләренә өйрәтү өчен бирергә әзер булган фермерыбыз бар.**
2. **Мәктәп җитәкчеләре, табигый, кушылмаларсыз продуктлар җитештерүче шәхси эшкуарлар арасында фикердәшләребез бар.**
3. **Бик күп идеяләребез, шул исәптән авыл туризмы һәм аңа кешеләрне җәлеп итү ысуллары турында фикерләребез бар.**

Әмма безнең моны ничек итеп башкарып чыгарга дигән әзер рецептыбыз юк. Шуңа да без, ярдәм сорап, укучыларыбызга мөрәҗәгать итәбез – сезнең киңәшләр безгә бик кирәк, аларны **tatarstan@tatmedia.com** почтасына җибәрә аласыз. Көтеп калабыз!



ТОРМЫШЫГЫЗНЫ ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРТӘЧӘК ЙОГЫРТ

Башка илдән күченеп, өч ай эчендә җитештерү эшен җайга салу һәм Татарстан Рәисенә тәкъдим итәрлек продукт ясау – «Натурпродукт» брендына нигез салган Динара һәм Ринат Рәхмәтуллиннар мондый хыялны ничек чынбарлыкка әйләндереп булуы хакында сөйли.

ПАНДЕМИЯ – МӨМКИНЛЕК ТӘ УЛ

Ресторанның ябылуы, утыз хезмәткәрнең эшсез калуы – 2020 елда шәхси бизнеслары җимерелү чигенә җиткән Динара белән Ринат өчен бу эшкуарлык тарихы әнә шулай башлана. Пандемия башланганда, Казахстанның Уральск шәһәрендәге өч катлы премиум рестораннары бар куәтенә эшләп киткән, үз аудиториясен яулап өлгергән чак була. Әлеге проектны тормышка ашыру өчен ир белән хатын биш ел сарыф итә.

– Бинаны да, команданы да без бик җентекләп сайладык. Шуңа күрә ресторанны да, кешеләрне дә ташлап калдыра алмадык. Беренче адым ярымфабрикатлар цехы булды. Аннары сыр ясау заводы ачарга һәм өстәмә рәвештә йогыртлар җитештерергә тотындык. Һәм көтмәгәндә йогырт эше үргә китте! Иң популяр продуктка әйләнде, – дип сөйли Ринат Рәхмәтуллин.

Ир белән хатын, эш урыннарын саклап калып, яңа бизнес җәелдереп җибәрү генә түгел, пандемия белән көрәшкә дә өлеш кертә. Рәхмәтуллиннар үзләре җитештергән төп ризыклар – шах-пылау пирогы һәм пылау белән блокпостларны һәм карантин үзәкләрен тәэмин итә.

ЯХШЫ КӘЕФ ОЕТКЫСЫ

«Ризык дару булсын» – Гиппократның бу сүзләрен Ринат белән Динара үзләре өчен кагыйдәгә әйләндерә.

– Без ингредиентлар һәм технологияләр сайлауда бик таләпчән. Өч лабыз бар, җитештергән ризыкларыбызның барысын да беренче чиратта алар өчен әзерлибез. Ресторан белән дә шулай булды, «Натурпродукт» йогыртларын җитештерү эше дә шулай оештырылды. Казан агропаркында үтә күренмәле витриналар ясадык. Җитештерү процессы, чисталыкны саклау, төрү-тутыру – барысы да уч төбендәге кебек. Агропаркта эшләүче хезмәткәребез Мария безнең белән Казахстаннан ук килде. Бу эшне башлаганнан бирле, дүрт ел дәвамында ул безнең белән, һәм без аңа тулысынча ышанабыз, – ди Динара.

Йогырт җитештерүдә чисталык аеруча мөһим. Бөтен хикмәт – бифидобактерияләрдә. Ашкайнату системасына эләккәч, алар патоген микрофлораны кысрыклап чыгара. Бу процесслар кешенең кәефенә йогынты ясый. Иммунитет, ашкайнату, хәтта кәефебез дә күп очракта безнең организмга нинди микроорганизмнар эләгүенә бәйле.

СССР БАКТЕРИЯЛӘРЕ

Балалар, өлкәннәр, авырудан яки операциядән соң савыгып килүче кешеләр лакто- һәм бифидобактерияләргә аеруча мохтаҗ. Әмма бу оч-

Фото: Александр Ефремов, Рәхмәтуллиннар архивыннан. РЕКЛАМА

ракта җитештерү шартлары, санитар нормаларны үтәү бик мөһим, бу исә чималга да кагыла. Әгәр оеткыга яки продуктка чит флора эләгә икән, ул анда рәхәтләнеп үрчеп китәчәк. Моннан тыш, продуктның натураль, табигый булуы да әһәмиятле. «Натурпродукт» кебек синтетик өстәмәләрсез йогыртта файдалы бактерияләр ризыкны җитештергәннән соң нибары 7 көн генә яши. Аннары ул савыктыру үзлекләре булмаган эчетелгән сөт продукты гына булып кала.

Бактерияләр тиешле күләмдә саклансын өчен, «Натурпродукт» пыяла шешәләргә тутырыла.

– Советлар Союзының күп традицияләре сәламәтлекне күздә тота һәм файда да китерә иде. Мәсәлән, безнең оеткы – СССРда дәвалау рационнарына кертелгән «Наринэ» эчемлеге оеткысы аналогы диярлек. Ә шешәләрне без кире кабул итәбез һәм аларны кайтаручыларга ташлама да ясыйбыз. Безгә төргәкләрне-савытларны яңадан эшкәртү идеясе бик ошый, – ди Динара.

СИН ДӘ ТАТЫП КАРА

«Натурпродукт»ка («хәләл» сертификатына ия) нигез салучыларның тырышлыгын халык күрә. Ачылып, өч ай гына эшләүләренә карамастан, Рәхмәтуллиннарның даими сатып алучылары пәйда була. Декабрьдә алар җитештергән йогырт «Татарстанның ел бренды – 2024» премиясенең бер номинациясендә җиңә. Агропаркка килгәч, йогыртны республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов та татып карый. Сүз уңаеннан, агропаркка килүче һәр кеше йогыртны бушлай тәмләп карый ала.

– Әнием тумышы белән Татарстаннан, шуңа күрә без, Уральскидагы бизнесны сатып, бирегә күченергә карар кылдык. Кайбер кыенлыкларга карамастан, бу адым бик дөрес булды. Монда без хакимият тарафыннан да, эшкуарлар берлегеннән дә ярдәм күрдек. Бу кәефне күтәрә һәм эшкә рухландыра, – ди Ринат Рәхмәтуллин. – Моннан тыш, Татарстанда кулинария традицияләре үсеш алган, безгә бу якын. Мәсәлән, төрки кухняда талкан – эре итеп тарттырылган арпа яки бодай киң кулланыла. Бу эчемлекләргә һәм боткаларга борын-борыннан салына торган биоактив өстәмә кебек. Безнең ассортиментта да иң популярлар продуктның берсе – баллы-талканлы йогырт.

ФАЙДАНЫҢ ТӘМЕ ҺӘМ ИСЕ

«Натурпродукт» йогыртын ясау өчен, Рәхмәтуллиннар бер җитештерүчедән сөт сатып ала. Ә менә оеткы һәм өстәмәләрне элегә Казахстаннан китертергә туры килә, ләкин алар биредә җитештерүчеләрне эзләү эшен дә дәвам итә.

– Киләсе елда без Россия авыл хуҗалыгы министрлыгы грантына гариза бирергә уйлыйбыз. Татарстанда үзебезнең сөт фермасын ачарга телибез, – дип, хыяллары белән уртаклаша Ринат.

Эшкуарлар сыр ясау һәм сөт продуктларын эшкәртү тәҗрибәләре белән уртаклашырга әзер. Үзләре оештырган биш көнлек курсларда алар сөтне эшкәрткәннән соң калган коры калдыкның, аертылган, эшкәртелгән сөтнең бәясен арттырырга, файдалы итеп сатарга өйрәтәләр.

– Савып алганнан соң 10 минут үткәч сөт нинди була, аннан нинди ис килә, ике сәгатьтән, бер көннән соң нишли, сөт – каймакка, ә каймак майга ничек әверелә – без барысын да беләбез, – ди Динара. – Бу белемнәрне 10 ел буе тупладык һәм хәзер аны кешеләр файдасына кулланабыз. Татарстанда сыйфатлы продуктлардан файдалану культурасы яхшы үскән. Монда йогыртыбызны яратып ашаучылар табылыр, алар «Натурпродукт»ның һәр шешәсенә салынган тәм һәм кайгыртучанлыкны тояр, дип ышанабыз.

ТАТАРСТАН ЕЛНЫҢ 12 МИЗГЕЛЕ

22–24 октябрь БРИКС саммиты

Казанга **36 ил** вәкиле, дәүләт башлыклары дәрәҗәсендәге **24 делегация** килде. Саммитта **6 халыкара оешма** җитәкчеләре, шул исәптән БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш та катнашты.

12–23 июнь БРИКС Уеннары

Җиңү өчен **85 илдән 4500 дән артык** спортчы көрәште. Медаль зачётында беренче урынны Россия җыелма командасы алды, икенче урында – Белоруссия, өченче урында – КХР.

21 февраль – 3 март Киләчәк Уеннары

Физик ярышларны һәм киберспортны берләштергән диджитал концепциясендәге халыкара мультиспорт турниры ТР башкаласында **107 илдән 2000 нән артык** спортчыны кабул итте. Алар **21 инновацияле дисциплинада** көч сынашты.

---

28 сентябрь

China Eastern Airlines Кытай авиакомпаниясе Казан–Шанхай маршруты буенча беренче авиаюнәлешне ачты

20 ноябрь

Тулысынча үзебездә җыелган Ту-214 самолёты беренче очышын ясады

21 декабрь

Украина пилотсыз очкычлары Татарстан башкаласында торак йортларга һөҗүм итте

2024

12 август

Millennium clinic күппрофильле медицина комплексы эшли башлады

Ул елына **150 000 нән артык** пациент кабул итә, шулай ук ел саен **20 000 гә якын** операция ясый алачак. Юнәлешләрнең берсе – медицина туризмы.

4 июль

Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге мәйданчыгында

«Свияжск-Зернопродукт» ЖЧҖнең яңа элеватор комплексы эшли башлады

Комплекс авыл хуҗалыгы продукциясен саклау, чистарту, киптерү, күчерү һәм төяүне тәэмин итәчәк.

Саклау куәте – **112 000 тонна ашлык**.

3 июнь

«Росатом» дәүләт корпорациясе «Иннополис» мәгълүматлар эшкәртү үзәгенең беренче чиратын эшләтеп җибәрде

Яңа дата-үзәк мәгълүмат технологияләре һәм цифрлы икътисад үсешен тәэмин итә торган инфраструктураның төп элементы булачак. Үзәк икътисадның төрле тармакларына, шул исәптән дәүләт секторына, бизнес һәм фәнгә мәгълүматларны саклау һәм эшкәртү хезмәтләрен күрсәтәчәк.

---

12 декабрь

Казандагы Музыкальная урамыннан «Волга» М-7 трассасына кадәрге Горький шоссесын реконструкцияләү тәмамланды

Борылыш полосаларын, тоннель, эстакада, җир өсте һәм җир асты җәяүлеләр кичүләрен төзү алты полосалы юлда (**11,3 км**) светофорсыз хәрәкәтне тәэмин итә.

22 декабрь

Яр Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрен урап узу юлы

М-7 трассасындагы **81 км** озынлыктагы участок **10 күперне**, **5 транспорт чишелешен**, **11 юлүткәргечне** үз эченә ала. Әйләнеп узу юлына Кама аша **1 км 300 метр** озынлыктагы яңа күпер дә керә.

26 декабрь

«Алексеевск–Әлмәт» юлы кулланышка тапшырылды

145 км озынлыктагы заманча автобан Алексеевск, Чистай, Яңа Чишмә, Чирмешән, Әлмәт районнары аша уза. Бу Татарстанда **югары I А категориясендәге беренче юл**, транспортның тизлеге **сәгатенә 150 км га кадәр** җитә.

«ЕЛ ТАТАРЛАРЫ – 2024»: РӘХМӘТ РЕЙТИНГЫ

Татар халкы үсешенә кем зур өлеш кертте? 2024 елның кайсы проектлары һәм вакыйгалары истә калды? Ел азагында Казан Кремлендә «Миллиард.Татар» проектының «Ел татарлары» рейтингында җиңүчеләрне бүләкләделәр.

«Атаклы татарларны» бүләкләү тантанасын «Миллиард.Татар» инде өченче тапкыр үткәрә. «Әлеге мәгълүмат ресурсы хезмәтләре кайчакта күләгәдә кала торган, әмма милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүче кешеләрне күрсәтү максатында оештырылды, – дип аңлата проект җитәкчесе Арслан Минвәлиев. – «Ел татарлары» рейтингы мондый кешеләргә рәхмәт йөзеннән барлыкка килде».

«МИЛЛӘТНЕҢ СОЦИАЛЬ ХАЛӘТЕН БИЛГЕЛӘҮ»

Бу юлы чара Казан Кремленең Кабул итү урыннарында узды. Лекторий залы шыгрым тулы иде: кунаклар Татарстанның шәһәр һәм районнарыннан гына түгел, Мәскәүдән һәм илебезнең башка төбәкләреннән дә килгән. Чынлыкта залга бүген милләтнең йөзек кашын тәшкил итүчеләр җыелды: галимнәр, театр әһелләре, җырчылар һәм музыкантлар, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре. Финалга чыгучылар арасында – блогер, татар теле укытучысы һәм имам. Арслан Минвәлиев фикеренчә, чара, чынбарлыкны чагылдырып, үзенә күрә «милләтнең социаль халәтен билгеләүгә» әверелде.

СӘХИБГӘРӘЙ ИСЕМЕННӘН

ТР Фәннәр академиясе галимнәре белән бергә, «Ел татарлары» проекты быел Алтын Урда чорын тирәнтен өйрәнү белән шөгыльләнде. Һәм җиңүчеләргә тапшыру өчен дә гадәти булмаган бүләк – ышаныч язуы әзерләде. Мондый ярлык Сәхибгәрәй хан заманында кешегә идарәне тапшыру, махсус вәкаләтләр бирү символы буларак тапшырылган. Ул заманда ул муенга тагылган яки билдә йөртелгән.

ХӨРМӘТ БЕЛӘН ХӘТЕРЛӘП

Бүләкләү тантанасы алдыннан катнашучылар 2024 елда вафат булганнарны искә алдылар. Алар арасында – Россиянең һәм Та-

Рамил Гали фотолары

Экспертлар «Ел татарлары», дип, Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевне һәм җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗанованы атады.

«Шамил» мәчете имамы Мәхмүт Шәрәфетдинов «Татар өммәте герое – 2024» дип танылды.

тарстанның халык артисты Ринат Таҗетдинов, җырчы Зөлфия Камалова, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Фән Вәлиәхмәтов һ.б. бар.

ВАКЫЙГАЛАР, УҢЫШСЫЗЛЫКЛАР ҺӘМ ГЕРОЙЛАР

Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләрне (ә алар егермедән артык) ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева һәм «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы баш мөхәррире Ринат Билалов атады.

Октябрь аенда Татарстан башкаласында узган БРИКС саммиты бертавыштан **«Ел вакыйгасы»** дип танылды.

Казанда төзелергә тиешле Җәмигъ мәчетен **«Ел уңышсызлыгы»** дип атадылар, төзелеш башланмады.

«Елның төп мәдәни вакыйгасы» дип, «Печән базары» көннәрендә оештырылган театр-цирк тамашасы аталды.

Әлмәт театрының «Суд сәгате» спектакле **«Ел спектакле»** номинациясендә җиңде. Авторы – язучы Равил Сабырның эше шулай ук конкурс кысаларында билгеләп үтелде.

«Ел татар хатын-кызы» статусы бу юлы Әлмәт театры директоры Фәридә Исмәгыйлевага бирелде.

«Шамил» мәчете имамы Мәхмүт Шәрәфетдинов **«Татар өммәте герое – 2024»** дип танылды. Ул шулай ук 12 мең тавыш белән **«Ел татар ир-аты»** итеп сайланды.

«ЭКСПЕРТЛАР САЙЛАВЫ» ҺӘМ «РЕДАКЦИЯ САЙЛАВЫ»

Җиңүчеләр «Миллиард.Татар» социаль челтәрләрендә тавыш бирү юлы белән билгеләнде. Әмма ике номинациядә тавыш бирү үткәрелмәде. Бу - «Экспертлар сайлавы» һәм «Редакция сайлавы». Җиңүчеләрне ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов бүләкләде.

Экспертлар – мәдәният эшлеклеләре һәм җәмәгатьчеләр **«Ел татарлары»,** дип, Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевне һәм җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗанованы атады. «Миллиард.Татар» редакциясе исә төрле өлкәләр буенча ун җиңүчене сайлап алды. Алар арасында каллиграф Рамил Насыйбуллов, тарихчылар Искәндәр Гыйләҗев һәм Искәндәр Измайлов, ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Эльмира Галимова, Telegram мессенджерын тәрҗемә итүче Илгиз Җиһангиров һәм башкалар бар.

Хатын-кызлар арасында фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы Алинә Заһитова махсус призга лаек булды. Диплом аңа «Хранители времени» боз тамашасында катнашуы өчен тапшырылды. Узган ел Заһитова читтән торып «Ел татар хатын-кызы – 2023» статусына лаек булган иде.

Хатын-кызлар арасында фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы Алинә Заһитова махсус призга лаек булды.

ХӘЛӘЛ ФОРМАТТАГЫ ЕЛ БРЕНДЫ

Һәр ел азагында төрле өлкәләрдә һәм номинацияләрдә ирешелгән уңышларга йомгак ясау кабул ителгән. «Ел җитәкчесе», «Ел вакыйгасы», «Ел сайлавы», «Ел товары», «Ел предприятиесе»... Барлык бу җиңүләр артында үз эшен рейтингның югары ноктасына күтәргән кешеләр тора. Без иң яхшыларның исемнәрен ишетәбез, аларны алкышлыйбыз, алар белән горурланабыз һәм аларга охшарга омтылабыз.

Шундый йомгаклау чараларының берсе «Ел бренды» премиясен тапшыру булды. Конкурс инде икенче ел рәттән Татарстанда бренд-продюсер Альбина Курбатова тарафыннан үткәрелә.

БРЕНДТАН БРЕНДКА

Аның «шәхси бренд» сандыгында нинди генә казанышлар һәм җиңүләр юк! Ул үзе, «Татарстан Республикасында маркетинг һәм пиарны үстерүгә керткән өлеш өчен» номинациясендә җиңеп, «Россиянең бөек кешеләре» премиясе лауреаты булды. Моннан тыш, Альбина «Россиянең иң яхшы 100 эксперты» рейтингына керә...

Шул вакыттан бирле аның максаты – үз республикасында яңа нәрсәләрне башлап җибәрү, үстерү, чөнки Альбина Курбатова әле «Татарстан Республикасы экспертлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасының президенты да.

ХӘМЕРСЕЗ БРЕНДНЫ ҮСТЕРҮ

Быел конкурста медицина, матурлык һәм сәламәтлек, мәгариф, дизайн, фи-

Фото Альбина Курбатова архивыннан

Бренд года
Татарстана 2024

ДИПЛОМ

нанс, мәдәният һәм сәнгать, IT-технологияләр, маркетинг һәм PR, төзелеш, блогинг һәм башка өлкәләрдә эшчәнлек алып барган компанияләр, күренекле затлар, шәхси бренд вәкилләре катнашты. Татарстанда мондый чара беренче мәртәбә хәләл форматта узды.

– Әлбәттә, мондый бүләкләүләр банкет рәвешендә, спиртлы эчемлекләр белән уза иде, – дип аңлата Альбина. – Әмма шул рәвешле без конкурсант һәм экспертлар санын чикләвебезне аңладык. Өстәвенә, хәзер инде хәмерне хәмерсез эчемлекләргә алыштыру трендка әйләнде. Без аңардан башка да бәйрәм тойгысын, тантана рухын җуймадык, өстәвенә, безне мөселман җәмгатьчелеге дә хуплады. Ягъни хәләл форматы безгә максатчан аудиториянең яңа мөмкинлекләрен ачты. Киләсе елга «Ел бренды» премиясен тапшыру тантанасын тагын бераз үзгәртергә планлаштырабыз: рәсми өлеше концертлар залында узачак, анда күбрәк кешене сыйдырып булачак. Аннары катнашучылар өчен банкет оештырачакбыз.

КЕМНӘР ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ БИЛГЕЛИ?

– Премия турында башка төбәкләрдәге эшкуарлар да белсен иде, дип хыялланам. Чөнки безнең жюри бик җитди һәм абруйлы. Аның составында ТР Экспертлар берлеге Советы һәм Россия маркетологлар гильдиясе әгъзалары бар, араларында – әйдәп баручы реклама агентлыклары вәкилләре, уңышка ирешкән эшкуарлар, төрле өлкәләрдә эшләүче экспертлар. Икътисад фәннәре докторы, КФУ профессоры, маркетинг кафедрасы мөдире, «НейроЛаб» нейромаркетинг лабораториясе җитәкчесе Наталья Каленская. ТР Экспертлар берлегенең мактаулы әгъзасы Елена Зубарева. ТР Иҗтимагый палатасының финанс мәсьәләләре эксперты, ТР Цифрлы үсеш министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы Фәнис Хөсәенов. Топ-менеджерлар һәм бизнес милекчеләренең финанс киңәшчесе, «Финанс планлаштыру белгечләренең милли ассоциациясе» Үзкөйләнүле оешмасының аккредитацияләнгән катнашучысы Светлана Тарасова. ТР Экспертлар берлеге рәисе, Халыкара сертификацияләнгән бизнес-консультант һәм стратег, компанияләрнең беренче затлары һәм дәүләт эшлеклеләренең PR-киңәшчесе Фирия Галиева. Алар брендның танылуын гына түгел, тәкъдим ителгән товар һәм хезмәтләрнең сыйфатын, элементләрнең нәтиҗәлелеген, эшлекле абруен, шулай ук тармак үсешенә керткән өлешен дә бәяли.

ЭМИЗ гастромәйданы – **традицияләрне саклыйбыз һәм мәдәниятләрне берләштерәбез**

ЭМИЗ

Банкетлар Китерү Кейтеринг

8 (843) 245 00 55 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Сафиуллин ур., 29

ЭМИЗ: йөземнең бар көче һәм файдасы – һәр йотымда

Премиаль сыйфат һәм кабатланмас тәм

ЛАУРЕАТ 100 ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ 2023 КОНКУРСА

2023 ЛУЧШИЕ ТОВАРЫ И УСЛУГИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

emiz.ru

8 800 444 09 37

РЕКЛАМА

«РОССИЯДӘ ЯШӘҮЧЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ЯУЛЫКЛАРЫН ЭШЛИ БАШЛАДЫК»

Сөмбел Могыйнова

Әле ун ел элек кенә милли бизәкле сумка, яулык, бизәнү әйберләрен күргәч аһ итә идек, чөнки безнең өчен бик тансык иде алар. Бүген хәл тамырдан үзгәрде: милли бизәкле күлмәк, свитшотлар, алъяпкыч, кыскасы, җаның ни тели, шул бар. Әйе, бу юнәлештә хәтта җитештерүчеләр арасында көндәшлек тә барлыкка килде. Мондый шартларда үз сатып алучыңны ничек табарга? Алай гына да түгел, ни рәвешле алга барырга? Шул турыда Tatarscarf брендына нигез салучы һәм аны уңышлы үстерүче ханым – Елена Владимировна Габдрахманова белән сөйләштек.

– Елена Владимировна, Tatarscarf бренды 2019 елда барлыкка килде. Биш елга нәтиҗә ясасак, нинди уңышларыгыз бар?

– 2024 елның 22 маенда биш елга нәтиҗә ясадык: зур бәйрәм оештырдык. Рәсми рәвештә 2019 елның 22 апрелендә теркәлдек. Нәрсә дип әйтим? Биш ел элек эшне кырык яулыктан башладык. Бертөрле генә бизәк иде. Шул кырык яулыкны бер чарада чират торып сатып алып бетерделәр. Нәкъ менә шунда үзебезнең дөрес юлда икәнлегебезне аңладык.

Эшли башлаганда максат татар мәдәниятен халыкка таныту иде. Ихластан әйтәм. Сәүдә итү уйда да юк иде. Әйтәм бит, кызык өчен, тәҗрибә өчен генә сатып карарга булдык. Нәтиҗәдә, бүген милли яулыклар җитештерү буенча иң зур һәм иң беренче бренд булып танылдык. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән, әлбәттә. Биш вакыт намазда мин, безнең – хәләл бизнес.

– Яулыкларны хәләл дә җитештереп буламы?

– Була. Хәләл ул, димәк, барысы да гадел дигән сүз. Без ялган юл белән сәүдә итмибез. Станок бит. Кайчакта яулык, шарфларда хилафлыклар киткән була. Кайчакта рәсеме дөрес чыкмый яки буявы башка төрлерәк ята. Андый чакта яулыкларның бәясен төшереп, сатып алучыны алдан кисәтәбез. Яки брак булган яулык, шарфлардан резинка, башка әйберләр ясыйбыз.

– Милли бизәкләрне үзегез дә уйлап табасыз. Аннан соң сез аларны берәр белгеч белән килештерәсезме?

– Белгечлегем буенча мин рәсем һәм сызым укытучысы, Евразия дизайнерлар берлеге, БДБ илләре рәссамнарының һөнәри берлеге, Мөселман дизайнерлар берлеге әгъзасы. Күп кенә дизайнер, рәссамнарны өйрәтәм. Татар яулыклары турында сөйләгәндә, иң беренче шуны әйтим: милли костюмнарны өйрәнә башлагач, татар хатын-кызларының үзләренең яулыклары булмаганын аңладык. Әйе, алар яулык бәйләгән, ләкин ул милли бизәкле булмаган. Мисал өчен кызыл француз яулыклары, Павловопосад бизәкле яулыклар, Оренбург шәлләре бар... Бер генә рәсми чыганакта да татар милли яулыкларын күрмәдек. Аның сәбәбе бик гади – татарлар милли бизәкле яулыкны бастыра алмаган, техник яктан мөмкинлекләр булмаган. Менә шул гына. Әйе, алар милли бизәкләр чиккән, тик машинада бастырмаганнар. Менә шуны күздә тотып, без станок ярдәмендә милли бизәкле яулыклар җитештерә башладык. Нинди бай тарихлы, мәдәниятле халыкның үзенең яулыгы булырга тиеш бит! Димәк, аны иҗат итәргә вакыт җиткән! Максатыбызга ирештек тә: бүген һәр татар хатын-кызының шкафында милли бизәкле яулык бар, дип уйлыйм.

– Сезнең көндәшләр бармы?

– Хәзер күбәйде. Иң шаккатыргычы – алар безнең бизәкләрне урлап та бастыралар. Ләкин бу безне куркытмый. Иң мөһиме – алар безнең миссияне, татар милли яулыгын таныту, үстерү юлын дәвам итәләр. Кайбер очракта хәтта алар эшләгән яулыкны да безнеке дип уйлыйлар. Әйткәнемчә, бу өлкәгә нигез салучылар – без, һәм безнең үз юлыбыз бар.

Эшли башлаган көннән үк үзебезнең Tatarscarf брендын рәсми рәвештә теркәдек. Бүген инде тагын берничә брендыбыз бар.

– Киләчәккә планнар?

– Барысын да сөйләп бетереп булмый. Без гел алга барабыз. Кибетебез булачак, Аллаһ боерса. Яулык, шарфлардан тыш, чигүле әйберләр, хатын-кызлар күлмәкләре, блузалар, костюмнар тегә башладык. Ир-ат костюмнары текмибез. Россиядә яшәүче халыкларның яулыкларын эшли башладык. Кыскасы, гел шушы юнәлештә үсәбез.

Фото: tatarscarf.ru; Елена Габдрахманова архивыннан. РЕКЛАМА

Миллилек һәрвакыт синең белән!
Tatarscarf бренды җитештергән яулык, шарфларны моннан сатып алып була:
Казан ш.,
Каюм Насыйри ур., 7
(ориентир – сувенирлар ишегалды)
Тел. +7 (980) 915-37-16
WB

100 000 СУМ

һәм башка бүләкләр

Бүләкләрне уйнату 2025 елның 6 февралендә узачак.

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз.

Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 26.01.2025 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин

ТАТ МЕДИА

РЕКЛАМА

акыллы
гамәлләр
игелекле
эшләр
мәңгелек
кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Замана табибы **нинди** була

Африка черкиен **ничек** терелтергә

Адвокаттан **ничек** биолокация белгеченә әйләнергә

ЗАМАНА ТАБИБЫ: «ӨЙГӘ КАЙТКАЧ ТА, ЭШЕҢ СИНЕ ҖИБӘРМИ...»

Руфия Фазылова

Редакциябезгә кояш булып балкып килеп керде ул. Ниндидер җылы бер нур бөркелде. Югыйсә ак халаттан да түгел, әмма шушы гүзәл туташның нәкъ менә табиб икәнлеге йөзенә язылган кебек иде.

– Алинә Хәсәншина мин булам, – дип елмайды.

Алинә Хәсәншина – гастроэнтеролог. Республика клиник хастаханәсендә дәваланучы авыруларга дәва белән бергә йөрәк җылысын да бирә ул.

Яшь табиблар беренче тәҗрибәне ничек ала? Гастроэнтерологиягә кайсы авырулар карый? Аларны ачыклау, дәвалау юллары нинди? Унбиш еллык тәҗрибәсе булган табиб белән әнә шулар турында сөйләштек.

– Алинә Йосыфовна, гастроэнтерологка күбрәк нинди проблема белән мөрәҗәгать итәләр?

– Гастроэнтерологка кеше күбрәк эче авыртып килә. Әгәр кеше эч кибү, эч күбү, эче китү белән интегә икән, ул һичшиксез табибка күренергә тиеш. Сәбәпсез ябыгу яки симерү дә, сару кайнау да гастроэнтерологка мөрәҗәгать итү өчен этәргеч булырга тиеш. Гомумән, организмдагы һәр үзгәреш кешене сагайтырга тиеш.

– Ләкин күпләр, эч авыртса, башта хирургка бара...

– Һәм дөрес эшли. Иң беренче чиратта, хирургия патологиясе булмавына инанырга кирәк. Үт куыгында таш, сукыр эчәге – болар иң еш очрый торган авырулар. Аларны хирург карап ачыклый ала. Нигездә, гастроэнтерологка хроник авырулар белән баралар.

Фотолар: Александр Ефремов; Алинә Хәсәншинаның шәхси архивыннан

– Бүген кешеләр, бигрәк тә яшьләр, туклануга зур игътибар бирә. Шуңа күрә нутрициологлар да гөмбәләр кебек үрчеп тора. Арада медицинага бер катнашы булмаган кешеләр дә очрый. Аларга мөнәсәбәтегез? Онлайн курслар тәмамлаган бу «табиблар» киресенчә сәламәтлегебезгә зыян салмыймы?

– Безнең заман шулкадәр тиз үзгәрә: тормышыбызга яңалыклар бер-бер артлы кереп кенә тора. Бу медицинага гына кагылмый, мәдәният, сәнәгать өлкәсе дә бик зур тизлек белән алга бара. Кешенең яшәү рәвеше, мохите, акылы да үзгә бүген. Безнең хәзер матур һәм яшь булып каласыбыз килә. Тик шунысы кызык: күпләр ниндидер могҗиза көтә. Бер генә капсула кабып, яшәреп китәселәре килә. Нутрициологлар бу әйберне шәйләп алды, медицина белеме булмаган кешеләр, өч айлык курслар узып, безне дөрес ашау юлына бастыру белән шөгыльләнә башлады. Тик шуны аңларга кирәк: нутрициологлар дәваламый, алар белгеч түгел. Бу төр белгечләрдә табиб сертификаты булу да мәҗбүри түгел, закон моны рөхсәт итә.

Дөресен генә әйткәндә, мин мондый белгечләргә каршы. Ничек инде кичә инженер булган кеше бүген безнең сәламәтлегебезгә ниндидер төзәтмә кертә, аны җайлый ала? Ул кеше организмының төзелешен өйрәнмәгән, матдәләр алмашын белми. Ләкин алар шундый ышандырырлык итеп сөйли, өмет уята. Нутрициологлар күбрәк кеше психологиясе белән эшли. Иң кызыгы – кемгәдер бу булыша да. Һәрхәлдә, кыска вакытка гына булса да. Кешене бит өмет яшәтә. Тик гафу итсеннәр, шулай да мин үз сәламәтлегемне нутрициологларга ышанып тапшырмас идем.

– Әле бит диетологлар да бар. Аларга да сертификатсыз эшләргә мөмкинме?

– Диетологларның медицина белеме булырга тиеш, шуннан соң гына алар кешеләрне дәвалый ала.

– Тагын бер мода: «бушану» көннәре оештыру яки бөтенләй ач тору. Шул рәвешле кешеләр үзләрен сәламәтләндерәбез дип саный. «Безнең әби-бабайлар ачлык, сугыш елларында атналар буе ашамаган. Нәтиҗәдә, сәламәт булган, йөзгә кадәр яшәгән», – дип аңлаталар. Сез мондый тәҗрибәгә ничек карыйсыз?

– Монда төптән уйлап җавап бирергә кирәк. Әйе, безнең әби-бабайлар ач торган, бик күп михнәт күргән. Һәм шуңа карамастан, 80–90 яшькә кадәр яшәгән. Бу урында зур итеп «кайберләре» дияр идем. Андый кешеләр табигый сайланыштан калган: йөзнең, меңнең берсе... Иң сәламәтләре генә шундый озын гомерле булган. Ә бит без беләбез: исән калучыларга караганда, үлүчеләр берничә тапкырга күбрәк. Халык төрле чирләрдән, ачлыктан кырылган. Шуңа күрә ач торып сәламәтлек яхшыра, дигән фикер белән һич килешмим.

Әйе, интервал ач торулар бүгенге көндә популяр. Интернетны ачсаң, нинди генә ысулларына юлыкмыйсың. Сигез сәгать, унике сәгать ач торырга да киңәш итәләр. Әлбәттә, ул кемгәдер ярдәм дә итәргә мөмкин. Әмма мондый ач торулар туклану законнарына туры килми. Бу барыбер организмны ниндидер стресска кертү була. Шуның өчен медицина фәне мондый алымнарны киңәш итми.

Сәламәт туклану нигезләре бар: ягъни ул көнгә 4–5 тапкыр аз-азлап ашау. Һәм эчүгә игътибарлы булырга кирәк: кеше үз авырлыгын 30 миллилитрга тапкырлап, шул күләмдә су эчәргә тиеш. Бу аның нормасы була. Монда фәкать чиста су турында сүз бара, чәй, кофелар керми.

– Рәсми мәгълүматларга караганда, 1991 елдан 2021 елга кадәр ашказаны-эчәк авырулары өч тапкырга арткан. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Сәбәбе бик гади – тормышыбыз яхшырды, нәтиҗәдә, ашау дөрес түгел. Кибет киштәләренә карасак, анда нинди генә ризык юк. Артык күп яки файдасыз ризык ашап, ашказанына зыян салабыз. Икенче сәбәп – физик активлык кимеде. Безнең хәзер барысы да автоматлашкан: кер юганда да, идән юганда да төймәгә генә басабыз. Эшкә машинада барабыз, кайтабыз... Болар барысы да сәламәтлекнең какшавына китерә.

– 50–60 яшьтән өлкәнрәк кешеләргә бер тапкыр булса да колоноскопия ясатырга кирәк, диләр. Купләрне куркыта торган процедура. Чыннан да, моны бөтен кешегә дә эшләргә кирәкме? Әллә инде эчәкләр белән проблема булмаса, ясамасаң да ярыймы?

– Колоноскопия ул эчәклектә булган начар чирләрне иртә стадиядә ачыклый. Сүз күбрәк онкология авырулары турында бара. Колоноскопия вакытында табиб, туры эчәклектән кереп, юан эчәктән нечкә эчәккә кадәр егерме сантиметр җирне күрә. Экранда полиплар яисә яңа барлыкка килгән ниндидер башка үзгәрешләр – барысы да ачык итеп күрсәтелә.

Мондый тикшеренүне илле яшьтән узган кешеләргә ел саен ясатырга киңәш итәбез. Әлбәттә, бу җиңел процедура түгел. Ләкин аны хәзер җиңелчә наркоз белән дә ясатырга мөмкин. Бу вакытта кеше йоклый һәм бер авыртуны да тоймый. Чынлап та, авыртуга бик сизгер кешеләр була. Бу организмга бәйле.

Колоноскопия буенча яшь чикләве юк, 90 яшьлекләр дә узарга мөмкин. Кайбер вакытта шушы ысулны кулланып, елына өчәр тапкыр да тикшеренү узучылар да бар. Барысы да авыруның хәленә карый, дәвалау ысулларыннан тора.

Гаилә бергә җыелганда.

– Эчәклектәге ниндидер проблеманы вакытында күреп алу өчен, нинди анализлар тапшырырга кирәк, әйтик, сәламәт кешеләргә?

– Әгәр кешенең эче авыртса, иң беренче чиратта, гомуми кан анализы бирергә кирәк. Гастроэнтерологлар башта гемоглобин, лейкоцит, тромбоцитларга игътибар итә. Шуннан инде табиб ялкынсынуның бармы-юкмы икәнлеген ачыклый.

Эчәклекне тикшерү өчен иң мөһиме – тизәк анализын тапшыру. Бу эчәклектәге кан эзен ачыклар өчен кирәк. Икенче төрле ул скрининг-метод дип атала. Тизәктә кан эзләре табылган очракта табиб авыруны колоноскопиягә җибәрә. Бу төр тикшерү диспансеризация программасына да кергән. Унсигез яшьтән утыз тугыз яшькә кадәргеләр – өч елга бер, кырыктан кырык тугыз яшькә кадәргеләр – ел саен, кырык тугыз яшьтән соң ике елга бер мәртәбә тизәк анализы тапшырырга тиеш. Нәкъ менә кырык яшьтән соң мондый авыруларның килеп чыгу проценты үскәнгә, ел саен тапшырып торырга кирәк.

– Алинә Йосыфовна, тагын бер тема турында сөйләшәсе килә... Бүген яшь табиблар зарлана. Чынлап та, вазыйфалары җаваплы, кәгазь эше күп, хезмәт хакы да әллә ни зур түгел. Сезнең дә андый чаклар буламы?

– Ни өчен яшь табиблар зарлана соң? Кичәге мәктәп укучысы медицина университетына ниндидер бер иллюзия белән килә. Кинолардагыча ак халат кына киеп йөри, барысы да сине хөрмәт итә... Инде укырга кереп, беренче тапкыр хастаханәгә баргач, чын тормыш белән очрашасың. Аннан соң, медицина университетында укырга да бик авыр. Яхшы, сигез ел баш күтәрми белем алдың. Ниһаять, кулда диплом! Шуннан эшкә урнаштың һәм... башлана. Көнгә ничә авыруны карарга, диагноз куярга, шуның өстенә – кәгазь боткасы. Өйгә кайткач та эшең сине җибәрми, уйлар гел шул тирәдә бөтерелә. Менә шулчак яшь табибның хыял-максатлары чәлпәрәмә килергә мөмкин. Һәм ул башка өлкәгә китәргә карар кыла. Мисал өчен, группадашларым арасында да күбесе медицина юлыннан китмәде. Яшермим, безнең һөнәр авыр һәм җаваплы,

гел психоэмоциональ киеренкелектә яшисең. Ләкин син һөнәреңне ихластан ярата-сың икән, авырлыкларына түзәсең. Кешедән рәхмәт ишетү сине канатландыра.

Мин – стационарда эшләүче табиб. Үземнең карамактагы авыру реанимациядә ятканда, эшкә җиденче яртыга ук барам. Көн саен кичке биштән дә иртә китү юк. Әле өйгә кайткач та эзләнәсең, теге яки бу диагноз турында күбрәк өйрәнәсең. Медицина бик тиз алга бара, кичә өйрәнгән дәвалау ысулы иртәгә искерә. Шуның өчен гел үзеңне камилләштерергә, үстерергә кирәк. Республика клиник хастаханәсендә иң авыр пациентлар ята. Аларны дәвалау өчен чынлап та белем, тәҗрибә сорала.

– Сез бит авыл хастаханәсендә эшләгән табибә дә. Авыл җирендә эшләү җиңелрәк дип буламы? Гомумән, алай чагыштырырга ярыймы?

– Университетны тәмамлагач, биш ел Саба районының Шәмәрдән бистәсендә участок терапевты булып эшләдем. «Авыл табибы» программасы кысаларында килешү төзегән идем. Анда терапевт булып эшләү миңа бик зур тәҗрибә бирде.

– Шулай да яңадан башкалага килгәнсез...

– Дөресен генә әйткәндә, авылга кайтканда ук, яңадан Казанга килү нияте белән яшәдем. Мин аны элек тә аңлый идем, хәзер дә: шәһәр табибына профессиональ яктан үсү өчен мөмкинлекләр күбрәк. Бигрәк тә – безнең хастаханәдә. Республика клиник хастаханәсе Россиядә иң яхшылар рәтендә бит. Аннан соң, гастроэнтеорология өлкәсендә юл күрсәтүче укытучым да үзебезнең бүлек җитәкчесе Әлфия Харис кызы Одинцова булды. Ул – Россиянең, Татарстанның атказанган табибы. Олы йөрәкле, тәҗрибәле белгеч. Аның кул астында эшләү – үзе бер бәхет.

– Табиб булу балачак хыялы идеме?

– Теләче районының Урта Мишә авылыннан мин. Укытучылар гаиләсендә үстем. Әтием – мәктәп директоры, әнием рус теле укытучысы иде. Тик беркайчан да укытучы буласым килмәде, чөнки мин бу һөнәрнең бөтен нечкәлекләрен күреп үстем. Урта сыйныфларда журналист һөнәрен үзләштерәсем килде, Екатерина Андреева кебек телевизордан сөйләргә хыялландым. Мәктәптә укыганда, мәкаләләр дә яздым. Тик... югары сыйныфка җиткәч, табиб һөнәре кызыграк тоела башлады. Табиб ничектер мәрхәмәтле, абруйлы һөнәр кебек тоелды. Химия, биология фәннәрен ярата идем. Унынчы һәм унберенче сыйныфларда ныклап торып шул юнәлешне өйрәндем.

Әлбәттә, медицина университетында уку җиңел булмады. Бигрәк тә беренче, икенче курсларда, без бит авылда төп фәннәрне татарча укыдык. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган бала буларак, тырышлык канга сеңгән. Шөкер, университетта сер бирмәдем.

«Тырышлык канга сеңгән», – ди Алинә Хәсәншина.

– Гастроэнтеролог буларак киңәшләрегез? Ашказаны-эчәктә проблемалар булмасын өчен, нәрсә эшләргә, ничек тукланырга кирәк?

– Эшне диспансеризациядән башларга киңәш итәр идем. Әйе, бу хакта күп сөйлиләр. Әмма ышаныгыз, күп авырулар нәкъ шундый профилактик тикшеренүләр вакытында ачыклана.

Ашказаны-эчәк белән проблемалар булмасын өчен, беренче чиратта, дөрес туклану режимы булдырырга кирәк. Бу дөрес продуктлар белән туклану дигән сүз: аксымнар, углеводлар, майлар һәм микроэлементлар, витаминнар булган ризыкларны куллану. Кеше көн дәвамында дүрт-биш мәртәбә ашарга тиеш. Ач тору вакыты өч сәгатьтән дә артмасын. Һәм йокларга ике сәгать кала ашамаска киңәш ителә. Икенчесе – физик күнегүләр ясау, саф һавада йөрү, физкультура белән шөгыльләнү. Өченчесе – стресска каршы торучанлыкны арттыру, ягъни үзеңнең күңел халәтеңне һәрвакыт контрольдә тоту, кәефсезләнергә юл куймау, позитив рухта яшәү.

Организмыгызда ниндидер проблема, үзгәрешләр сизәсез икән, кичекмәстән табибка барырга кирәк. Интернеттан карап, үзеңә диагноз кую, үзлектән дәвалану белән шөгыльләнергә ярамый гына түгел, куркыныч та!

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность

Реклама 16+

Фото «Татарстан» журналы архивыннан фото

«Татарстан» журналының махсус проекты

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

Казан университетына – 220 ел!

Әлеге вакыт эчендә биредә миллионлаган студент белем алган. Кемнәрдер үз өлкәләрендә танылган белгеч булып җитешкән, исемнәре бөтен дөньяга танылганнары да бар араларында. Һәр факультет, һәр белгечлек юнәлеше үзенең шундый йолдызлары белән мактана, горурлана ала. Күпчелеге юбиляр университетны тәмамлаучылардан торган «Татарстан» редакциясе дә «КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР» проектын эшли.

Ел буена без сезне, кадерле укучыларыбыз, иң кызыклы шәхесләр белән таныштырып барырга тырышырбыз. Алар укыган елларда университет нинди булган, биредә тупланган белем тормышларында, эшләрендә үз урыннарын табарга ничек ярдәм иткән – барысын да беләчәкбез. Аларга (безгә дә) дөрес юл күрсәткән мөгаллимнәребезне дә җылы сүз белән искә алырбыз. Бераз сагышланырбыз да. Казан университеты – бик күп татарстанлы өчен альма-матер бит. Татарстанлылар өчен генәме соң?! Россиянең һәр гаиләсендә һичшиксез Казан университетын тәмамлаган кеше табылачак!

Бу турыда «Татарстан» журналының 11 нче һәм 12 нче санында да (2024 ел) укый аласыз.



Казан дәүләт университетының умырткасызлар зоологиясе кафедрасы студенты, 1990 нчы еллар азагы.

«Постгеном–2024» конференциясендә, Мәскәү.

Фотолар Олег Гусев архивыннан

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР
ОЛЕГ ГУСЕВ

Евгения Чеснокова

Шулай бервакыт Россия һәм Япония галимнәреннән торган халыкара фәнни төркем галәмгә озынборын личинкасын очырып җибәрә. Без белә торган гадәтиен түгел, ә Африка черкиен. Һәм хәтта галәмгә генә дә түгел, ә МКСның тышкы сүрүенә. Ә анда – экстремаль температура, космик радиация һәм тормышның тагын башка төрле «шатлыклары». Личинка үзе дә сәяхәткә болай гына чыгып китми, тулаем дегидрацияләнгән (ягъни сусызландырылган) халәттә. Ә иң шаккаткыч хәл – Җиргә әйләнеп кайтканнан соң, суга урнаштыргач, ул... терелә!

Бу эре астробиологик проектта катнашучыларның берсе – Казан дәүләт университетын тәмамлаган, бүген Токионың Джунтендо университетында медицина факультеты профессоры, КФУның «Регулятор геномика» фәнни үзәге җитәкчесе, Уфа фәнни үзәгенең геном һәм постгеном технологияләре буенча мегагрант җитәкчесе Олег Гусев.

ГАЛӘМДӘ – ЯТЛАР?

– БЕРВАКЫТ, – дип искә ала Олег, – минем укытучым – профессор Такаши Окуда бары тик чын мәгънәсендә әһәмияткә ия эшләр белән генә шөгыльләнергә кирәк, диде. Әгәр хайваннарны күзәтергә, өйрәнергә яратасың икән (ә мин бик ярата идем), димәк, бик үзенчәлекле төрләрне өйрәнергә кирәк – нинди дә булса өлкәдә чын чемпионнарны. «Карале, – диде ул миңа, – менә черки бар, үтереп булмый торган җан иясе, ул булдыра алганны башка бернәрсә дә булдыра алмый». Шулай итеп мин Африка черкиен өйрәнергә керештем. Ул хәтта ачык космоста исән калырга сәләтле булып чыкты.

Без хәзер экстремаль мөмкинлекләргә ия башка төрләрне дә өйрәнәбез. Мисал өчен, зур булмаган кысласыманнар, калкан кыслаларны. Алар күкәйләрен саклагыч тышчага төреп сала, бу тышча корылыктан да, тагын бик күптөрле хәвефле һава шартларыннан да саклый. Без аларның берничә дистә мең күкәйләрен ачык галәмгә очырдык. Күптән түгел генә «космонавтлар» кире әйләнеп кайтты, баксаң, яшәргә сәләтләре хәтта Африка черкиенекеннән дә яхшырак икән. Космос вакуумында алар үзләрен гаять уңайлы хис итә – температура алышынуына, космик радиациягә карамастан.

Әлеге футуристик проект асылда фән үсеше өчен искиткеч зур әһәмияткә ия. Хәзерге вакытта кулыбызда бик зур күләмдәге биоматериал запасы бар. Без аны генетика күзлегеннән тикшерә алабыз: аерым организмнарга нинди механизмнар сусызландырылган хәлдә дә планетаара пространствода исән калырга мөмкинлек бирә? Өстәвенә, бу – тормышның башка планетадан «китерелгән» булуы хакындагы гипотезаны сынар өчен дә менә дигән ысул.

САМУРАЙ ЮЛЫ

БЕРВАКЫТ әле мәктәп укучысы Олег Гусев туристлар төркеме белән Түбән Иделгә походка бара. Походны Олегның этисе – туризм буенча спорт мастеры, Казан университеты доценты җитәкли. Әлеге сәфәрдән Олег үз-үзләрен тотышы белән шаккатырган бик күптөрле бөҗәкләр табып кайта. Шуннан соң ул зоолог булырга дигән катгый карарга килә.

Аңа кадәр ул әле этисе кебек үк астрофизик булам дип хыяллана. Ахыр чиктә, КДУның биология факультетына укырга керә, умырткасызлар зоологиясе кафедрасы студенты булып китә.

Үзенең фән юлын Олег Гусев менә шушындый, беренче карашка, иррациональ, интуитив рәвештә кабул ителгән карарлардан торган, әмма барыбер уңышка китергән адымнар чылбыры итеп күрә.

Чираттагы сәер адымы Төньяктагы Ак диңгезгә практикага китү була. Шуннан соң инде ул диңгез биологиясе белән шөгыльләнергә ниятли. Казанда – диңгез биологиясе, диярсез... Әмма Олег диңгез затларына хас биологик ритмнар белән мавыга, моны кайда җитди рәвештә өйрәнүләрен белешә башлый. 1990 нчы еллар, әле Интернет юк, әмма КДУ китапханәсе бар. Эзләнә торгач, китапханәдә ул чит ил тикшеренүчеләренең реферативжурналларын табып ала. Япониянең Окояма шәһәрендә галимнәр уздыра торган тикшеренүләр җәлеп итә аны. Ул аларга хат юллый. Гадәти, кәгазьгә язылган, конвертлы хат. Килегез, дигән җавап ала.

Гап-гади Казан студентының болай тик торганнан гына Япониягә чыгып китәр мөмкинлеге булмый, әлбәттә. Әмма Япония мәгариф министрлыгының стипендиясен алырга тырышып карасаң ярый, дип ниятли Олег. Икенче тапкыр гариза биргәннән соң, чынлап та, ул аны ала.

– Япониянең гыйльми атташесы белән әңгәмә вакытында миннән ни өчен әллә кай-

дагы Калкулыклы тауларга («Окояма» шулай тәрҗемә ителә) барырга атлыгып торуым хакында сорадылар. Токио белән Осака күпкә мәртәбәлерәк, олпатрак бит, янәсе. Әмма миңа Окоямадагы галимнәр шөгыльләнә торган тематика кызыклы иде. Мине анда алмасалар, башка бер җиргә дә баруның мәгънәсе юк, дип җавап бирдем, – Олег моны хәзер дә көлеп искә ала. – Алар бик гаҗәпләнде, әмма ниятемнең самурайларча нык икәненә инанды булса кирәк. Алдагы җиде ел дәвамында миңа Япониядә яшәргә мөмкинлек биргән стипендия тапшырылды.

ФӘН ҺӘМ ТОРМЫШ

БЕРВАКЫТ Олег Гусев җитәкләгән фәнни төркемгә бер башкорт фирмасы вәкилләре мөрәҗәгать итә – дуңгызчылык буенча эре җитештерүчеләр һәм экспортёрлар. Аларны бик тә конкрет гамәли сораулар борчый – дуңгызлар яхшы үссен-үрчесен һәм азрак чирләсен өчен нишләргә? Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге җитештерүчеләр белән галимнәрнең гамәли яссылыкта максатлары кисешә икән.

Геном тикшеренүләре – хәзерге вакытта Олег Гусев актив шөгыльләнә торган икенче юнәлеш. Соңгы елларда ул Россиядә күбрәк эшли, гәрчә өе белән гаиләсе Япониядә булса да. Аның сөйләвенчә, Казан галимнәре геном тикшеренүләре буенча шактый алдынгы һәм уңышлы нәтиҗәләргә ирешкән.

– Бездә, мәсәлән, кеше геномындагы «чүп ДНК»сы анализы өлкәсендә компетенцияләр бик көчле, – дип аңлата ул безгә. – Кеше геномында өч миллиард нуклеотид бар, әмма безнең барыбызны да тәшкил иткән аксымны җитештерүче ген – шуларның нибары бер проценты гына. Калганнары, шулай дип әйтергә килешсә, «кара материя». Һәм, беләсезме, ул «кара материя» искиткеч зур әһәмияткә ия, шунда геннарны дистанцион контрольдә тота торган «кабызучылар» белән «сүндерүчеләр» тупланган. Генетик тикшеренүләр шуны ачыклады: авыруга бәйле күп кенә мутацияләр геномдагы нәкъ шул караңгы өлкәләрдә урнашкан. Без аларның активлыгын өйрәнәбез. Медгенетика офыкларын киңәйтергә омтылабыз: ни өчен генның кодлашу урынынннан еракта булган мутацияләрнең теге яки бу авыруны китереп чыгаруын аңларга һәм аңлатырга тырышабыз.

Ни гаҗәп, безнең югары фән өлкәсенә карый торган тикшеренүләр авыл хуҗалыгы практикасында бик кирәкле булып чыкты. Башкортстаннан мөрәҗәгать иткән коллегаларның сораулары төгәл: ни өчен дуңгызның кайсыларыдыр чирли, ә икенчеләре – юк? Нишләп кайбер дуңгыз балалары кечкенә булып туа, ә икенчеләре – эре булып? Без геннарга контрольлек итү әлеге кирәкле сыйфатларга ничек йогынты ясавын аңлатып бирәбез. Коллегалар исә алга таба бу белемне гамәлдә куллана ала: хайваннарны сайлаганда, тукландырганда, дәвалаганда.

ФАНТАСТИК МӨМКИНЛЕКЛӘР ҺӘМ АЛАР КАЯ КИТЕРӘ АЛА

БЕРВАКЫТ галимнәр өйрәнелә торган матдә салынган пробирканы өстәлдә онытып калдырган...

Әйе, кайчандыр якынча шул рәвешле пенициллинны ачканнар. Әмма сүз ул хакта түгел. Минем Олег Гусев төркемендә эшләгән галимнәр турында сөйләвем: алар энәле тычкан күзәнәкләрен алганнар да, шулай ук бик кызыклы ачыш ясаганнар. Бәлки, бу ачыш кешелекне бөтенләй яңа офыкларга чыгарыр.

Сүз уңаеннан, энәле тычкан – Олегның «коллекциясендәге» чираттагы «күренекле» җәнлек.

– Чөнки ул – имезүчеләр арасында регенерациягә фантастик сәләте белән аерылып тора, – ди Гусев. – Әгәр тычканны берәр ерткыч эләктереп алса, ул бөтен тән тиресен аның тешләре арасында калдырырга һәм үзе качып китәргә мөмкин. Ә тән тиресе... яңадан үсеп чыга. Без экспериментлар вакытында шуны да ачыкладык: әгәр аның колагы киселә икән, искесе урынына яңа колак үсә. Бүген фән аерым бер күзәнәктә ниләр баруын ачыклар дәрәҗәгә җитте, ниһаять, без күзәнәктәге популяцияләрнең төрле, шул исәптән регенерация процессларында ничек катнашуын да өйрәнә алабыз.

Тычканнарга килгәндә исә, ял көннәрендә ялгыш өстәлдә онытылып калган күзәнәкләр галимнәр эшкә килгәндә башка күзәнәк тибына үзгәреп куйган, ягъни трансформация кичергән була. Бу галимнәргә стресслы ситуацияләрдә күзәнәкләрдә бер типтан икенче типка үзгәртергә сәләтле механизм барлыгын ачыкларга мөмкинлек бирә. Бик әһәмиятле күзәтү, фәндә ул, чыннан да, яңа офыклар ачарга мөмкин.

СЕНСЕЙ АРЕКУ

2011 елда Япониянең Фукусима префектурасында бик көчле җир тетрәү була, ул цунами күтәрә. Нәтиҗәдә, Фукусима атом электростанциясе җиһазлары зыян күрә.

Ул вакытта Гусевлар яшәгән Цукуба академшәһәрчеге Фукусумига шактый якын урнашкан була, һәлакәтне Олегның хатыны Ирина белән бер яшьлек кызлары бар масштабында кичерә. Берничә сәгать буе алар урамда тетрәп-калтыранып торган җир өстендә утыралар, фатирларына кайта алмыйлар...

Олег үзе бу вакытта Япониядә булмый, әмма икенче көнне үк ул гаиләсе янына кайта. Тиз генә хатыны белән кызын Россиягә озата, үзе һәлакәт барлыкка китергән хәрабәләрне аралорга, кешеләргә булышырга кала. Ял саен Фукусима префектурасы көньягына килеп, җимерелгән йортларны сүтәргә һәм тикшерергә алына, казага тарыганнарга гуманитар ярдәм ташый. Ул чакта Олег «Живой журнал»да блог алып бара, шунда үзенең язылучыларына, зыян күрүчеләргә ярдәм итик, дип мөрәҗәгать итә. Аңа акчаларны дөньяның төрле почмакларыннан җибәрәләр. Ә Олег ул акчаларга дарулар, гигиена кирәк-яраклары, эчке киемнәр сатып ала...

Аның ярдәмен күргән кешеләр Олегны, зур хөрмәт белән, «сенсей Ареку» дип атый (япон кешеләре, билгеле булганча, «л» хәрефен әйтә белми, ә сенсей диюләре – Олег галим булганга). Олег блогында Япония халкының һәлакәт алдында никадәр нык һәм чыдам торуын, сабырлыгын зур соклану белән теркәп бара. Шулай ук, галим буларак, АЭС авариясеннән соң бар тереклеккә куркыныч янаву, «коточкыч радиация» турындагы мифның да чынбарлыкка туры килмәвен кешеләргә җентекләп аңлата.

«Мәскәүдә хәзерге вакытта радиация Токиога караганда 5 мәртәбә югарырак. Ә Япониядә нормаль кешеләрнең мәшәкатьләре икенче – өй, эш, һәлакәт корбаны булганнарга ярдәм күрсәтү... – дип яза Олег. – Эшләргә һәм яшәргә кирәк. Бу – иң мөһиме».

Аның белән шул вакытта аралашканда, Олег үз позициясен бик төгәл аңлатты: «Авыр чакта кайда файдалы була аласың, шунда барырга кирәк».

Блогындагы тагын бер гади генә җөмлә һәрвакыт илһамландырырга сәләтле: «Ә сакура барыбер чәчәк атачак».

Бүгенге заман фәненә суперзаманча җиһазлар кирәк. КФУның «Экстремаль биология» лабораториясендәге яңа буын HiSeq-2500 секвенаторы.

2011 ел, Фукусима АЭС реакторына 35 километр якынлыкта. Олег Гусев, җир тетрәүдән соң, ул китергән һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша.

Бөҗәкләргә карата булган кызыксынуы Олег Гусевның фәнни юнәлешен билгеләде.

Фото: Александр Ефремов, Дмитрий Сивков

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР
ГӨЛНАРА УРАЗМАНОВА

Дмитрий Сивков

Экзотерик туризм белән шөгыльләнү өчен җир читенә – Аркаимга яки Алтайга барасы да юк икән. Көч бирә торган җирләр Казанда да бар, һәм алар шәһәр халкының популяр ял итү урыннарында урнашкан. Аларны биолокация буенча белгеч, Казан университетында ике тапкыр югары белем алган Гөлнара Уразманова тапкан.

БАШКАЛАРГА ИЯРЕП – ЭКСТРАСЕНСЛЫККА

Урамда 1989 ел... СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалындагы икътисад бүлеге хезмәткәре, КДУның тарих факультеты дипломы иясе, фәнни коммунизмны биш бармагыдай белүче Гөлнара Уразманова үзенең... парапсихологик сәләтләрен тикшереп карарга ниятли. Кызык табып, башкаларга ияреп кенә. Өстәвенә, ерак та барасы түгел: Мәскәү һәм Новосибирскида СССР Фәннәр академиясенең биолокация бүлекләре эшли. Күрәзәлек сәләте булган кешеләрне сайлап алу эше бөтен ил күләмендә алып барыла.

– Андый тестны Казанда да үткәрделәр, – дип искә ала Гөлнара. – Үзем анда аяк та атламас идем, тик бер хезмәттәшем үзе белән барырга күндерде. Нәтиҗәдә, сынау узган барлык казанлылар арасыннан бары тик минем белән генә эшне дәвам иттеләр.

Шунысын да искә төшереп узу урынлы: ул вакытта илне сүз иреге дулкыны белән бергә күрәзәлек шаукымы да каплап алды. Джуна, Анатолий Кашпировский, Алан Чумак, Юрий Лонго халык белән шыгрым тулы стадионнар җыя, әледән-әле телеэкраннарда күренеп тора, газета-журналларның беренче битләрендә урын ала. Кайберәүләр, телевизор алдында су һәм кремнар куеп, «сихәтләүченең» энергиясен җыя, кайсылары үзләре үк паранормаль нәрсәләр белән шөгыльләнә башлый... Хәер, бу аларның үзләре өчен җитди проблемага әйләнә ала иде бит.

Гөлнара моны үз тәҗрибәсендә татый. Экстрасенслар курсында кыска гына вакыт эчендә өстән-өстән генә белем алып чыга. Анда хәтта мондый эшчәнлекнең бик мөһим компоненты – үз-үзеңне саклау системасы белән таныштыруны да кирәксенмиләр. Һәм болар барысы да, җыелып, Гөлнараның сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый. Аңа куркынычсызлык техникасын мөстәкыйль рәвештә үзләштерергә һәм эшләргә туры килә.

АДВОКАТЛЫКТАН – БИОЛОКАЦИЯГӘ

Бүген Гөлнараның төп шөгыле – әйләнә-тирә мохиттә күзгә күренми торган объектларны һәм аномалияләрне табу һәм тикшерү. Озак вакыт дәвамында бу шөгыле хобби гына булып тора. Тормышта лаеклырак эшләр дә бар кебек тоела. КФУда юридик факультетны тәмамлап, икенче югары белем алганнан соң, адвокатлык белән шөгыльләнә. Аннары дизайнерлык мавыктыра, 12 ел Раифа монастыре белән хезмәттәшлек итә. Һәм менә бервакыт, монастырьның чираттагы витражын ябыштырганда, ул бу эшнең үзенеке түгеллеген аңлый. Тумыштан бирелгән сәләте төп эше булырга тиеш!

– Моңа кадәр бу шөгылем өчен акча алмый идем, үземә ошаганга гына эшләдем, – ди Гөлнара. – Хәзер торак йортларда, офисларда патоген зоналарны тикшерү белән рәсми рәвештә шөгыльләнәм.

ХАРТМАН ВАРИСЫ

– Ә биолокация һәм патоген зоналарның фән тарафыннан рәсми рәвештә танылмавы эшегезгә комачауламыймы?

– Ни генә әйтсәләр дә, аларның кеше организмына энергетик йогынтысы бар. Ахыр чиктә, исеме атаклы челтәргә бирелгән Эрнст Хартман да надан бер һәвәскәр генә булмаган, ә Геобиология тикшеренү үзәген җитәкләгән. Лозоходлар да борын-борыннан эшләп килгән, гыйбадәтханәләрне алар белән киңәш-табыш итмичә төземәгәннәр.

– Кешеләр сезгә нигә мөрәҗәгать итә?

– Сәламәтлекләрен кайгырту максатында. Чөнки энергетикасы бик уңай тәэсир итә торган урын да, тискәресе кебек үк, куркыныч булырга мөмкин. Әгәр, әйтик, кемнеңдер караваты шул урынга туры килсә, анда йоклаучы кешедә рак котылгысыз диярлек. Хәзер, архитекторлар белән эшләп, күбрәк кешегә ярдәм итә алам. Әгәр дә мондый «көч ноктасы» күпкатлы бинада икән, аның йогынтысы нигездән түбәгә кадәр «тишеп үтә».

– Рамкаларыгызга башкаларга кагылырга рөхсәт итәсезме? Әллә алар шаман дөңгере кебек беркем орынмаска тиешле әйберме?

– Биолокация магиясе һич тә рамкада гына түгел. Алар асылда заказ бирүчегә процессны визуальләштереп күрсәтү өчен кирәк. Сүз уңаеннан, минекеләр – гап-гади бәйләм энәләре, әле совет заманыннан ук калган.

ЯЛКАУЛАР ӨЧЕН «НОКТАЛАР»

Гөлнараның тагын бер яраткан шөгыле бар. Ул Казанның «көч нокталарына» экскурсияләр оештыра. Экскурсиягә язылырга теләүчеләрне шунда ук кисәтеп куя: кайбер урыннарның энергетикасы кеше өчен артык көчле булырга мөмкин. Шуңа күрә ул аларны чит-ятларга күрсәтмәскә тырыша. Кешеләрнең сәламәтлеге өчен дә җаваплылык алырга әзер түгелмен, ди. Бу мәсьәлә әле тикшерелмәгән, әйтик, шул ук Аркаимда булганнан соң, күпме кешенең нәрсә белән авырганы турында мәгълүмат юк.

– Шулай да экскурсия оештырасызмы соң?

– Зыян китермәс өчен, мөмкин кадәр саграк эшлим. Кеше күпмедер басып торып, бераз көч-дәрт тупларлык урыннарны гына билгелим. Әлбәттә, ул арада кешегә зыян килмәячәк, бернинди инсульт-инфаркт та бәрмәячәк. «Көч ноктасында» 2–3 минуттан да артык тормаска киңәш итәм.

– Андый урыннарга ничә тапкыр барырга ярый?

– Әгәр көчегез бетүен сизәсез икән, көненә берничә тапкыр да ярый. Һәркем үзенә карый. Элек мин мондый урыннарны курка-курка гына күрсәтә идем, ләкин соңрак шуны аңладым: безнең кешеләр ялкау холыклы, андый нокталарга еш барып йөрерләр дип артык борчылмасаң да ярый икән.

«ТАБА»ДА КӨЧ ҖЫЙ

Казандагы көч урыннарының берсен булса да телгә алмасак, дөрес булмас кебек. КФУның бер түгел, ә ике диплом иясе безне үзенең альма-матерына алып килде.

Югары уку йортының төп корпусы каршындагы скверны, аның ярымтүгәрәк формасы һәм җәйге кояшлы көннәрдә көйдергән эсселеге аркасында, студентлар «сковородка» – «таба» дип йөртә. Болытлы кышкы көндә исә «таба»дагы бердәнбер якты тап булып, университетның иң мәшһүр студенты – Володя Ульянов-Ленинның йомшак кар бөртекләре кунган һәйкәле постаментындагы канәфер чәчәкләре бәйләме генә ята.

Елның башка фасылларында биредә гадәттә кеше күп була: университет халкы да мәш килә, туристлар да бихисап күренә. Декабрьнең бүгенге шимбәсендә Гөлнараның чыгышын тыңларга КФУның IV курс студентлары Сабина һәм Даниилны гына җәлеп итә алдык.

Гидыбыз эскәмиянең кырыена гына диярлек утырды да аңлатып китте:

– Мин утырган урыннан – эскәмия читеннән 10-15 сантиметрда «көч ноктасы» бар. Монда хәтта кыш көне дә кар булмый диярлек. Бу – экскурсияләр һәм чыбыксыз телефон аша ирешкән хәбәрләр нәтиҗәсе: бу урынны яхшы белүчеләр шактый.

Бу «нокта» бик җиңел табылуы белән аерылып тора.

– Кара әле, кызык икән! Монда ничә минут утырып торырга була? – дип сорый булачак инглиз теле белгече Сабина.

– Өч-дүрт минут, шуннан артык түгел. «Утырган батареяларыгызны» кору өчен шул җитә. Димәк, лекцияләр арасындагы тәнәфес вакытында да өлгерә аласыз.

– Моннан файдаланырга кирәк әле... Рәхмәт.

Шул рәвешле бүген бу ноктаны белүчеләр исемлеге тагын берничә кешегә озынайды.

КФУ студентлары Сабина белән Даниил «таба»дагы «көч ноктасы» турында сөйләшә.

** Хартман челтәре – геобиологик челтәрләр кисешкән урыннар. Алар сәламәтлеккә тискәре йогынты ясый торган геопатоген зоналар тудыра, мондый зоналар биолокация методы белән табыла. Әлеге күренешне тасвирлаган Эрнст Хартман хөрмәтенә аталган.*

АЛТЫН ТУЙГА ИЛТКӘН ЮЛ

Руфия Фазылова

2024 ел Россиядә Гаилә елы дип игълан ителгән иде. Ел тәмам. Аңа карап лаеклы, матур гаиләләр турында язуны туктатмыйбыз. Гаилә ул – мәңгелек тема. Бүгенге гаиләбез үзенчәлекле: тормыш аларга бәхетен дә, сынавын да өеп биргән...

Гаиләдә хатын-кыз роле – ул нинди? Иң авыр вакытларда да ничек үзеңдә көч табарга? Казанда яшәүче Фәнисә Гайнуллина бу сорауларга җавапны тәгаен белә. Яңа елның беренче эш көнендә очрашып, Фәнисә ханым белән озаклап сөйләштек.

Башта ачыклык кертергә кирәктер: Фәнисә ханым – танылган журналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Хәлим Гайнуллинның җәмәгате. Хәлим абыйны күпләр «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире, аннан соң «Шәһри Казан» газетасын оештырган тынгысыз кеше буларак хәтерлидер. Шулай ук ул Татарстан Республикасы мәгълүмат һәм матбугат министры урынбасары булып та хезмәт куйган шәхес. 2002 елдан – Татарстан Юстиция министрлыгының «Хокук һәм хәят» журналы мөхәррире дә. Ни аяныч, шулай матур гына эшләп йөргәндә, Хәлим Гайнуллинга инсульт булды. Әнә шул көннән бирле ул – җәмәгате Фәнисә ханым кулында...

УРАЛ КЫЗЫ МИН...

Фәнисә ханым хәзерге Пермь краеның Барда районында туып үсә. Әтисе Фәсах Бөек Ватан сугышында Кёнигсбергка кадәр җитә, яраланып, күп кенә орден-медальләр белән кайта. Шуннан соң авылда авыл советы рәисе булып эшли, әнисе исә укытучы була. Фәнисә ханым нәселе, эби-бабалары белән бик горурлана:

– Картәнием (бездә дәү әнине шулай атыйлар) – абыстай, картәтием авыл мулласы иде. Без әнием ягыннан – Мурадимовлар, картәтинең әтисе Мирхәйдәр хәзрәт белән бик горурланабыз. 1916 елда үзенең хаҗга барырга дип җыйган акчасына авылда мәчет салдырган. Революциядән соң мәчетнең манарасын кисканнәр һәм аны мәктәп иткәннәр. Әнием әлеге мәктәптә укыткан да әле. Бүген

Фотолар Гайнуллиннарның гаилә архивыннан

бу ике катлы агач йортта яңадан мәчет эшли. Ул Пермь краенда революциягә кадәр салынган һәм бүген дә эшләп торган өч мәчетнең берсе. Рәхмәт авыл кешеләренә, мәчетне карап торалар. Аллаһ йортына икетуганым Рафикъ та һәрдаим ярдәм итеп тора.

МӘКТӘПЛЕ ГОМЕР

Фәнисә ханым башта – Оса педагогика училищесын, аннан соң Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Мирза Мәхмүтов җитәкләгән фәнни-тикшеренү институтында эшләп алганнан соң, мәктәпкә тарих, татар теле, әдәбияты укытырга күчә. Шулай итеп 30 елга якын гомере балалар арасында уза...

– 1989 елда без, берничә укытучы, Казан мәктәпләренең кайберләрендә, эксперимент буларак, беренче сыйныфларда укучы рус балаларына татар теле укыта башладык. Аңа кадәр рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле йә дәресләргә кадәр, йә дәресләрдән соң калдырып укытыла иде. Рус балалары өчен бернинди дәреслекләр дә, методик кулланмалар да юк заман. Татар балаларына рус теле укыту методикасын кулланып эшли башладым. 1993 елда гимназияләрдә милли мәгариф буенча директор урынбасары вазифасы штатка керде. Һәм мине атаклы 102 нче гимназиягә Мария Устинова урынбасары итеп билгеләделәр. Документлар өйрәнеп, шулар нигезендә программа, укыту һәм тәрбия эшләре планнары төзедем. Бик яратып эшләдем. 2008 елда, Казанда 20 нче мәктәптә эшләү чорында, өстенлекле «Мәгариф» милли проектында җиңеп чыгып, Путин грантына ия булдым. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләндем. Югары категорияле укытучымын.

Хәзер дә милли мәгариф системасындагы үзгәрешләр белән кызыксынып барам. Бүген татар теленең аяныч хәлен күреп бик сыкранам. Безнең мәктәпнең рус балалары район, шәһәр олимпиадаларында призлы урыннар алалар, хәтта мәктәпнең татар театрында да катнашалар иде. Ә хәзер рус мәктәбендә укучы татар баласы да үз ана телен әти-әнисе теләге булса гына өйрәнә ала. Кем уйлаган шундый көннәр килер дип...

ИР – ХАТЫНЫНЫҢ, ХАТЫН ИРЕНЕҢ КОЛЫ БУЛЫРГА ДА ТИЕШ ТҮГЕЛ

Гайнуллиннарның узган ел алтын туйлары булган. Илле ел гомер узган... Танышулары кызык кына: егет тә, кыз да Казан дәүләт университеты студентлары. Хәлим – өченче курста, Фәнисә исә беренче курста укый. Күрше бүлмәдә генә яшиләр. Егет беренче булып кызга сүз ката. Әле укырга кереп, Казанга яңа гына ияләнә башлаган Фәнисә исә бик игътибар итми. Егетләр белән аралашырга түгел, укырга кирәк дип уйлый. Әмма бик тиздән Хәлимнең нияте изге, максатлары җитди икәнлеген аңлап ала.

– Университетны тәмамлагач, Хәлимне армиягә җибәрделәр. Ул Ерак Көнчыгышта өлкән лейтенант булып хезмәт итте. Мин аны армиядән көтеп алдым. 1974 елның 17 августында өйләнештек.

«Ир – баш, хатын – муен» дигән гыйбарә безгә туры килми. Боргалап кара син аны! Миңа да мөстәкыйльлек, алга куелган максатларыңа ирешергә тырышу хас. Без Хәлим белән беркайчан да бер-беребезнең иреген кысмадык. Минем тарафтан ул кайда булдың, ник соң кайттың дигән сорауларны ишетмәде диярлек. Аның хәтта күпме хезмәт хакы алганын да белмәдем. Театрга, концертларга, туганнарга-дусларга кунакка йөрергә, үзебез дә кунак чакырырга яраттык. Тик аның да, минем дә вакыт җитмәү сәбәпле, андый бәхет күп булды, дия алмыйм. Хәлим Бардага кайтырга да бик ярата иде.

2006 елда Италиягә икәү бергә бардык. Иң истә калган сәяхәт шул булды. Ләкин дөресен әйтим, Хәлим авырып киткәнче, санаторийга бергә без бары тик бер мәртәбә бардык.

Балалар, йорт, бакчадагы эшләр күбесе миндә иде. Хәзер уйлап куям: гаиләдә җаваплылык күбрәк минем җилкәгә төшкән икән бит. Хәер, бу зарлану түгел, димәк, башкача булдыра алмаганмын. Ир канаты астында, беркайда эшләмичә яшәүче хатыннарны аңламыйм. Тормышта төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Киләчәгеңне, картлыгыңны уйламыйча яшәргә ярамыйдыр ул.

Гаиләнең ныклыгы ул бер-береңне аңлауда, тормыш иптәшеңне шәхес буларак ихтирам итүдә, дип саныйм. Гадел булырга, алдашмаска кирәк. Алдашкан кешеләрне җенем сөйми. Ир – хатынының, хатын иренең колы булырга да тиеш түгел.

– Университетны тәмамлагач, Хәлимне армиягә җибәрделәр. Ул Ерак Көнчыгышта хезмәт итте. Мин аны армиядән көтеп алдым.

СЫНАУ...

Аллаһы Тәгалә һәр гаиләгә сынау бирә. Кемгәдер ул – яшьлектә, кемгәдер олыгайган көндә килә. Һәм ул сынауны барлык парлар да уза алмый. Менә шунда инде ир белән хатынның бер-берсенә булган мәхәббәте, ихтирамы күренә дә.

Гайнуллиннар гаиләсен дә язмыш икегә бүлә. Тау кадәр планнар белән йөргәндә, гаилә башлыгы урынга егыла...

– 2010 елның 10 гыйнвары безнең гаилә тормышын бөтенләйгә үзгәртте. Хәлимнең күпме планнары, эшләнәсе эшләре чәлпәрәмә килде. Автобиографик жанрдагы китап язарга җыенып йөри иде ул. Аның инде материаллары, фотолары да җыелып беткән. Диссертация буенча эшләү сәбәпле, китап язуны кичектереп торды. Диссертацияне уңышлы яклады, тарих фәннәре кандидаты исемен алды, ләкин... Хәзер уйлыйм, киресенчә, диссертацияне кичектереп торып, китабын бастырып чыгарырга кирәк булган икән.

Хәлим реанимациядә, комада ятканда, аннан соң да өй телефоны бертуктамый шалтырады. Шунда мин аның дуслары никадәр күп булуын аңладым, туганнарның, гаилә дусларыбызның ярдәмен тойдым. Хәлимгә операция ясату өчен нейрохирурглар белән элемтәгә кереп, аны үлем тырнагыннан коткару өчен тырышлык куйган «Апас» якташлык җәмгыяте җитәкчесе, Россия Дәүләт Думасы депутаты Марат Габделхәй улы Нуриевка бик рәхмәтлемен. Ул хәзер дә аның хәлен белешеп тора, ярдәменнән ташламый. Якташлык җәмгыяте җитәкчесе урынбасары Наил Галиуллин, Фәрит Мифтахов, Габделбәр Ризванов, Ислам Әхмәтҗанов һәм башка бик күпләр, һәрдаим Хәлимнең хәлен сорашып, өйгә килеп, аңа ярдәм итеп тора. Аларның барысына да бик зур рәхмәт.

САБЫРЛЫК СЕРЕ

Халим абыйга егерме дүрт сәгать дәвамында игътибар кирәк. Тик Фәнисә ханым зарланмый. Хәер, аның моңа вакыты да юк. Сабыр ханым бу теманы артык куертырга да яратмый.

– Үземне сабыр кеше димәс идем. Тормыш өйрәтә икән ул сабыр булырга да, еламаска да. Авырлыкларны җиңеп чыгу өчен, кеше иң беренче үз-үзенә таянырга тиеш, дип уйлыйм. Тора-бара авырлыкларга да яраклаша икән ул адәм баласы. Әйткәнемчә, туганнар, дуслар бар. Хәлимнең Апаста яшәүче абыйсы белән энесе, кучтәнәчләрен төяп, бик еш киләләр. Берничә җәй аны үзләренә алып та карадылар. Казанда яшәүче апасы белән сеңлесе, минем ике сеңлем хәлне белеп торалар. Без, берничә гаилә, Казанда яшәүче бардалылар, инде күп еллар бергә аралашып, кунакка йөрешеп, ярдәмләшеп яшибез.

Мин бит әле һаман эшлим дә. Хәлимнең «Хокук һәм хәят» журналы әле дә кварталга бер тапкыр чыга. Хәзерге мөхәррире Айгөл Җиһаншина белән бергәләп эшлибез. Кыскасы, депрессиягә бирелергә вакытым юк. Иң мөһиме – исәнлек булсын.

УЛЛЫ, КЫЗЛЫ ГАИЛӘ

Хәлим абый белән Фәнисә апа бер ул, бер кыз тәрбияләп үстергән. Ата белән ананың юанычы, олы шатлыгы алар.

– Олы кызыбыз Ләйсән педагогика институтының чит телләр факультетын тәмамлады. Инглиз теле укытучысы булып та, ТР Дәүләт автоинспекциясенең пропаганда бүлегендә дә эшләде. Хәзер гаиләсе белән Америкада яши. Оныгыбыз Элинага 15 яшь. Бик актив кыз, үзләренең штатлары хорына да йөри, флейтада, саксофонда уйный. Курайда матур гына татарча көйләрне уйнарга өйрәнеп килә. Һәр җәйне Ләйсән белән Элина ике айга Казанга кайта. Мине кая да булса ялга җибәрергә тырышалар.

Улыбыз Илнар исә финанс-экономика институтын тәмамлады. Хәзер Татарстан Милли китапханәсендә маркетинг бүлеге җитәкчесе булып эшли. Әле алар бар дип сөенәм. Нинди генә авырлык килсә дә, төшенкелеккә бирелергә ярамый, минемчә. Киләчәккә өмет белән яшәргә кирәк. Кешене шул яшәтә.

игелекле эшләр

мәңгелек / кыйммәтләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Шәехзадә Бабич татар тарихында **нинди** эз калдырган

Беренче бөтендөнья сугышында татар әсирләре **нинди** җырлар җырлаган

Урта Бирәзә авылының яшьлек сере **нәрсәдә**

Кукмара итекләре кәефне **ничек** күтәрә

ТАТАР БАСМА СҮЗЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ТАРИХЧЫ–ЭНЦИКЛОПЕДИСТЫ

Илдус Заһидуллин

Мәһабәт бина-йортлар ныклы нигезгә таяна. Шулар шикелле үк, гуманитар фәндә дә беренче карашка күзгә бәрелеп тормаган, әмма гаять әһәмиятле, нигез ташы саналырга тиешле милли матбугат тарихы, энциклопедистика өлкәләре бар. Бу өлкәдәге фидакарь шәхесләребезнең берсе – күренекле галим-китапчы, матбугат белгече һәм библиограф Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиев.

«АМУР»ДАГЫ ГАМЬЛЕ КИЧӘЛӘР

Исмәгыйль Рәмиев Уфа губернасы Эстәрлетамак шәһәрендә 1895 елның 1 гыйнварында вак сәүдәгәр, кызыл мал кибете тотучы Габдулла Рәмиев гаиләсендә дөньяга килә. Рәмиевләр нәселе төбәктә руханилар һәм алыш-биреш итүче сәүдәгәрләре белән танылган була. Габдулланың бер кардәше Лотфулла (булачак шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең этисе) төзелеш өчен агач материаллары белән сату итә. Тагын бер кардәше Мөхәммәтсадыйк – шагыйрь Дәрдемәнднең этисе – алтынчы-сәүдәгәр, күренекле меценат булып таныла. 1891–1926 елларда Эстәрлетамакта мулла булып торган Мөхәммәтгариф Рәмиев тә – аның туганы.

Әлбәттә, мондый көчле нәсел үз дәвамчыларына төпле белем бирү ягын кайгырткан. Исмәгыйль дә туган шәһәрендәге җәдит мәдрәсәсендә укый. Аннары Казанга килеп, Юнысовлар табыш йорты бинасындагы «Амур» мосафирханәсенә (хәзерге Мәскәү урамы, 70 йорт) хисапчы булып эшкә урнаша.

Әлеге табыш йортының беренче катында «Шәрык клубы» идарәсе, касса, кием салу урыны һ.б. эшләсә, икенче каты сәхнә һәм өч йөзгә якын тамашачы сыя торган тамаша залы көйләнгән була. Анда спектакль, концерт, лекция, бию кичәләре, аерым артистларның концертлары, 1913 елдан башлап балалар өчен чыршы бәйрәмнәре үткәрелә. Заһидулла Яруллин җитәкчелегендә оешкан беренче татар кыллы оркестры да биредә чыгыш ясый. Исмәгыйль 1912–1913 елларның кышкы айларында Габдулла Кариев җитәкләгән «Сәйяр» труппасында суфлёр булып та эшли, артистлар тормышы белән якыннан таныша.

1912 елның декабрендә нәшер ителә башлаган «Кояш» газетасы да «Амур»да бер бүлмәне били. Фикри җитәкчесе Фатих Әмирхан булган газета редакциясендә Габдулла Тукай әдәби хезмәткәр булып исәпләнә. Исмәгыйль дә редакциягә һәм иҗат әһелләре янына килеп йөргән күпсанлы язучылар һәм сәнгать кешеләре белән аралаша.

Клубның уку залы һәм буфеты, мосафирханәнең рестораны да буш тормый: берәүләр ашый, чәй эчә, газета караштыра, икенчеләр шар суга. Биредә әдәбият, матбугат мәсьәләләре буенча бәхәсләр кабына, аларда әйтелгән фикерләр татар әдәбиятына йогынты ясамый калмый. Шул рәвешле, Шәрык клубында даими үткәрелгән мәдәни чаралар, «Кояш» газетасы редакциясе эшчәнлеге, күренекле иҗат әһелләре яшәгән «Амур»да зыялы татар егет һәм кызларының даими җыелуы, аралашуы үз ролен уйнамый калмый. Тәүлек дәвамында «Амур»да эшләгән һәм яшәгән Исмәгыйль бу тормышны кызыксынып күзәтә.

РӘМИЕВНЕҢ ТАТАР МИЛЛИ-МӘДӘНИ ҮЗӘГЕНӘ ӘВЕРЕЛГӘН «АМУР»ДА ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШНЫҢ БАРЫШЫ, АНДА ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ КӨНКҮРЕШЕ ХАКЫНДА ДИСТӘ ЕЛЛАР ҮТКӘЧ ЯЗЫЛАЧАК КҮЗӘТҮЛӘРЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕН ӨЙРӘНҮЧЕЛӘР ӨЧЕН ИСКИТКЕЧ КЫЙММӘТЛЕ ТАРИХИ ЧЫГАНАККА ӘЙЛӘНӘ.

Фотолар автордан алынды

ХӘРБИ ХЕЗМӘТ ҺӘМ ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ХӘРӘКӘТЕ

Егет җәй айларында «Сәйяр» профессиональ театры суфлёры буларак, ил буйлап гастрольләрдә йөри, күп шәһәрләрдәге татар җәмгыяте лидерлары белән таныша. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, 1915 елда Исмәгыйль Рәмиев армиягә мобилизацияләнә, ләкин фронтка эләкми. 1917 елга кадәр Уфа гарнизонындагы бер полкта писарь вазифасын үти.

Уфада татар сул эсерларының җитәкчесе булган Галимҗан Ибраһимов аны 1917 елдан башлап сәяси эшчәнлеккә һәм татар иҗтимагый хәрәкәтенә җәлеп итә. Солдат Рәмиев 1917 елның 12–17 июлендә – Уфа губернасы мөселманнары съездында, 20 июльдә Казанда Бөтенроссия мөселманнарының II корылтаенда катнаша.

Оренбургта 1917 елның декабрендә үткән III Гомумбашкорт корылтаена ул татар халкы вәкиле итеп чакырылган Галимҗан Ибраһимовның ярдәмче-сакчысы сыйфатында бара. Уфада эшләгән Милләт мәҗлесе (1917 елның 4 декабре – 1918 елның 24 гыйнвары) эшендә гаскәриләр Шурасы вәкиле буларак катнаша. Бер үк вакытта татар эсерларының «Безнең юл» газетасында журналист булып та эшли.

Гражданнар сугышы башлангач, Көнчыгыш фронтның 5 нче армия штабында нәшер ителгән «Кызыл яу» (Бөгелмә), Төркестан фронты 1 нче революцион армиянең «Кызыл йолдыз» матбагаларында, 1920 елда Самарада басылган «Кызыл дөнья», 1920–1921 елларда Уфада чыгып килгән «Шәрык ярлылары» газеталарында эшли.

Тугыз елга диярлек сузылган хәрби хезмәттән соң, ниһаять, Уфада төпләнеп, төрле елларда Башкортстан башкаласының матбугат һәм мәдәният оешмаларында тәрҗемәче, журналист һәм инструктор булып эшли.

БАРЛЫГЫ ОНЫТТЫРЫЛГАН КИТАП

1921–1930 елларда Казанда ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршында Академик үзәк уңышлы эшләп килә. Үз тирәсенә фән белән шөгыльләнүче шәхесләрне туплаган бу оешма татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү буенча зур эш башкара. 1925–1927 елларда Академик үзәкне Галимҗан Ибраһимов җитәкли. Шуңа күрә Рәмиев 1925 елда Казанга күченгәч, Ибраһимов аны Үзәкнең әдәби мирасны бастырып чыгару комиссиясе сәркатибе итеп эшкә ала, милли матбугат буенча белешмәлек әзерләү бурычын йөкли.

1926 елда аның «Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» исемле 233 битлек, күпсанлы рәсемнәр урнаштырылган альбомы дөнья күрә. Төзүче үз хезмәтен «альбом», «әсәр» дип атаса да, чынлыкта ул материалларның бирелеш тәртибе, аларның эчтәлеге ягыннан татар вакытлы матбугаты буенча белешмәлек булып тора. Татар басма сүзе тарихын яктырткан тәүге белешмәлек әнә шулай дөньяга килә. Ул кайсы яклары белән үзенчәлекле соң? Басма, беренчедән, хронологик яктан 1925 елга кадәр, ягъни хезмәт типографиягә тапшырылган вакытка кадәр җиткерелгән. Икенчедән, анда татар телендә нәшер ителгән, автор-төзүче ачыклый алган кадәр барлык газета-журналлар, сыйнфый караштан чыгып һәм сәяси-идеологик төркемнәргә (милли буржуаз, социалистик, контрреволюцион, кызыл гаскәри, совет һәм партия матбугаты һ.б.) бүлеп-бүлеп урнаштырылган. Өченчедән, бирелдә татар мөселманнары һәм татар керәшеннәре газеталарыннан тыш, Кавказда, Кырымда, Төркестанда төрки телләрдә нәшер ителә торган матбугат органнары турында кыскача мәгълүмат (күбрәк таблицалар рәвешендә) бирелгән. Дүртенчедән, мөселманнарга атап, русча бастырылган газеталар да кертелгән.

Төзүче үзенең кереш сүзендә Идел-Урал төбәге вакытлы татар матбугатының барысы да бу хезмәткә кереп бетте, дип әйтә алмавын белдерә. Бигрәк тә Февраль революциясе һәм хәрби коммунизм чорларында чыгарылганнарын туплау кыен булуын, Гражданнар сугышы вакытында шәһәрләрнең кулдан-кулга күчеп йөрүе, кайбер газеталарның берничә сан гына чыгып калуы сәбәпле, аларның төп нөсхәләрен табу авырлыкларын әйтеп уза. Шулай ук белешмәлек структурасының эш барышында формалашуын; фәкать басма матбугатны гына исәпкә алуын; тулысы белән булмаса да, татар матбугатында фикер, тел, ислах юнәлешләрендәге үзгәрешләр ачык күренеп торсын өчен, язмалардан өзекләр урнаштыруын билгеләп үтә. Сәяси юнәлешләргә бүлгәндә, башта милли рухта чыгарылган, тора-бара аннан тайпылып, төрлечә үзгәреш кичергән газеталарны бүлекләргә урнаштыргандагы кыенлыкларны әйтә.

10 ел да үтми, сәяси сәбәпләр аркасында, альбом-белешмәлек китапханәләрдән җыеп алыначак һәм аның барлыгын да онытгырачаклар...

Әмма мәгълүматның киңлеге һәм тирәнлеге ягыннан Рәмиев төзегән фундаменталь басма вакытлы матбугат һәм милли мәдәният тарихы белән шөгыльләнүче бер галим дә әйләнеп үтә алмаган хезмәткә әверелә.

МАТБУГАТ КАЗАНЫНДА

Исмәгыйль Рәмиев 1928 елда яңа урынга күчкәнче, ягъни ТАССР Үзәк башкарма комитеты каршындагы яңа татар әлифбасы – «Яңалиф» җәмгыятендә һәм аның «Яңалиф» журналында җаваплы һәм техник сәркатип вазифаларына керешкәнче, газета-журнал нәшриятында сәүдә вәкиле, «Чаян» журна-



«Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» альбомының русча титул бите.

«Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» альбомының татарча титул бите.

«Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» альбомының соңгы бите.

«Истәлекләр. Татарча басма сүз» китабының тышлыгы. Казан, 1965 ел.

«Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек)» китабының тышлыгы. Казан, 2001 ел.

лында әдәби хезмәткәр булып хезмәт куя. Яңа эш урынында латин алфавитын тиз арада гамәлгә кую программасы кысаларында «Имля сүзлеге»н әзерләп бастыра. 1930 елдан ТАССР дәүләт нәшриятында җитештерү бүлеге мөдире урынбасары булып эшли. Бу чорда аның «Татар теленең орфография сүзлеге» (И. Кули белән бергә әзерләнгән, 1931) һәм «Татар әдәби телендәге интернациональ сүзләрнең орфография сүзлеге» (1934) дөнья күрә.

1937 елда Казанда иҗат әһелләрен кулга алулар башлангач, хәвеф-хәтәрдән котылу эзләп, Урта Азиягә китеп бара. Исмәгыйль Рәмиевнең Урта Азиядә яшәгән чоры әлегәчә махсус өйрәнүне сорый торган тема булып кала бирә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 1942 елның декабрендә 47 яшьлек Исмәгыйль Рәмиев хезмәт армиясенә алына һәм 1944 елның июненә кадәр Свердловск өлкәсе Алапаевка шәһәренең бер заводында укыту инструкторы булып, аннары тылдагы хәрби частьләрдә писарь вазифасын башкара.

Казанга кайткач, прописка булмау сәбәпле, гаиләсе яшәгән Кайбыч районына китә һәм 1949 елга кадәр районның «Колхоз бригадасы» исемле газетасында җаваплы сәркатип, аннары, 1956 елда пенсиягә чыкканчы, Мәдәният йортында инструктор булып эшли. Кайбычта яшәгән вакытта ул фәнни эзләнүләрен яңарта. Казанга килгән саен архивта милли мәдәни институтларга һәм шәхесләргә бәйле документларны, китапханәләрдә 1917 елга кадәрге вакытлы матбугатны өйрәнә. Сталин вафатыннан соң илдә беркадәр иркенлек урнашкач, 1956–1966 елларда «Совет әдәбияты» журналында аның истәлекләр сериясе дөнья күрә.

Бу елларда Исмәгыйль Рәмиев язучылар һәм мәдәният хезмәткәрләре арасында каләм тибрәтеп тә танылა. Аның юмор-сатира әсәрләре «Чаян»да басыла, 1956 елның декабрендә Татарстан Язучылар берлеге драма секциясендә «Тәфтиләү» исемле тарихи пьесасы тикшерелә һәм уңай бәяләнә.

РӘМИЕВНЕҢ ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА, ГАБДУЛЛА КАРИЕВКА, «ШӘРЫК КЛУБЫ»НА, XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР КАЗАНЫНЫҢ МӘДӘНИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫНА БАГЫШЛАНГАН КҮЗӘТҮЛӘРЕ 50 НЧЕ ЕЛЛАР АЗАГЫНДА ХАЛЫК ТАРАФЫННАН АЧЫШ БУЛАРАК КАБУЛ ИТЕЛӘ.

БЕР КУЛЪЯЗМАНЫҢ ЯЗМЫШЫ

Галим 1958 елда «Идел буе татарлары арасында китапчылык эше» исемле монографиясен тәмамлап, аны бастыру өчен Татарстан китап нәшриятына тапшыра. Кулъязма рецензентлар тарафыннан тискәре бәяләнә. Бу урында рецензентлар тәнкыйтенең кайбер объектив сәбәпләрен әйтеп китү дә урынлы булыр. Беренчедән, автор китабында, фәнни текстларда таләп ителгәнчә, мәгълүматның кайсы чыганактан алынганын күрсәтми. Икенчедән, аның хезмәте ул заман фәне өчен гаять зур яңалык була, шул сәбәпле дә кайбер мәгълүмат шик уята. Әйтик, ул елларда совет тарих фәнендә Казан университетында укыган 5-6 татар студентының исеме генә билгеле була, ә Рәмиев, ТАССР Дәүләт архивында Казан университеты фондыннан студентларның шәхси эшләрен өйрәнеп, аларның XIX гасырның беренче яртысында ук өч дистәгә якын булуын ачыклый. Казан университеты галимәсе С. М. Михайлова 1840–1861 елларда укыган әлеге татар студентлары исемлеген фәкать 1979 елда гына «Казанский университет и просвещение народов Поволжья и Приуралья» китабында урнаштыра. 1861–1895 елларда укыганнарның исемнәрен 1991 елда нәшер ителгән «Казанский университет в духовной культуре народов Востока России» исемле монографиясендә санап үтә.

Моннан тыш, 1917 елга кадәр нәшер ителгән газета-журналлар, бигрәк тә китаплар саны совет чоры татар мәдәнияте казанышларының масштабына кагылышлы шикле сораулар тудыра. Кулъязмада шулай ук, сыйнфый көрәш теориясенә каршы килеп, татар байларының китаплар һәм вакытлы матбугат чыгаруга ярдәмнәрен сурәтли, милли мәсьәлә буенча да сәяси «ялгышлар» җибәрә. Анда ТАССРда гуманитар совет фәненең артта калганлыгы күренә, яңа фактларның революция генә татар халкына яхшы тормыш һәм югары мәдәният алып килде, дигән партия фикеренә каршы килүе дә хезмәтне бастыруга киртә була. Җиде ел дәвамында кулъязма автор һәм нәшрият арасында йөри, бу вакыт эчендә фәнни текст юкара, авторның «Казан утлары»нда басылган истәлекләре белән алыштырыла. Шул сәбәпле 1956 елда хезмәт ике өлештән торган «Истәлекләр. Татарча басма сүз» исеме куелып нәшер ителә.

Хезмәт хронологик яктан Идел буе Болгарстаны заманыннан башлап 1917 елларга кадәрге чорны колачлый, ягъни басма сүз кулъязма китап тарихының дәвамы итеп тасвирлана. Урта гасыр чорын автор Шиһабетдин Мәрҗанинең хезмәтен файдаланып бәян итә. XVIII гасырда төркиләр өчен китапларның патша хакимияте тарафыннан сәяси максатларда басылуын ассызыклый. XIX гасыр башында «Азия типографиясе» ачылу, анда техника, кадрлар һәм эш шартлары, басылган китаплар репертуары, аның университет китапханәсенә кушылу сәбәпләрен этрафлы итеп сурәтли. Хосусый басмаханәләр һәм нәширләр, фәнни һәм дөньяви, русчадан тәрҗемә ителгән китапларга, халык әдәбиятына юл истәлекләренә, календарьларга күзәтүләр ясый, китап бастыру динамикасын тасвирлый.



Әдәби сүзлек

Исмәгыйль РӘМИ

* Дәвамы. Башы журналның 1992 елгы 5—6, 7—8, 9—10, 11—12 һәм 1993 елгы 1, 2, 3, 4 саннарында.

80

«ЛӘҺҖӘИ ТАТАРИ» — татар теленең сүзлеге. Каюм Насыйри әсәре. Ул ике кисәктән гыйбарәт булып, беренче кисәге — 224 бит, 1895 елны, икенче кисәге — 157 бит, 1896 елны Казанда басыла.

Бу хезмәт бездә татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүдә беренче тәҗрибә булып тора. Сүзлеккә 10 500 гә якын сүз кергән. Китапка язылган сүз башында мондый юлларны укыйбыз:

«... Татар телебезгә хезмәтчеләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телебез артта, бик бәгыйд (еракта) йоклап калмыштыр. Әмма татар телебезгә хезмәтче мән буласм дип утыз биш ел уздырдым, ләкин күп мәгънә чыкмады. Төн-көн никадәр иҗтиһад кыйлсам, шулкадәр җәфа чиктем; милләтебез халкын татар дип тәсмия кыйлсам (атасам), яратмадылар, татар теле дисәм, яратмадылар...»

Бездә гарәпчә, фарсыча яки гарәп-фарсы-чыгътай катыш чуар телдә язу өстенлек иткән бер заманда К. Насыйри әнә шулай туган телебезне яклап чыга һәм үзенең бу өлкәдәге эшчәнлеге белән бүгенге татар әдәби телебезнең нигез ташларын салуда беренчеләрдән була.

МАКСУДИ Садретдин Низаметдин улы (1879—1957) — язучы, җәмәгать эшлеклесе, юрист. Казан өязе Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа. 1888—94 елларда Казанда Күлбуе мәдрәсәсендә укый, аннан Укытучылар хәзерләү мәктәбен (Учительская школаны) тәмамлый. Ахырда Парижда Сорбонна университетының юридик факультетын тәмамлап кайткач, Казанда антлы дәгъва вәкиле (присяжный поверенный) булып эшли. Икенче һәм Өченче чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты. Татар милли хәрәкәте лидерларыннан берсе.

Басылган әсәрләре: «Мәгыйшәт», милли хикәя (1898 елда язылган), 78 бит, Казан, 1900 (икенче басмасы — 1914); «Тәрҗеман руси» (Краткий практический учебник русского языка), 60 бит, Казан, 1990; «Англиягә сәяхәт» (Дәүләт Думасы депутатлары составында Англиягә барып кайтуы турында, 1909 елда язылган), 146 бит, Казан, 1912.

1917 елны С. Максуди Уфада Милләт мәҗлесе тарафыннан Милли Идарәнең рәисе итеп сайлана. Милли Идарә туздырылгач, 1918 елны эмиграциягә китә.*

* 1918—24 еллар арасында С. Максуди Финляндия, Германия һәм Франциядә яши, ә 1925 елда Төркия президенты Мостафа Кемал Ататөрек (1881—1938) чакыруы буенча гаиләсе (хатыны һәм ике кызы) белән Төркиягә күченеп, гомеренең ахырынача шунда кала һәм иҗтимагый вә гыйльми-педагогик эшен дәвам иттерә: егерме елдан артык башта Анкара, аннан Истанбул университетларының юридик-хокук факультетлары профессоры булып эшли, Ататөрек заманында Төркия парламентына (Милли мәҗлесенә) ике тапкыр депутат итеп сайлана; хөкүмәт делегацияләре составында Милләтләр Лигасының Лондон, Глазго һәм Чехословакиядәге конгресслары эшендә катнаша; фән өлкәсендә төрки халыкларның тарихы, дәүләт һәм хокук, тел белеме, Шәрекъ халыкларының хокук фәне тарихы, философиясе һәм социология буенча күпсанлы хезмәтләрен яза. 1955 елда Истанбулда басылып чыккан **«Милләят тойгысының социологик әсаслары»** исемле күләмле китабы аның гыйльми хезмәтләреннән соңгысы була. Садри Максуди-Арсал («Арсал» — аның Төркиядә алган фамилиясе) 1957 елның 20 февралендә Истанбулда вафат була. (Әдип турында тулырак мәгълүматны кара: И. Таһиров. Парижда укыган Садри.— Соц. Татарстан, 1990, 27 май; Ә. Кәримуллин. Садри Максуди-Арсал.— Шәһри Казан, 1991, 21 май; шулай ук «Идел» журналының 1991 ел, 10—11 санында Ә. Кәримуллинның тагы бер мәкаләсе һәм С. Максудиның Дәүләт Думасында сөйләгән бер нотыгы урнаштырылган.)

МАКСУДИ Әхмәтһади Низаметдин улы (1868—1941) — педагог, тел галиме, нашир. Садри Максудиның бертуган абыйсы. Элекке Казан өязе Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда Күлбуе мәдрәсәсендә укый. 1894 елны Истанбулга китеп, анда алты ел укый. Кайтышында Кырымга тукталып, Бакчасарайдагы Зынҗырлы мәдрәсәсендә гарәп әдәбияты укыта. Шунда чагында Исмәгыйль Лимановтан (1871—1942) рус теленнән дәрес ала, Лимановның үзенә исә госманлы (төрек) теленнән дәрес бирә. 1902 елны Казанга кайта, экстерн тәртибендә рус теле учительлегенә имтихан тота. Казан университетының

6. «Татарстан» № 5. 81

«Әдәби сүзлек» кульъязмасының бер нөсхәсе Рәис Даутов тырышлыгы белән 1992–1994 елларда, өлешләп-өлешләп, «Татарстан» журналында басыла.

СОҢГЫ ХЕЗМӘТ

1960 нчы елларда «Казан утлары»нда Исмәгыйль Рәмиевнең чираттагы истәлеге басыла. Замандашлары – өлкән буын язучылар Нәкый Исәнбәт, Афзал Шамов, Әмирхан Еники, авторның энциклопедик белеменә сокланып, аңа татар әдәбияты һәм мәдәни хәрәкәте буенча кыскача белешмәлек төзергә киңәш итәләр. Галим-энциклопедист 1969 елның 13 маенда «Әдәби сүзлек» дигән хезмәтен төгәлләп, Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә тапшыра. Әмма үзе шул елның 28 декабрендә кинәт вафат була. Идарә, кульъязманы машинкада 3 данәдә бастырып, кызыксынган кешеләргә танышырга бирә.

Илдә сәяси вазгыять уңай якка үзгәргәч, Татарстан китап нәшриятына тапшырылган кульъязманың бер нөсхәсе Рәис Даутов тырышлыгы белән 1992–1994 елларда, өлешләп-өлешләп, «Татарстан» журналында басыла.

Үзе Мәскәүгә кызы янына күченер алдыннан, Рәмиевнең хатыны Камәр ханым Рәис Даутовка иренең шәхси архивын тапшыра. Шул архивтагы кешеләр һәм репрессияләнгән шәхесләр турында яңа материаллар кертелеп, булган текстның кайбер урыннары баетылып, бу хезмәт уртак авторлыкта 2011 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә.

Бүген татар мәдәнияте тарихын өйрәнүче галимнәрнең өстәл китабына әверелгән бу басмада алфавит тәртибендә урнаштырылган 500 гә якын мәкалә-язма тупланган. Россиянең төрле шәһәрләрендә һәм чит илләрдә югары белем алган татар кешеләре, чиновниклары, дәрәҗәле хәрбиләре исемлеге, шулай ук 1917 елга кадәр төрки халыклар яшәгән төбәкләрдә нәшер ителгән газета-журнал атамалары кушымта рәвешендә урнаштырылган.

«МЕНДЕМ КОЯШКА АШКЫНЫП...»

Луиза Янсуар

Бу саннан башлап, «Татарстан» журналы татар язучылары, фән һәм сәнгать әһелләре туган, эшчәнлеген алып барган төбәкләрне барлап, мәдәни карта төзергә кереште. Татар дөньясына күренекле шәхесләрне, хәзерге тел белән әйтсәк, милли кадрларны биргән төбәкләр Россия һәм дөнья буйлап таралган. Узган гасыр башына кадәр андый мәдәни учаклар берничә була – Оренбург, Уфа, Уральск, Петербург, Троицк, Орск һ.б.

Беренче сәхифәне татар-башкорт дөньясының фаҗигале язмышлы, әмма кыска гына гомере эчендә кометадай балкып узган шәхесе Шәехзадә Бабичка багышлыйбыз. 14 гыйнварда аның тууына 130 ел тула.

ИДЕЛ ЯРЛАРЫННАН – АГЫЙДЕЛГӘ

Бабичлар – Башкортостан җирендә элек-электән билгеле нәсел. Чыгышлары буенча – Казан артыннан. Нәсел атасы Мохтар баба кайчандыр Казан якларында фабрика-мастерскойлар тота, соңрак Башкортстанның Агыйдел буйларына килеп чыга. Хатынлыкка чибәрлеге белән дан тоткан башкорт кызын ала. Аларның биш уллары туа – Илекәй, Ишкилде, Ишбулды, Ишалды һәм Гайнулла.

Мохтар баба дәүләтле һәм укымышлы кеше була, улларына кечкенәдән төпле белем, һөнәр бирү ягын кайгырта. Биш улы да билгеле кешеләр булып җитешә. Бертуганнарның Ишбулды дигәне Агыйдел буендагы Кыйгазытамакка мулла итеп куела. Киләчәктә татар-башкорт дөньясына танылачак шагыйрь Шәехзадә Бабичның нәсел җебе әнә шул Ишбулды тамырыннан башлана.

ЯРЛЫЛАРНЫ ЯКЛАУЧЫ

Ишбулдының оныгы Мөхәммәтзакир сигез яшендә ятим кала. Аны энисе ягыннан тирәюньдә «ак бабай» буларак танылган Әхмәт бабай тәрбия кылып үстерә. Ул оныгын Әсән авылы мәдрәсәсенә укырга илтә. Мәдрәсә программасын алданрак тәмамлаган белемле малайны хәлфә итеп куялар. Соңрак ул икенче мәхәллә мәдрәсәсенең мулласы, мөдәррисе һәм имамы итеп билгеләнә.

Мөхәммәтзакир мулла үз гомерендә өч мәртәбә өйләнә. Беренче һәм икенче хатыннары авырып дөнья куя, унҗиде баласы була. Шәехзадә – өченче хатыны Бибисаҗидәбануның иң олы улы.

Мөхәммәтзакир мулла гадел, туры сүзле, ярлыларга мәрхәмәтле булуы белән аерылып тора. Ярлыларны кыерсытучыларны яклый. Ул Әсәндә зур китапханә оештыра, бакча үстерә, сабын кайнату белән шөгыльләнә. Шул чордагы барлык газета-журналларны алдырып бара, үз заманының алдынгы фикерле кешеләре белән аралаша, китаплар яздырып китертә, аларны балаларына, халыкка кычкырып укый. Җыеннарда дөнья хәлләрен аңлатып бирүче, «акны карадан аеручы хәзрәт» буларак танила.

КАНАТЛЫ МАНДОЛИНА

Шәехзадә 1895 елның 14 (2) гыйнварында Уфа губернасы Бөре өязенең Әсән авылында дөньяга килә. Кечкенәдән хөрлектә, иркенлектә үсә. Бөтен авыл халкын таң калдыра торган җырлар-бәетләр чыгара, бакчаларындагы иң биек өянкегә эленгән асма бишектә такмаклар яза. Яраткан мавыгуларының тагын берсе – «театр» уйнау.

Иллюстрацияләр millattashlar.ru; durtulicbs.ru сайтларыннан алынды



Шәехзадә мәдрәсәгә кергәнче үк, Бабичлар йортында «концертлар» куела башлый. Мондый кичәләр күбрәк Мөхәммәтзакир хәзрәт Дүртөйле бистәсенә яисә Уфага киткән көннәрдә оештырыла. Шәехзадә абыйсы Фәтхелкадир, күршеләре Шакир-гармунчы һәм Рәхимҗан-җырчы белән, сәгатьләр буе скрипка сызгыртып, гармун тартып, җыр көйләп, такмаклар әйтеп утыра. Шулай да иң яраткан уен коралы мандолина була. Ул аңа илаһи бер әйбергә караган кебек карый – сатып алганда ук аның «канатлы» булуын тели. Андый мандолиналарны бик сирәк осталар гына эшли торган булган. «Концертларда» кызлар, яшь киленнәр, эбиләр булып, мулла-мөәзиннәр кебек, башларына сөлге урап, көлке тамашалар кора. Тамашачылар – тирә-күршедән җыелган балалар, абыстайлар, хәлфәләреннән качып кергән шәкертләр.

Уку яшенә кергәч, Закир мулла улын җәдит мәдрәсәсенә бирә. Бабичларның зур китапханәсенә дә юл ачыла аңа – шунда ул матбугат, әдәбият белән очраша, Тукай шигырьләрен укып соклана.

«БАБИЧ ТЕАТРЫ»

300 ләп шәкерт укыган мәдрәсәдә 1904–1906 еллар тирәсендә чып-чын татар театры барлыкка килә. Бабич бик тиз арада аның җанына әверелә. «Бабич театры»нда күбрәк көлкеле сәхнә күренешләре күрсәтелә. Шәкертләр байлардан, ялган руханилардан, исерекләрдән, наданнардан, яшь киленнәрдән, гайбәтче хатыннардан көләләр. Күпчелек күренешләрне Бабич үзе уйлап чыгара, спектакль барганда Шакир-шәкерт үзенең «Саратов» гармунында уйнап тора. Бөтен рольләрдә дә егетләр уйный.

Каян килгән соң Әсәнгә театр шаукымы? Татар дөньясында театр сәнгате аякка баса башлаган вакыт бу. Казанда, Оренбургта татарча спектакльләр куела. Бу хакта газета-журналлар хәбәр итеп тора. Мәдрәсәне тотучы бай, меценат һәм депутат Сәхибзадә Максудов та үзе булган шәһәрләрдә, шул ук Санкт-Петербургта, чын театрларны күреп кайта. Казаннан килеп укыта башлаган мөгаллимнәр дә үзләре белән «театр рухы» алып килә.

Әсән авылыннан чыккан Рахман Сафа дигән кеше Казанда бер типографиядә хезмәт итә. Кайтканда мәдрәсәгә кереп йөри. Бабичларда кич утырганда, Казанда оешкан беренче театрлар хакында сөйли. Шәехзадә Галиәсгар Камалның «Беренче театр» әсәре турында аңардан ишетә.

Бабичларның рухи дөньясын татар дөньясындагы мәдәни казанышлар белән бәйләп торган тагын бер кеше – Орск шәһәрендә Шәрекъ көтепханәсе тоткан Әхмәт Исхакый. Бу татар зыялысы, авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә йөреп, китап, календарь, газета-журнал тарата, Уфа – Казан юлында урнашкан Әсән авылында да кунып киткәли. Имеш, Исхакый пьесаларын да Шәехзадәгә ул биреп китә.

Вакыты-вакыты белән «Бабич театры»на куркыныч янап алгалый. Кадим мәхәллә имамнары аны «шайтан почмагы» дип атый, әзәрлекли. Ә бит Шәехзадәнең әнкәсе Бибисаҗидәбану – шул кадим якның баш имамы Мөхәммәтһадинең яраткан кызы. Кадимчеләрнең астыртын эшләре 1904 елның Сабан туеннан соң халыкка мәгълүм була. Нәкъ шул җыенда Мөхәммәтзакир хәзрәт дөнья хәлләре, әхлак турында вәгазь сөйли, халык җырларын башкаручыларга бүләкләр өләшә, ярлыларга хәер тарата. Шунда ук японнар



белән сугыш юньлегә илтмәячәген дә белдерә. Мәдрәсәдәге «шайтан туе»на чик куя алмагач, кадимчеләр дошман якка сәяси ялa ягa. 1904 елның 16 октябрендә, Шәехзадәгә 10 яшь тулганда, Әсәндә эчеп-исереп йөргән белән дан алган бер бәндә: «Мөхәммәтзакир хәзрәт сугышта Россиянең җиңелүен, японнарның җиңүен теләде», – дип, губернаторга хат юллый.

Мөхәммәтзакирны кулга алып, Бөре шәһәренә төрмәгә ябалар. Указын алдыралар. Ярдәмгә Сәхибзадә Максудов килә. Губернаторга мөрәҗәгать итә. 1905 елның башында хәзрәт авылга кайтып төшә, указы да кире кайтарыла.

«КОЙКЫ КОЛАК МУЛЛА»

1910 елның язында Шәехзадә Бабич «Мәдрәсәи Максуди»ны тәмамлап чыга. Атасының фатихасын алып, күрше авылдагы Зәки шәкерткә ияреп, казах далаларына мөгаллимлек итәргә чыгып китә. Май аеның кояшлы көнендә, бер кулына китаплар белән шыплап тулган кәрзинен, икенче кулына канатлы мандолинасын тотып, Казахстанның Тургай өлкәсенә кергән Дүсәнбай авылына килеп төшә һәм Мортаза исемле, заманасы өчен укымышлы гына сәүдәгәрдә туктый. Килеп төшү белән, кечкенә алачыкта балалар укытырга керешә.

Ул вакытта казах ягында балалар мәктәпкә җәй айларында йөриләр. Чөнки аларны җәйге яллары вакытында акча эшләү нияте белән килгән татар хәлфәләре, татар шәкертләре укыта. Хәреф таныган, дини йоланы башкара белгән муллаларга да кытлык. Шәехзадә бер үк вакытта мулла вазыйфаларын да башкарырга тиеш була.

Ләкин 15 яшьлек мулла, кул кушырып, дога кылып кына утырмый, халык белән аралаша, мәкаль-әйтемнәр җыя, йола уеннарында катнаша, үзе тамашалар оештыра, концертлар куя, шигырьләр яза. Мәшһүр казах шагыйре Абай Кунанбаевның иҗатын үз итә, Абайны рухи остазлары рәтенә куя. Анда яшәгәндә, кечкенәдән җырлап, көйләп үскән татар, башкорт көйләренә үзе дә җыр-шигырьләр язып, чичәннәр кебек көйләп йөри башлый. Дүсәнбай авылында төзи башлаган «Кульязма шигырьләр» җыентыгында халык көйләренә язылган шигъри язмалары байтак. Казахлар Бабичны, яратып, «койкы колак мулла» дип йөртәләр. Шәехзадәнең тырпаеп торган колагына ишарә инде бу.

Казах далалары Бабичны искиткеч рухландыра – ул ныклап шигърият белән мавыга башлый, такмакларын ташлап, җитди шигырьләр, парчалар, эпиграммалар язуга күчә. Тиздән бу шөгыль аның гомерлек максатына әверелә.

«ГАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ШӘКЕРТЕ

1911 елда Шәехзадә, Уфага килеп, атаклы «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Беренче сыйныфта укыганда ук Бабич үзенең тәүге шигырьләр җыентыгын әзерли, аңа «Әйтеп узыйм» дип үзе үк сүз башы да яза. Әмма билгесез сәбәпләр аркасында, бу китап дөнья күрми кала.

1912–1913 елларда Бабич халык иҗаты белән кызыксынып китә. 1913 елда Троицкида чыгып килә торган «Акмулла» журналының берничә санында «Мәкальләр фәлсәфәсе» дигән цикл бастырып чыгара. Мәкальләрнең «мәгънәләрен, тәрбияләрен, фәлсәфәләрен» аңлатырга тырыша. Рухланып китеп, татар-башкорт көйләрен өйрәнә, аларның тарихларын язып чыга. Үзенең фольклор белән мавыгуын алга таба да дәвам итәргә, фәнни нигезле итеп хезмәтләр язарга хыяллана.

1913 еллардан Бабич исеме мәртәбәле «Шура» (Оренбург) журналында күренә башлый. Ләкин биредә ул фольклорчы, фельетончы буларак түгел, ә беренче мәртәбә шагыйрь буларак «аваз сала».

Шәехзадә «Галия»дә иң билгеле шәкертләрнең берсенә әверелә. Фикердәшләре белән берлектә «Парлак» кульязма әдәби журналы чыгара, аның мөхәррире вазыйфасын башкара. Моннан тыш, Шәехзадә «Милли көй, сәхнә вә әдәбият» түгәрәге җитәкчеләренең берсе була, мәдрәсәнең зур кыллы оркестрында беренче мандолиначы булып таныла. Әдәби-музыкаль кичәләрне оештыручыларның мәдрәсә идарәсенә җибәрелә торган делегация әгъзаларының иң активына, башлап йөрүчесенә әверелә. Үзе дә яшерен түгәрәк оештыра, Хәсән Туфан да беренче иҗат адымнарын шунда ясый.

ҮЗ ЧОРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕЛӘРЕ

Озак та үтми, Бабичның эшчәнлеге мәдрәсә кысаларына гына сыймый башлый. Дворяннар сарае һәм башка мәдәният учакларында уздырыла торган барлык кичәләрдә дә диярлек катнаша ул: үз шигырьләрен укый, конферансье вазыйфасын үти, спектакльләрдә рольләр дә уйный. 1916 елда Уфага килгән Габдулла Кариев белән берлектә аның берничә спектакль куюы мәгълүм. Соңрак Бабич җырчы Газиз Әлмөхәммәдов белән бергә концертлар оештыра башлый. Шундый бер концерт программасы белән Мәскәүгә барырга җыенулары хакында да истәлекләр теркәлеп калган.

Шәехзадә, нәрсәгә генә тотынса да, моңарчы беркем эшләп карамаганча эшләргә омтыла. Төрки-татар дөньясында, беренчеләрдән булып, концерт алып баручылар, артистларга программа төзегәндә ярдәм итәр өчен, төрле авторларның әсәрләрен туплап, «Көлке капчыгы» җыентыгы чыгара.

> КӨЛКЕ КЕШЕНЕ РӘХӘТЛӘНДЕРӘ, КҮҢЕЛНЕ АЧА, ЭЧ ПОШУНЫ БАСА, ҖИТДИ НӘРСӘЛӘРНЕ ТЫҢЛАРГА БӨЕК БЕР ТЕЛӘК УЯТА, ЯЛЫККАН КЕШЕЛӘРНЕ ҖИҢЕЛӘЙТЕП ҖИБӘРӘ.
>
> **Шәехзадә Бабич**

«Галия»дә уку дәверендә Шәехзадә XX гасыр башында үз заманының мәдәни өлкәсендә «беренчеләрдән» булган иң асыл шәхесләр белән аралышып яши. Алар арасында татар, башкорт, казах әдипләре, музыкантлары, артистлары, мәгърифәтчеләре бар. Уфадагы әдәби хәрәкәт Мәҗит Гафури тирәсендә тупланган була. «Галия»нең тынгысыз, талантлы шәкерте дә шулар арасына керергә омтыла. Алар Гафури белән аралаша башлыйлар, дуслашып китәләр. 1914 елда Уфага Сәгыйть Рәмиев килгәч, Бабич аның белән танышу юлларын эзләргә керешә, шулай ук дуслашып китәләр. Нәҗип Думави, Сәгыйть Сүнчәләй, Зариф Бәшири белән дә аралашып яши.

ГАЛИМҖАН АГА КАНАТЫ АСТЫНДА

1915 елда Уфага кайткан Галимҗан Ибраһимовны шәкертләр үтенече буенча «Галия»гә татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп чакыралар. Бу Бабич тормышында хәлиткеч очрашу була. Яшь егетнең иҗатына, фикер сөрешенә зур йогынты ясаган һәм аңа рухи кыйбла биргән кеше, асылда, Галимҗан Ибраһимов була. Ул егетнең талантын да, бу талантның масштабын да шунда ук күреп ала.

> БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУЫМ УФАДА «ГАЛИЯ»ДӘ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ УКЫТКАН ЧАГЫМДА БУЛДЫ. УЛ ТӘКЪРИР (ИНША) ӨЧЕН БИРЕЛГӘН МАУЗУГ (ТЕМАЛАРНЫ ДА, ПЛАННЫ ДА) ФАЙДАЛАНЫП, ШУНДЫЙ КЫЙММӘТЛЕ ЧАТКЫЛАР ЧӘЧРӘТӘ ИДЕ КИ, ӘДӘБИ ЗӘВЫКЛЫЛАР ӨЧЕН АНЫҢ СЫЙНЫФ ТӘХРИРЛӘРЕННӘН ЯЛТЫРАГАН ИСТИГЪДАДЫ (СӘЛӘТЛЕЛЕГЕ) БЕЛӘН СИХЕРЛӘНМӘСКӘ МӨМКИН ТҮГЕЛ ИДЕ. ҺӘМ ШУЛ ВАКЫТТА МИН АҢА ҮЗЕНДӘГЕ ТАБИГЫЙ ТАЛАНТНЫҢ ҮСҮЕНӘ ЯРДӘМ БИРЕР ДИП УЙЛАГАН ЧАРАЛАРНЫ КЫЛЫРГА ТЫРЫШТЫМ.
>
> **Галимҗан Ибраһимов**

Шәехзадә Бабичның бу чорда «Чыңгыз хан» исемле әсәр язганы турында мәгълүмат бар. Имеш, аны югары бәяләп, Галимҗан Ибраһимов матбугатка бастырырга да бирергә тәкъдим иткән, әмма кульязмалары сакланып калмаган һәм бу әсәр билгеле түгел. Шулай ук ул шигырьләрен дә гаять тәэсирле яза башлады, дип искә ала сабакташлары яшь Бабич турында.

«Галия» мәдрәсәсен алты ел урынына биш елда бик уңышлы тәмамлап чыкканнан соң, Шәехзадә Бабич балалар укыта, «Аң» (Казан), «Шура» (Оренбург), «Кармак» (Оренбург), «Сүз» (Мәскәү), «Тормыш» (Уфа) кебек газета-журналларда актив язышa, Агыйдел елгасында салчылар җитәкчесе булып эшли.

ҖИЛ-ҖИЛ АТЛАП, ЯҢА КИЛӘЧӘККӘ...

1916 елның көзендә Бабич Троицк шәһәренә укытучы булып китә. Февраль революциясен шунда каршылый, аңа зур өметләр баглый.

> 1917 ЕЛДА ПАТШАНЫ ТӨШЕРГӘН КӨННӘРДӘ АНЫҢ ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ ШАТЛАНЫП ЙӨРҮЛӘРЕ ҺӘМ ДЕМОНСТРАЦИЯ ВАКЫТЫНДА КУЛЫНА КЫЗЫЛ БАЙРАК ТОТКАН ХӘЛДӘ ҖИЛ-ҖИЛ АТЛАП БАРУЛАРЫ ӘЛЕ ДӘ КҮЗ АЛДЫНДА.
>
> **Сәрвәр Әдһәмова**

Революция тәэсирендә Бабич ныклап журналистика эшенә тотына, Әхмәт Таҗетдин Рахманкулов дигән журналист белән «Хөр милләт» газетасы да чыгарып йөри. Газетаның беренче санында шагыйрьнең «Яшәсен эшчеләр!» шигыре басылып чыга. Бабич, Сәйфи Кудаш, Җамалетдин Юмаев һәм үз шигырьләрен туплап, «Шигырьләр мәҗмугасы» төзеп бастыра.

Галимҗан Ибраһимов белән хат алышып тора. 1917 елның июнь ахырында, остазы дәшкәч, Уфага кайта һәм «Ирек» газетасында языша башлый. «Яшь шагыйремездән Шәехзадә Бабич та Троицкидан Уфага кайтты», – дип хәбәр итә Галимҗан Ибраһимов газета битләрендә. Уфада Бабич социалистлар белән бергә эшли, әдәбият кичәләрендә татар буржуазиясеннән ачы көлеп шигырьләрен, сатира үрнәкләрен укый, газетада да буржуазия белән байларны каһәрләп яза, революция каһарманнарына дан җырлый.

Уфада ул озак тормый, аны 150 сум эш хакы вәгъдә итеп, сатирага һәвәслеген исәптә тотып, Мәхмүт Галәү «Кармак» журналына эшкә чакырып ала. Матди хәле мактанырлык булмаган Бабич ризалаша, августта Оренбургка барып урнаша, эшкә чума. Матбугат эшчәнлегеннән тыш, активлыгын монда да туктатмый – концертлар бирә, кичәләр уздыра, әдәби түгәрәк оештырып җибәрә. Оренбургта Бабичның күптәнге хыялы чынга аша: шагыйрь Төхвәт Ченәкәй аны Дәрдемәнд белән таныштыра.

Бабич бу чорда үзен чолгап алган иҗтимагый вакыйгаларга катлаулы, каршылыклы мөнәсәбәттә тора, юкка гына ул «һич тотар хәл юк керәелнең тезгенен, һич белер хәл юк фикернең төзлеген» дип язып калдырмагандыр.

«МИЛЛӘТЕМНӘН, ХАЛКЫМНАН ВАЗ КИЧМӘЯЧӘКМЕН!»

1917 елның көзеннән алып 1919 елның мартына кадәрге чор – Бабичны бөеклеккә дә, фаҗигагә дә илткән чор. Ул вакытта Оренбургтагы сәяси аренада бик тә төрле затлар эш алып бара: большевиклар (кызыл гаскәрләр), Башкорт автономиясе вәкилләре (башкорт полклары), латыш укчылары, дутовчылар, акгвардиячеләр, Колчак иярченнәре.

1917 елның ахырында бунтарь Бабичны ярсу йөрәге башкорт милли хәрәкәте сафларына алып килә. Башта ул эзләгәнен тапкандай була, күңеле юана – «иҗтимагый хакыйкатьне» милли лозунглар, трибун чыгышлар чагылдыра, дип ышана. Әлбәттә, кулына корал тотып йөрми, окопларда ятмый. Автономиянең матбугаты өчен җаваплы була. Ә матбугат – көчле корал. Ул башкорт хөкүмәтенең төп органы – «Башкортостан» газетасын чыгаруда актив катнаша. Публицистик мәкаләләрен, сәяси мөрәҗәгатьләрен, ялкынлы шигырьләренең күбесен башкорт телендә яза. Әлеге катлаулы чорны өйрәнүче тарихчыларның фикере уртак: башкорт халкы милли хәрәкәтне хуплап каршы алган, аңа һәрьяклап ярдәм итәргә тырышкан. Бу хәрәкәттә Бабич кебек фигураның да булуы хәлиткеч роль уйнаган.

Бик күп икеләнүләр һәм авыр югалтулардан соң, Зәки Вәлиди Хөкүмәте 1919 елның башында кызыллар ягына чыга, бу гамәлен Шәехзадә Бабичның поэма-мөрәҗәгате белән игълан итә: «Без ник кызылларга кушылдык?» Темәс авылында Кече Башкортостан автономияле республикасы игълан ителә. Бабич матбугат эшләре буенча Башревком инструкторы итеп билгеләнә. Газета чыгару, листовкалар басу, гомумән, бөтен типография эшчәнлеге аңа йөкләнә.

Башревком типографиясен Габделхәй Иркәбаев дигән хезмәттәше белән бергә Темәстән Кызыл Мәчеткә (Мраково ягына) алып барганда, Зилаир бистәсендә урнашкан кызыл гаскәрләрнең Смоленск полкы шовинистлары Бабичны эләктереп ала. Аны бик озак җәзалыйлар. Бары бер генә сорау бирәләр: «Үз милли идеяләреңнән баш тартасыңмы-юкмы?» «Әйе» дисә, җибәрерләр иде, бәлки. Ләкин шагыйрь: «Мин милләтемнән, халкымнан бервакытта да ваз кичмәячәкмен!» – дип җавап бирә.

Аны зинданга ябып тоталар, кыйныйлар, күзләрен чокып, колакларын кисеп алалар, әмма Бабич милли идеяләреннән ваз кичми. Шуннан соң шагыйрьнең канга баткан гәүдәсен ат койрыгына тагып, Зилаирның ташлы урамнары буйлап йөртәләр.

...Аңа әле нибары 24 яшь кенә була.

КОНКУРС

«ГЕРОЙЛАР ЯНӘШӘДӘ» – «ГЕРОИ РЯДОМ»

Татарстанда патриотик юнәлештәге «Геройлар янәшәдә» – «Герои рядом» ачык әдәби конкурсында катнашу өчен гаризалар кабул ителә. Ул традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне һәм патриотизмны үстерү максатында үткәрелә.

Конкурста 2022 елдан бирле язылган һәм махсус операция бурычларын үтәү барышында татарстанлыларның фидакарьлеген, батырлыгын, каһарманлыгын чагылдырган әдәби әсәрләр катнаша ала.

Гаризалар 2025 елның 31 мартына кадәр дүрт номинация буенча татар һәм рус телләрендә кабул ителәчәк:

«ПОВЕСТЬ»:

1 урын – 300 мең сум (ике премия);
2 урын – 200 мең сум (ике премия);
3 урын – 150 мең сум (ике премия).

Шулай ук һәрберсе 50 шәр мең сум күләмендәге дүрт кызыксындыру премиясе һәм 52 750 сум күләмендә тагын ике кызыксындыру премиясе тапшыру каралган.

«ХИКӘЯ»:

1 урын – 120 мең сум (ике премия);
2 урын – 70 мең сум (ике премия);
3 урын – 55 мең сум (ике премия).

Шулай ук һәрберсе 35 әр мең сум күләмендә тагын алты кызыксындыру премиясе тапшыру каралган.

«ПОЭМА ЯКИ ШИГЫРЬЛӘР ЦИКЛЫ»:

1 урын – 150 мең сум (ике премия);
2 урын – 100 мең сум (ике премия);
3 урын – 70 мең сум (ике премия).

Шулай ук һәрберсе 40 шар мең сум күләмендә тагын алты премия тапшыру каралган.

ОЧЕРК:

1 урын – 120 мең сум (ике премия);
2 урын – 70 мең сум (ике премия);
3 урын – 55 мең сум (ике премия).

Шулай ук һәрберсе 35 әр мең күләмендә тагын алты кызыксындыру премиясе тапшыру каралган.

Премиянең салым алынганнан соңгы күләме күрсәтелгән.

Шулай ук **«Әдәбият аша Татарстан Республикасында патриотик тәрбиягә кертелгән өлеш»** номинациясендә бөтен әдәби эшчәнлеге чорында хәрби-патриотик тематиканы үстерү юнәлешендә автор тарафыннан башкарылган эш бәяләнә.

Әлеге номинациядә приз – 1,35 млн сум.

Гаризаны **«Геройлар янәшәдә» – «Герои рядом»** патриотик юнәлешендәге ачык әдәби конкурс» тамгасы белән litkonkurs.tatmedia@mail.ru электрон почта адресына юлларга мөмкин.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 570-31-12.

Конкурста җиңүчеләрне 2025 елның 12 июнендә булачак бүләкләү тантанасында игълан итәчәкләр.

Конкурсны «ТАТМЕДИА» АҖ һәм «Татарстан китап нәшрияты» ДУП ярдәмендә «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы оештыра.

«ТУГАН БАТЫР»:
КАҺАРМАННАР ЗАМАНЫ ҖИТТЕ

Дмитрий Сивков

Әлеге әкиятне тудыручыларның исемнәре кайчандыр Камыр батыр белән Святогорны язып калдыручыларныкы кебек онытылмаячак, монысы – көн кебек ачык. Яңа татар мультипликация каһарманының «әти-әниләре» генә түгел, туган көне дә билгеле – 2024 елның 24 декабре.

Туган Батыр образын тудырыр өчен нейрочелтәрне ярдәмгә чакырганнар. Ул, дөнья буйлап балаларның миллионлаган фотографияләрен җыеп, шул сурәтләрне берләштереп, без белгән каһарманны барлыкка китергән.

ӘКИЯТ ТУРЫНДА КЫЙССА

Моннан да халыкчанрак кыйссаны табуы кыен булыр... Шекспирның «моннан да сагышлырак повестьне табуы кыен» дигән юлларын искә төшерик тә, татар супергерое турындагы бәянгә күчик. Туган Батыр образы һәм аны әйләндереп алган дөнья – ул моңа кадәр булган барлык татар халык әкиятләре белән мифлары, риваятьләре кушылмасы. Татар «супермены»ның гәүдәләнешенә килсәк, биредә авторлар гына көч куеп калмый, ә тарих, фольклор, әдәбият, корал куллану һәм заманча брендинг буенча консультантлар командасы да җиң сызганып эшли.

Җитди якын киләләр, озын сүзнең кыскасы. Проектның авторлары да үз алдына бик җитди бурычлар куя: үсеп килүче буын өчен кызыклы булырдай милли каһарман образын тудыру, буыннар арасындагы бәйләнешне исәптә тоту, туган мәдәниятеңә, аның традицияләренә тугрылык саклау, туган туфракка ышаныч һәм мәхәббәт тәрбияләү. Аннан да бигрәк, Туган Батыр татар мәдәниятен генә түгел, ә Россия мәдәниятен дә халыкара дәрәҗәдә яклаучы, башкаларга илһамландыручы амбассадор булырга тиешле, дип ниятләнә.

Мондый максатка ирешү бары тик бер генә кеше кулыннан килә торган нәрсә түгел, билгеле. «Туган Батыр» очрагында бик файдалы һәм бәрәкәтле өчлек үз ролен уйный – бизнес, иҗат һәм рухият. Проект – «Туган Авылым» милли-туристик комплексына нигез салучыларның берсе Радик Абдрахманов, Татарстанның халык язучысы Зөлфәт Хәким һәм ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин инициативасы.

Фото: Александра Живушкина. 6+

Чынлыкта, Көнбатыштан үтеп кергән һәм балалар белән үсмерләр арасында гаять популяр булган Бэтмен, Үрмәкүч-Кеше һәм Коише каһарманнарны алыштыра алырдай милли образ турындагы идеяне Камил хәзрәт әйтә. Сюжетка тылсымлы Зихгир бөҗрасын кертеп җибәрү дә – аның тәкъдиме. Зөлфәт Хәким – бөтен батырлыклары туган илгә, гаилә һәм дусларына мәхәббәт белән сугарылган Туган Батыр турындагы тарихларны иҗат итүче. Радик Абдрахманов исә проектның матди ягын һәм танылуын, алгарышын үз өстенә алган. Әкияттән төшмәсәләр дә, әкияти эшләр башкарып чыккан әлеге өч баһадирның тәвәккәлеге нәтиҗәсендә, «Туган Батыр» дөньяга туган да инде.

Сүз уңаеннан, китапны әле ниятләгән чакта ук ике телдә – татарча һәм русча язарга уйлыйлар. Зөлфәт Хәким татарча яза, шуннан соң аларны үзе үк русчага тәрҗемә итә. Әмма инде беренче китап шулай ук инглиз, гарәп, төрек, казах телләрендә дә басылып чыга, алар барысы да бер томга туплана. Икенче китапны татар теленнән биш телгә тәрҗемә итәләр, әмма һәр тәрҗемә аерым китап булып басыла. Өченче китап та – нәкъ шулай. Ә хәзер менә инде мультфильмга да вакыт килеп җиткән. Премьерасы декабрь азагында Казандагы кинотеатрларның берсендә ябык карау вакытында тәкъдим ителде.

СЕЗНЕ СЮРПРИЗЛАР КӨТӘ

Мультимедиа форматы проектны таныткканда басма продукциягә караганда күпкә үтемлерәк. Җитмәсә, илебез мультипликация тарихында бик уңышлы сериаллар үрнәге бар, шул исәптән Көнбатышта да билгеле. Проект командасына нәкъ менә шундый югары дәрәҗәдәге продукт булдыру кызыклы. Алар үзләренә ориентир итеп иң шәп белгечләрне һәм эшләрне алган. Үз планнарын сер итеп саклауны кирәк тапмый, алар белән бик теләп уртаклаша Радик Абдрахманов.

– Беренче сезонда без 52 серия чыгарырга ниятлибез, хронометраж ягыннан – һәрберсе 6,5 минутлык. Аннары инде шуның нигезендә тулы метрлы фильм чыгарасы килә. Икенче, өченче сезоннар да булыр, дип фаразлыйбыз, – дип сөйләде ул «Татарстан» журналы хәбәрчесенә ябык караудан соң.

– Залда Туган Батырны Зөлфәт Хәким китаплары аша белеп өлгергән өлкәннәр һәм балалар күп иде. Аларга мультсериал белән тулы метрлы версияне карау инде кызыксыз булмасмы? Ни дисәң дә, әкиятнең ничек дәвам итәсен һәм тәмамланасын беләләр бит...

– Күңелсез һәм кызыксыз булмаячак, мин моны сезгә гарантияли алам. Сериалның сценарие китапныкыннан аерыла, әмма анда шул ук төп каһарман – Туган Батыр һәм аның тирәсендәге геройлар: явыз Сарыкан, Зихгир бөҗрасы, Гөлчәчәк, зирәк Галим бабай... Мультфильмда аларга яңа персонажлар да өстәләчәк.

– Мәсәлән, кемнәр?

– Алар бик күп! Безнең команда татар фольклорына баштанаяк кереп чумды. Анда шулкадәр күп универсаль әкият каһарманнары бар, без аларны белеп тә бетермибез икән! Тулы метрны Зөлфәт Хәким әсәренә нигезләнебрәк эшләячәкбез. Хәер, анда да барыбер безнең канатлы аждаһабыз – Зилант пәйда булачак. Сезне бик күп сюрпризлар көтә. Өстәвенә, тулы метр гәүдәләнеше ягыннан да сериал версиясеннән аерылып торачак, ябык карауга килүчеләр өчен бу – тагын бер яңалык.

– Яңа персонажлар кертү белән мавыгып китеп, проектның төп идеясен һәм асылын күз уңыннан ычкындыру куркынычы янамыймы?

– Юк. Сценарий белән безнең зур бер команда эшли, барлык идеяләр дә «коллектив аң» аша тикшерү уза, шулай ук балалардан торган фокус-төркем дә бар. Иң мөһиме – серияләр аларга ошарга тиеш, шулай ук мәгънәсе дә аларның күңеленә үтеп керергә. Әгәр дә моңа ирешәбез икән, димәк, барысын да дөрес эшлибез, дия алабыз.

КАҺАРМАННАР ЗАМАНЫ

– Иң баштан ук куелган максат – Көнбатыш геройларына капма-каршы каһарман тудыру теләге сәнгати алымнарга хилафлык китермәсме?

– Сез безнең идеологияне күздә тотып әйтәсезме? Ул бик гади һәм аңлаешлы, проектның аерылгысыз өлешен тәшкил итеп тора. Без традицион гаилә һәм кешелек кыйммәтләренә акцент ясыйбыз. Көнбатышта аларның асылы шикле, ә бездә ул кыйммәтләр җәмгыятьнең нигезендә ята: бу ата-бабаларга ихтирам, Туган илне һәм гаиләңне ярату, аңа тугрылык, юмартлык... Безнең генотипка нәрсә салынган, шуларның барысы да. Әйе, болар кайбер башка халыкларга, шулай ук Европа кешеләренә дә хас, диярсез, модада булган трендларга карамастан да...

– Халыкара базарда, мөгаен, иң беренче чиратта, Көнчыгыш илләренә йөз тотасыздыр?

– Әйе, төрки-көнчыгыш дөньяның үз заманча каһарманнары юк, шулай ук – көчле анимациясе дә. Шуңа да «Туган Батыр»ны гарәп илләрендә яратып кабул итәрләр, дип ышанып калабыз. Җитмәсә, без моңа нигез дә булдырдык – Туган Батырның иң якын дусты итеп, сюжетка лачынны керттек. Көнчыгышта бит лачыннар белән ау бик популяр.

Ә болай... без бар дөньяга ачык, Туган Батырның үзе кебек үк. Яңа елдан безнең онлайн-кинотеатрлар белән сөйләшүләр каралган. Федераль каналлардан күрсәтүне дә җайга салырга ниятлибез.

Китап белән мульфтильмда Туган Батыр явыз Карабаш белән комсыз Котсыз ханга, сихерче Сарыканга, урман юлбасарларына һәм башка төр көчләргә каршы тора икән, мәгълүмат киңлекләрендә аңа инде танылып өлгергән, яхшы рекламаланган «коллегалары» белән очрашырга туры киләчәк – Үрмәкүч-Кеше, Бэтмен, Наруто... Аңа уңыш телик!

Дөресен генә әйткәндә, бу тормышта безгә бүген чын әкиятләр җитми. Прагматик дөньяда аларга урын калмады, барысы да кулланучылык мөнәсәбәтләренә корылган. Туган Батыр белән аның дуслары әле бу мөнәсәбәтне бераз булса да үзгәртә алыр, дигән өмет бар. Каһарманнар заманы җитте.

Радик Абдрахманов ябык карауга килгән мәртәбәле кунаклар белән.

МӘРХӘМӘТКӘ ҺӘМ ЯРАТУГА ЧАКЫРУ, ЯКИ КЫШКЫ ИХЛАС КИТАПЛАР

Луиза Янсуар

Бу китапларның икесе дә гыйнвар салкыннарында безне җылытырга һәм күңелебезнең нечкә кылларын тибрәтергә сәләтле. Әйдәгез, хозурланыйк әле...

Фото: goodfon.ru, livelib.ru

ИРЕК ТУРЫНДА БЕЛМӘС ТӘ ИДЕЛӘР...

«Почтальонша», Франческа Джанноне, 2024

Тәрҗемә: Юлия Гармашова

Яшь итальян язучысы Франческа Джанноне иҗат иткән һәм, ниһаять, быел рус телендә дә дөнья күргән «Почтальонша» романы Италиянең үзендә чын мәгънәсендә әдәби сенсациягә әверелә. Дебют әсәре өчен һич көтелмәгәнчә, 580 000 мең нөсхәдә сатылып, 37 илдә нәшер итепергә хокук алына. Ул ике дәрәҗәле әдәби премиягә (Bancarella, Amo Questo Libro) ия, хәзерге вакытта аның буенча кино төшерергә әзерләнәләр.

Роман авторның үзе өчен бик кадерле гаилә тарихына нигезләнгән – бу аның әбисенең язмышы. Сюжет буенча, без 1934 елгы Италиягә кайтып, иренең туган туфрагына – илнең көньягына төпләнеп яшәр өчен килгән яшь ханым Анна белән танышабыз. Аннаның шәһәргә килүе шунда ук шау-шу тудыра: җирле халык аңа беренче көннән үк «килмешәк» («чужачка») дигән кушамат тага, төньякта тәрбияләнеп үскәне һәм үзен бөтенләй монда килешмәгәнчә тотканы өчен астыртын гына битәрләргә керешә. Җитмәсә, Анна – укымышлы, димәк ки, телиме-теләмиме, үзен «бездән өстен куя» дип исәпли күпләр. Ире Карло һәм бәләкәй улы Роберто белән дә үзен икенче төрле тота Анна. Башка хатыннар кебек, көн дә базарга йөрми, гайбәттә катнашмый, кухня колы булып, иртәдән кичкә кадәр пешеренми-юмый-чистартмый-агартмый... Йорт бакчасына чыгып, андагы агачларга хозурланып утырып... китап укый!

Үлгән агасының йортын мирас итеп алган Карло, кайтуга ук тик ятмыйча, йөзем үстерә башларга карар кыла. Аның үз фамилия шәрабен җитештерәсе килә, ул бу эш белән чын-чынлап янып йөрергә керешә. Кайчандыр яратышкан Кармелланың әтисе ишегең шакып, аңардан шәраб җитештерү серләренә өйрәтүен үтенә. Әмма бу ишекне шаку аның өчен эзсез үтми, үзеннән күпкә өлкәнрәк яшьтәге ире һәм үсеп килгән улы белән яшәп яткан Кармелла аны яңадан наз ятьмәләренә йолып ала. Җитмәсә, үткәннең эзләре шактый тирән ярылып калган булып чыга...

Менә шундый аңлаешсыз-сәеррәк көннәрнең берсендә Анна, берәү белән дә киңәш-табыш итеп тормыйча, почта бүлеге ишеген шакый. Шәһәрдә күп еллар буе эшләгән почтальонның үлеменнән соң, аңа алмаш эзләгән көннәре була почтаның. Укый-яза белгән кешенең килүенә куансалар да, ул укый-яза белүченең хатын-кыз булуына аптырарга да, аптырамаска да белми аның гаризасын кабул итүчеләр.

Патриархаль тәртипләре белән тыныч кына яшәгән Лицанелло өстенә, әйтерсең, бомба ташлыйлар – Аннаның почтальон формасы киеп, хатын-кыз башы белән почта таратырга чыгуы барысын да шок хәленә куя. Өйләрендә дә җәнҗал куба. Әмма биредә аны иренең абыйсы – Антонио яклап чыга.

Антонио Анна беренче мәртәбә биредә пәйда булган көннән... аннан күзен дә алмый. Бу икәүне, әйтерсең, күзгә күренми торган ниндидер серле җеп бәйләп тора. Әмма икесе дә, бу җепнең гаиләләренә, балаларына күпме кайгы-хәсрәт китерәсен аңлап, аны сизмәмешкә салышыбрак яшәвен дәвам итә. Антонио кинәт башына ишелеп төшкән бу вакытсыз һәм гөнаһлы мәхәббәттән читкә качып та карый, тик барыбер әйләнеп кайта. Аннадан гына түгел, иң беренче чиратта, үзеннән качып булмаячагын бик яхшы аңлый ул. Һәм үз өендә булмый торган арада гаиләсеннән никадәр бизүенә, аларның да аны терәк итеп тоймаска күнегүенә төшенә.

Әмма Анна белән Антонионы яшерен хис кенә түгел, ә тагын да куркынычрак һәм бөтенләй дәвалап булмый торган мавыгу берләштерә. Китапларга мәхәббәт! Һәм алар чынбарлыкта ирек бирә алмаган хисләрен дә шул китапларга күчереп, киная белән аңлашып, бер үк әсәрләрне параллель укып, юаныч алалар.

«Ох, бу Антонио һәм аның рус язучыларына булган мәхәббәте... Шулай бервакыт Анна аңардан сорады да: алар сиңа нәрсәсе белән шулкадәр ошый соң? Ә ул болай дип җавап бирде: рус язучылары кеше хәсрәтләрен башкаларга караганда иң яхшы сурәтләүче генә түгел, алар кеше хәленә керүне, икенче берәүнең кайгысын үзеңнекедәй кичерә белүне дә гаҗәеп чагылдыра. Рус язучыларын укыганнан соң, син үзеңне нииндидер гарип һәм кимчелекле итеп тоймыйсың, бары кеше генә икәнеңне аңлыйсың».

Әнә шул башкаларга охшамаган булуы Аннаны шәһәрдән берничә чакрым ераклыкта, Лиццанелло җәмгыятеннән читкә тибәрелеп яшәгән «сихерче» Джованна йортына алып бара. Аны укырга-язарга өйрәтергә өнди. Ире үз шәраб йортын ачып, карьера ясагач һәм шәһәр мэры вазыйфасына сайлауларга катнашырга ниятләгәч, бу карарга ачыктан-ачык каршы торырга, моны сафсата дип атарга да. «Донна Анна» шәрабе бөтен Италиядә танылып, инде дөнья күләмендә экспортка чыгарыла башлагач, муллыкка ирешкәч тә, барыбер җәяү һәм велосипедта теләсә нинди һава шартларында почта сумкасын асып өйдән чыгып китәргә дә. Укый-яза белмәгәннәргә хатлар язып кичләрен уздырырга, солдатларга әниләре, хатыннары исеменнән җаваплар сырларга, алар белән бергә көләргә-еларга... Шәһәр кешеләренең хатлардагы иң яшерен, кайчак хәтта хәвефле серләрен йөрәгенә сыйдырып, чит-ятка чыгармаска, үзенә йомып, аларның намусын, дәрәҗәсен, абруе белән исемен сакларга да.

20 ел буе почта тарата Анна үзен «килмешәк» дип тамгалаган шәһәрдә. Аның халкы белән бергә муллыкны да, юклыкны да кичерә, сугыш афәтен дә уздыра. Һәм, үзе дә абайламыйча, шәһәрдә хатын-кызларның хокукларын яклый, аларның тормышына уңайлыклар кертә, тулы бер гаиләләрнең, династияләрнең язмышларын хәл итә. Хәтта урыны-урыны белән «көньяк менталитетын» да үзгәртеп кора.

Аннаны соңгы юлга озатырга җыелгач, тын гына әнә шуларны уйлана һәм ваемлап ала Лиццанелло кешеләре табуты алдында. Асылда, аның бу шәһәргә алар барлыгын да белмәгән ирек һәм ярату алып килгәнен.

ХОМО ДЕЛЬФИНУС, ЯКИ БЕЗ АЧАРГА ТИЕШ ДӨНЬЯ

«С дельфинами. Навстречу удивительным существам», Фабьенн Дельфур, 2024

Тәрҗемә: Настасья Вахтина

Фабьенн Дельфур – белеме буенча этолог һәм цетолог (китсыманнарны өйрәнүче), когнитив этология докторы, Франциядәге «Астерикс» паркы җитәкчесе, Париж университетының Эксперименталь һәм чагыштырма этология лабораториясе фәнни хезмәткәре. Тулузадагы Милли ветеринария мәктәбендә фәнни тикшеренүче һәм мөгаллим. Дельфиннарга багышланган хезмәтеннән тыш, «Күркәләр Раштуа турында нәрсә уйлый?», «Үзегезне хайваннар урынына куеп карагыз» китаплары авторы да.

Китсыманнарны Фабьенн Дельфур 20 елдан артык өйрәнә. Дөнья океанының барлык өлешләрендә дә – Франциянең Атлантик ярыннан алып Гавай утрауларына кадәр. Нәселдән-нәселгә һәм буыннан-буынга үз мәдәниятләре белән традицияләрен тапшырып барырга сәләтле, әмма беркайчан да үз төрләре арасында бер-берсен юкка чыгаруга

нигезләнгән канкойгыч сугышлар ачарга башларына китереп карамаучы бу җан ияләренә гомерен багышлауга үкенми Дельфур.

«Без аларны дельфинарий, туристик сәфәрләр кебек мәгънәсез шартларда түгел, ә чын Табигать стихиясендә күрсәк, шаккатыр... хәтта үзебезнең дельфин эзәрлекләп йөрергә мәҗбүр кеше булуыбызга оялыр да идек», – дигән караштa тора ул. Дельфиннар белән кешеләр үзара мөнәсәбәтләрен бары тик ихтирамлы итеп кора алса гына, ни дә булса барып чыга ала, ди.

Ахыр чиктә, океан-диңгезләргә – аларның яшәеш стихиясенә – без бит чакырылмаган килеш барып керәбез дә үз кагыйдәләребезне урнаштыра башлыйбыз. Ә анда инде башка кагыйдәләр һәм кануннар бар.

Шунысын да онытмаска кирәк, ди Дельфур: аларда кланнар көрәше яки нинди дә булса тайпылыш, кискен ситуация булырга мөмкин, социаль иерархия бәрелешләре һ.б. Әмма тикторганнан гына бер дельфин икенче дельфинны үтерми. Бу әле дельфиннар дөньясын анык беләбез һәм нинди нәтиҗәләр ясый алабыз, дигән сүз түгел, чөнки беребезнең дә аларның башына кереп караганы, тирeләренә сеңеп тойганы юк, ди ул. Үзләрен бу өлкәдәге пионерларга тиңли.

Беренче мәртәбә дельфиннарны өйрәнергә мөмкинлек алгач, Дельфур ачылмаган өр-яңа галәм алдында торганын аңлый. 20 ел буена, ул галәмне ача-ача, соклануы, гаҗәпләнүе арта гына бара. Кешеләр судан чыкмаган булса, дельфиннарга иң якын төр булырлар иде, ди галимнәр. Кайберләре ассызыклый: бәлки, алар нәкъ менә дельфин булгандыр да? Атлантида һәм аның цивилизациясе белән дельфиннарны чагыштыручылар бар бит.

«Ни генә димә, алар чынлап та башка төр имезүчеләрдән бик нык аерылып тора, – ди Фабьенн ханым. - Җәмгыяте һәм социаль тормышы гаять үзенчәлекле һәм катлаулы». Дельфиннар бер дә дельфинарийларда җәфа чиккән «мөлаем» хайваннар гына түгел, һәрберсенең үз холык-фигыле, психотибы, темпераменты бар икән: оптимист, пессимист, мыжык-мыгырдавык, ялгызаклыкны сөюче, социопат, альтруист, дуамал, шаян-юморист, иҗади-хисчән. Ыруындагы башка дельфинны, яки үз җенесендәге якын дустын югалтса, алар зур хәсрәт кичерә, кешеләр шикелле, траурга керә. Үлгән балаларын атналар буе аркасында йөртеп, бәләкәчнең гәүдәсе таркала башлагач та калдырып китә алмаучы ана дельфиннарның язмышын, ялгызак һәм авыру, картайган дельфиннарның нәрсәгә дучар булуын җентекләп яза.

Дельфиннарның исемнәре һәм үз исемнәренә анык мөнәсәбәте бар, ди Дельфур. Шулай ук – үз ырудашларын гына түгел, мәсәлән, аларны өйрәнгән кешеләрне дә аермачык танып-белү сәләте, аралашу форматлары. Әлбәттә, исемнәре без кушкан сәер исемнәр түгел, ә чып-чын озын,

«ӨЧ МУШКЕТЁР» РОМАНЫНДАГЫ АТАКЛЫ ГЫЙБАРӘ – «БЕРӘҮ – БАРЫСЫ ӨЧЕН ДӘ, Ә БАРЫСЫ ДА – БЕРӘҮ ӨЧЕН» – НӘКЪ МЕНӘ ДЕЛЬФИННАР ТУРЫНДА. АЛАР ГАДӘТТӘ ҮЗ ТӨРЕНӘ КАРАГАН ИКЕНЧЕ ҖАН ИЯСЕН БӘЛАДӘ ТАШЛАМЫЙ, ҖИТДИ СӘБӘП БУЛМАСА, КЫЕРСЫТМЫЙ, КИРЕ КАКМЫЙ, ЯРДӘМ ИТМИЧӘ, ЙӨЗЕП КИТЕП БАРМЫЙ. МОНДЫЙ ХӘЛ АЛАРНЫҢ ГЕНЕТИК ХӘТЕРЕНДӘ ЮК, БУЛУЫ МӨМКИН ДИП УЙЛАНЫЛМЫЙ ДА».

Фабьенн Дельфур

сонор, акустика ярдәмендә аерып була торган «дельфин теленәдәге» атамалар. Дельфиннар ул исемнәр белән бер-берсенә дәшә, телләре ярдәмендә аралаша. «Өченче күзләре», тәндәге тотып алу «антенналары» барлыгы турында да сүз алып бара Дельфур. Телепатларча, ябык тартмалар, биналар эчендә нәрсә барлыгын күрергә сәләтле һәм моны үз тормышларында актив кулланалар, ди.

Ана дельфиннарның бала дельфин белән бергә бик якын йөзеп килеп, кешеләргә «смотр» ясавын төшереп алган фотолар очрый китапта. Әйтерсең, дельфин: «Менә, балам, бу кеше була инде», – дия сыман.

«Дөньякүләм фәнни җәмәгатьчелектә үз урынымны яулап алу өчен шактый көрәшергә туры килде, чөнки мин дельфиннарны өйрәнә башлаганда, бу җан ияләренә бик түбәнсетеп, хәтта мыскыллап карыйлар иде. Аларны өйрәнүче «исәрләргә» дә. Ни кызганыч, минем эшләрем Франциядә бу өлкәгә караган бердәнбер тикшеренү булып тора. Миңа бик урау, авыр юллар узарга туры килде. Үземне һәрдаим расларга, дельфиннарның, башка төрләр кебек үк, фәнни өйрәнелергә хокукы барлыгын дәлилләргә. Бәхеткә, вакыт дельфиннарга карата да, фән белән шөгыльләнергә теләгән хатын-кызларга да мөнәсәбәтне акрынлап үзгәртте. Хәзер мин, океанда дельфиннарны өйрәнү белән беррәттән, университетларда лекцияләр укыйм, студентлар белән аспирантлар тәрбиялим, аларны да бу өлкәгә җәлеп итәм. Бу гаҗәеп имезүчеләрне өйрәнү ихтирамга лаек хезмәт итеп кабул ителә башлады, әлеге юнәлешкә чын фән итеп карау барлыкка килде. Моның белән чиксез горурланам».

Фабьенн Дельфур

Ул «кеше» төренә караучы имезүчеләрне, саграк, мәрхәмәтлерәк булырга чакыра. Бер генә дельфинның да, судан чыгып, шәһәр-авылларга бәреп кереп, кешегә зыян китергәне булмавын әйтә. Безне дә үз исемебезне мәсхәрәләмәскә өнди. «Дельфиннар – болай да язмышлары һәр көнне кыл өстендә торган кабатланмас җан ияләре, аларга бу чиксез табигать кочагында үз дельфин язмышын яшәргә һәм тормыш тәҗрибәсен кичерергә комачау итмик!»

Фото Айдар Фәйзрахманов архивыннан

АНЫҢ ТОРМЫШ ҖЫРЛАРЫ

Евгения Чеснокова

Бервакыт Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле җитәкчесе Айдар Фәйзрахмановка Лейпцигтан Беренче бөтендөнья сугышы вакытында немецлар ясаган аудиоязмаларны алып кайталар: анда әсир татарлар «Кара урман» һәм «Заман» җырларын җырлый. Шул чын тавышларны кулланып, Фәйзрахманов җитәкчелегендәге ансамбль клиплар төшерә*. Ул аутентик фольклорны һәм аның заманча яңгырашын тамашачыга җиткерүне үзенең бурычы саный.

Фольклор музыкасы ансамбле – уникаль коллектив. Анда биючеләр дә, җырчылар да, төрле уен коралларында (гармун, курай, гөслә, кубыз, саз) уйнаучылар да бар. Аларның чыгышлары Прага һәм Истанбул, Париж һәм Дубай, Венеция һәм Улан-Батор (Россия шәһәрләрен санап бетерерлек түгел) тамашачыларын таң калдыра.

– Мин һәрвакыт тамашачыга татар фольклорының югары сәнгать дәрәҗәсендә булуын күрсәтергә омтылам, – дип аңлата үзенең иҗади кредосын Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Фәйзрахманов.

* *Клипларны «Интернет» челтәрендә табарга була, карагыз – үкенмәссез!*

Мөгаен, шуңа күрә бөтен дөньяда аны шулай аңлыйлар һәм кабул итәләрдер.

ОЗАККА СУЗЫЛГАН БЕР ЕЛ

2002 елда Айдар Фәйзрахмановка өч ел элек оештырылган фольклор музыкасы ансамблен җитәкләргә тәкъдим итәләр. Ул вакытта Фәйзрахманов Муса Җәлил исемендәге опера театры солисты була, педагогика институтының музыка факультетында вокал укыта, телевидениедә популяр «Җырлыйк әле» программасын алып бара. Ул үз өстенә тагын шундый авыр эш алырга җыенмаган була. Ләкин ансамбльне оештыручы – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакиров коллективны нәкъ менә Айдар Фәтхрахман улы җитәкләвен тели. «Бер генә ел килешү буенча эшләргә» дигән ризалык алына җырчыдан.

Һәм менә 23 нче ел ул – шул вазыйфада...

ОПЕРА ҖЫРЧЫСЫ

1970 нче еллар ахыры. Айдар Фәйзрахманов консерваториядә укый, тулай торакта яши. Беркөнне кич белән аны вахтага төшәргә чакыралар. Анда егетне бер ят кеше көтә. «Мин – Мәсгуть Имашев, опера театры директоры, – дип таныштыра үзе белән ул, шунда ук гозерен дә җиткерә. – Миңа син баянда уйныйсың, җырлыйсың, дип әйттеләр... Опера труппабыз Ташкентта гастрольләрдә, баянчыбыз авырып китте, концертта уйнарга кеше юк. Зинһар, коткар, Ташкентка барырга кирәк».

– Мин өченче курска кадәр эстрадада җырларга ниятләгән идем, аннары опера театрына йөри башладым. Карузо, Паваротти, Атлантов язмаларын тыңладым һәм шуны аңладым: әгәр кеше классик опера җырлый ала икән, ул халык җырларын да, эстрада җырларын да – барысын да башкара алачак, – дип искә ала Айдар Фәтхрахманович. – Минем өчен Хәйдәр Бигичев үрнәк булды. Ул миннән бер курска алдарак укыды, әмма опера театрында эшли, параллель рәвештә татар җырларын да бик яхшы башкара иде. Мин опера театрында эшләргә хыялландым! Ә монда шундый форсат туды... Әлеге гастрольләрдән соң, опера театрына юл ачыласына ышана идем. Әмма ул арада директорны да алыштырдылар. Директор булып Рәүфәл Сабирович Мөхәммәтҗанов килде. Һәм минем хыялым чынга ашмас кебек тоелды...

Ләкин опера театрындагы танышлары аны яңа директор янына алып керә. Янәсе, менә кадерле милли кадр, җитмәсә баянда да уйный... Ә баянчылар ул вакытта – алтын бәһасе. Заманасы да шундый: театр шул исәптән концерт бригадалары гастрольләре хисабына яши. Аны алалар – дөрес, икенче партияләргә. Ләкин ул барыбер бәхетле.

– Хәтерлим әле, бервакыт труппа җыелышында директор мине урынымнан күтәрде дә: «Менә Айдар гастрольдән яхшы акчалар алып кайтты, хәзер инде барыгызны да отпускка озата алам», – диде. Шундый заман иде, 80 нче еллар уртасы, – дип искә ала Айдар абый. – Ә минем театрда беренче

1961 ел.
Айдар Фәйзрахмановка алты яшь.

Россия Президенты Владимир Путин Казан Сабан туенда. 2000 ел. Уңда тальянка белән – Айдар Фәйзрахманов.



Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» операсы. Кәрим бай – Азат Аббасов, шымчылар – Айдар Фәйзрахманов, Мөнир Якупов.

партияләрне җырламавым – анысы мәҗбүри түгел. Мин табигатем белән актер. «Борис Годунов»та мин Мисаил ролен башкардым. Варлаам белән булган күренештә караваттан шундый матур итеп тәгәрәп төшә идем, хәтта Мәскәү режиссеры да: «Менә шундый артистлар театрны театр итә дә инде!» – диде. «Князь Игорь»да – Ерошка, «Алтынчәч»тә хан хезмәтчесе Урмай... Уен күренешләре күп булган үзенчәлекле партияләрне яратып башкардым. Бәлки, тавыш ягыннан бераз оттырсам да, актерлык ягыннан һәрвакыт өстен идем! Һәм һөнәри үсеш ягыннан опера театры биргән кадәрле тәҗрибәне мин башка беркайда да алмадым.

Биредә Фәйзрахманов чирек гасырдан артык хезмәт итә, һәм бүген дә, үз ансамблендә музыкантлар белән эшләгәндә, опера театрында алган тәҗрибә аңа нык булыша.

КАМИЛЛЕККӘ ОМТЫЛЫШ

Айдарга җиде яшь булганда, әтисе аңа тальян гармун бүләк итә.

– Табигатьтән килгән сәләт булгандыр, гармунда уйнарга үзлегемнән өйрәндем, – дип искә ала ул. – Музыка мәктәбенә йөрмәдем. Авылда яшәдек, гадәти мәктәпкә чаклы гына да көн саен дүрт километр йөрергә туры килде, кире кайтырга да кирәк, кая анда тагын музыка белән дә шөгыльләнергә. Аннары, әти-әни авыл укытучылары, аларның артык акчасы юк.

Абыйсы педагогика институтының музыка факультетына укырга керә һәм бервакыт каникулга, программаны өйрәнергә дип, баян алып кайта.

– Тальянда яхшы гына уйный идем инде, ә монда баян... Абый миңа ноталар тоттыра да уйнарга куша. Мин ноталар белмим бит. Уйнап күрсәт үзең, дим. Ул ике мәртәбә уйнап күрсәтте – мин отып калдым, кабатлап күрсәттем! – дип елмаеп искә ала Айдар Фәтхрахманович. – Алтынчы-җиденче сыйныфлардан башлап, мине җиткән кызлар кич утырырга чакыра башлады – аларны биетергә гармунчы кирәк. Мин оялчан, башымны кызлардан читкәрәк борып уйныйм. Аннары борылам – алар инде биеми икән, мине тыңлыйлар...

Ә тагын мин авылда кемнең кайсы урамда нәрсәдә уйнаганын һәрвакыт ишетә, аера идем. Әле дә хәтеремдә: авыл егетләре армиягә китәр алдыннан гармунга җырлап урам әйләнә. Зур түгәрәк ясап, кемдер алга карап бара, кемдер аркасы белән борылган... Мин шунда Рафаэль абый гармунының тавышы минем тальяннныкына караганда күпкә матуррак яңгыравын ишетәм... Йөгереп барып карыйм: әйе, анда ике рәт. Ләкин миңа да андый гармун алып булмаячак, чөнки әти-әнинең мөмкинлеге юк. Унынчы сыйныфтан соң шулай ук педагогика институтының музфагына укырга керергә дип баргач, ишетеп уйнадым. Бер татар җырын җырладым. Имтиханны Нәҗип Гаяз улы Җиһановның бертуганы – опера театры дирижеры Җәләл Садриҗиһанов кабул итте. Ни күрим – ул елый... «Бар, өеңә кайт, син безнең студент!» – диде ул. Менә шулай музыка мәктәбендә укымыйча гына студент булып куйдым.

Институтны тәмамлаганда, педагогы аны консерватория ректоры Нәҗип Җиһановка тыңлатырга алып бара. Һәм аны вокал факультетына кабул итәләр.

– Кайчак эстрада артистларыннан ишетергә туры килгәли: талант бар икән, белем алу мәҗбүри түгел... – ди Айдар абый. – Әкият бу! Булган талантны үстерергә кирәк, кеше һәрвакыт камиллеккә омтылырга тиеш. Югыйсә кайбер җырчыларны тыңлаганда: «Эх, сиңа бераз гына белем бирәсе иде, яхшы җырчы чыгар иде үзеңнән», – дип уйлап куясың.

ҮЗ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМДА

Арча районы Урта Бирәзә авылының бер урамын авылдашлары Фәйзрахмановлар урамы дип үзгәртәләр. Абыйсы Альберт Фәйзрахманов Татарстан авылларын газлаштыру белән шөгыльләнә, туган авылына да газ кертә. Аннары су да үткәрә. Айдар абый үзе асфальт юл салдыру максатында берничә ел төрле кабинет бусагаларын таптый – туган авылы Арчадан дүрт чакрым ераклыкта гына, ә юл юк. Шуның аркасында халык та шәһәргә китү ягын карый. Телләгенә ирешә, юл салына, хәзер авылда халык саны арта бара.

Гаилә кочагында. 2019 ел.

Берничә ел элек гаиләгә авыр кайгы килә: Айдар абыйның хатыны вафат була. Күңелсез уйлардан котылу өчен, ул үзләренең гаилә йортында Фәйзрахмановлар музееен ачу белән шөгыльләнә. Анда җырчының беренче тальянкасын, беренче баянын яки, мәсәлән, әнисе каймак аерта торган сепараторны да күрергә мөмкин....

– Әле дә хәтерлим: футбол уйнап, урамнан өйгә кайтып керәсең, әниең сиңа каймак ягылган икмәк телеме суза... – дип искә ала ул. – Хәзер андый тәмле каймак юк, шуларны сагынам. Каз мае салып пешерелгән бәрәңге исен... Кышын чаңгыда мәктәптән кайтып киләсең, ә анда шул ис... Әни ипи пешергән мич тә кызган... Мин шул мич алдында дәрес әзерләп утырам... Кешеләр үзләренең тамырларын онытырга тиеш түгел. Ерак гастрольләрдән Татарстанга һәрвакыт шатланып кайтып керәм.

ҖЫР КАЛАЧАК...

2022 елда Айдар Фәйзрахманов «Юлын белгән арымас» китабын яза. Китапта – истәлекләре, фотосурәтләр, танылган кешеләрнең аның турындагы фикерләре. Ә бу матур җыентыкның азагында куар-код куелган, аның буенча артист башкаруындагы җырларны тыңларга була. Әлеге йөзгә якын җырны ул төрле елларда Татарстан радиосы өчен яздырган булган. Бүген алар республика радиосының алтын фондына керә. Алар арасында халык җырлары гына түгел, авторныкы да бар, шул исәптән көен Айдар абый үзе язганнары да.

– Еллар узар, бу җырлар да фольклор булып саналыр, – дип елмая ул. – Башкаручыларын, авторларын онытачаклар, ә җырлар калачак. Фольклор шул инде – җыр халык арасында яшәгәндә. Без ансамбль белән җыр җыентыклары чыгардык, өч томда. Бөтен репертуарыбызны. «Сезнең җырларыгызны кулланырга ярыймы?» – дип сорасалар, бик шатланам. «Ярый гына түгел, кирәк! Китабымның исемен хәтерлисезме? Үз юлын белгән кеше беркайчан да арымас. Минә минем үз юлым бар. Минем әле яшисем, иҗат итәсем килә.

ЧИРЕК ГАСЫРЛЫК ИҖАДИ ХЕЗМӘТ

2024 елның 13 декабрьдә Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор ансамбле үзенең 25 еллыгын билгеләп үтте. Татар дәүләт филармониясе сәхнәсендә зур концерт оештырылды. Артистлар матур җырларын җырладылар, дәртле биюләрен биеделәр. Ә сул яктан сәхнә артын күреп торган тамашачы пәрдә артында Айдар Фәтхрахмановичның үз артистлары белән һәр хәрәкәтне кабатлавын күзәтә алды. Һәм бу яшьнең ничәдә булуына да карамастан – 30 гыйнварда Айдар Фәйзрахмановка 70 яшь тула.

– Тормыш матур, ә яраткан эш белән шөгыльләнгәндә ул тагын да матуррак! – ди җырчы үзенең илһам чыганагы сере турында.

«Татарстан» журналы редакциясе Айдар Фәтхрахман улын күркәм юбилее белән котлый һәм аңа сәламәтлек, имин-мул тормыш, әлбәттә, яңа җырлар һәм иҗади уңышлар тели!

Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле.

УРТА БИРӘЗӘ: ЯШЬЛЕККӘ КАЙТУ

УРТА БИРӘЗӘ

Ел дәвамында матур татар авыллары турында язабыз. Инде дистә ел шулай. «Татарстан» журналы бармаган бер генә район да калмады. Быел да күркәм традицияне дәвам итәрбез.

Халык Яңа ел бәйрәмнәре белән мәш килгәндә, Арча районының Урта Бирәзә авылын күреп кайттык. Ни өчен дигәндә, бирeдә ел саен яңа йортлар салына. Авыллар бетә, дип сыкранганда, Урта Бирәзә киресенчә үсә бара. Моның сәбәбе нәрсәдә? Тагын әле бу авыл Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахмановның туган ягы булуы белән дә үзенчәлекле.

Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

ФӘЙЗРАХМАНОВЛАР УРАМЫ

Урта Бирәзә бүген икенче яшьлеген кичерә дисәм, арттыру булмас. 2000 нче еллар башында авылда 48 йорт калган. Бүген исә 101 нче йорт төзелеп ята. Уноч ел эчендә илле йорт салынган. Нәтиҗәдә, Урта Бирәзәдә бер генә буш нигез дә юк. Инде яңа йортларны кыр җирләрен рәсмиләштереп салалар икән. Хәтта шундый тулы бер урам да барлыкка килгән.

– Революциягә кадәр Урта Бирәзәдә 109 йорт булган, 1049 кеше яшәгән, – диде Наласа авыл җирлеге башлыгы Илфира Шакирова. – Якын киләчәктә шушы санга яңадан кайтырбыз, дип уйлыйм. Авыл еллап түгел, айлап үсә, Аллага шөкер. Бүген авылда 324 кеше теркәлгән. Ләкин халык саны бермә-бер артык, чөнки күп яшь гаиләләрнең шәһәрдә фатирлары бар. Алар шунда теркәлгән. Ә үзләре монда йорт салып, матур итеп яшәп яталар.

– Авылда калган яшь гаиләләр үзегезнең егет-кызлармы? – дим.

– Төрлесе бар. Читтән дә килеп төпләнәләр. Ата-бабалары нигезен яңартучы яшьләр дә күп. Яшьләр белән күп тапкырлар очрашулар үткәрдем. «Җир ул – байлык. Ата-бабаларыгызның нигезләре ташландык хәлдә ята, шуларны чистартып, яңа йорт җиткезегез. Дәүләт яшьләргә

төрле программалар тәкъдим итә. Үзем документларын эшләп бирәм, алыгыз гына», – дидем.

– Һәм эшләп тә бирдегезме? – дим.

– Әйе. 2012 елдан башлап авылда калган яшь белгечләргә дәүләт йорт салырга 1 миллион сум акча бирде. Ул чагында бу акчага бер дигән йорт салып була иде. Әнә шулай башта бер гаиләгә, аннан икенчесенә документлар юллап, субсидияләр кайтты. Авыл җирлекләренә дә яхшы бит: мәдәният йорты эшләүме, юл салу программасымы – кеше саны аз булса, берсендә дә катнаша алмыйсың. Ә болай ел саен авылда биш-алты, хәтта унар йорт салына. Кайсы ишеккә барып керсәң дә, авыз тутырып: «Безнең авыл үсә, шушы программага кертегез әле», – дип әйтә аласың. Газы, суы кергән, юлы бар. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, ФАП, мәчет, кибет – барысы да гөрләп эшләп тора. Үз эшен башлаучы яшьләр шактый. Арчага, Казанга йөреп тә эшлиләр...

Урта Бирәзәнең табигате дә искиткеч: янәшәдә генә – таулары, болыннары. Географик яктан да уңайлы, Арча шәһәренә дүрт-биш кенә чакрым. Димәк, балаңны спорт яки музыка мәктәбенә, бассейнга йөртсәң, җәяү дә барырга мөмкин.

Авыл җирлеге башлыгы белән Фәйзрахмановлар урамына килеп туктадык. Башка урамнардан аермалы буларак, биредә ике катлы яңа йортлар күп түгел.

– Без үскәндә авылда менә шундый йортлар иде, – диде Илфира Рамазановна.

– Урамны Россиянең атказанган, Татарстанның халык җырчысы хөрмәтенә атадыгызмы? – дим.

– Айдар Фәйзрахманов һәм аның абый-апалары хөрмәтенә куштык. Алар бит – алты бала, Айдар абый иң төпчеге. Фәйзрахмановларның кайсын гына алсаң да, горурланып сөйләргә була. Иң мөһиме – барысы да авыл өчен янып яшәде, яши. Мисал өчен, Альберт абый Фәйзрахманов бөтен Татарстан авылларына газ кертте, «Востокгазстрой»ның генераль директоры иде. 1988 елда ук, Татарстанда беренчеләрдән булып, Урта Бирәзәгә газ кертелде. Аннан соң халыкны сулы да итте. Юл артыннан исә Айдар абый Фәйзрахманов йөрде. Яңа мәдәният йорты да Айдар абыебыз тырышлыгы белән салынды. Атаклы нәселнең данлыклы балалары шул...

– Яшьләр белән күп тапкырлар очрашулар үткәрдем, – ди Наласа авыл җирлеге башлыгы Илфира Шакирова.

ТӨП НИГЕЗГӘ ХӨРМӘТ

Фәйзрахмановларның төп нигезе бүген Айдар абый кулында. Төпчек бала буларак, абый-апалары аны энекәшләренә тапшырган. Ә Айдар абый бер эшкә алынса, аны җиренә җиткермичә туктамый. (Моны без авылдашларыннан берничә тапкыр ишеттек.)

Җәен Фәйзрахмановларның йорты гөлбакчага әйләнә икән. Айдар абый анда атналар буе яши, кызлары, оныклары да кайта. Кышын исә йорт күбрәк бикле тора. Хәер, күршедә Рәмзия апа яши, ул көн саен кереп, утны, газны карап чыга.

– Айдарның йорты кышын да җылы тора, – диде Рәмзия апа Фәйзрахманова. – Карын күрше егете көри. Мәрхүм ирем белән Айдар икетуган булып чыга, шулай булгач, мин дә Фәйзрахмановлар нәселен дәвам итүче. Урта Бирәзәгә килен булып төшкәнгә 58 ел булды, күрше Күкчә авылыннан мин.

Рәмзия апа үзе артыннан ияртте. Ниятебез – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты йортын күреп чыгу.

– Айдар нигезне бик карап тота, – дип дәвам итте Рәмзия апа. – Ир-атлардан үзе генә калды инде, ике абыйсы да мәрхүм булды. Ике апасы исән-сау, Аллага шөкер. Казанда яшиләр, җәен алар да кайта. Ишек алдында беседкалары бар, шунда табыннар корып, матур итеп кич утыралар. Мин дә керәм инде.

Айдар абый әти-әнисеннән калган йортны яңарткан: әчен агач белән тышлаган, янкорма ясап куйган. Анысы музей буларак хезмәт итә. Ни генә юк монда: кәстрүл, чынаяктан башлап, музыка уен кораллары, кадерле фо-

– Мәрхүм ирем белән Айдар икетуган булып чыга, шулай булгач, мин дә Фәйзрахмановлар нәселен дәвам итүче, – ди Рәмзия апа.

Җәен Фәйзрахмановларның йорты гөлбакчага әйләнә.

толарга кадәр... Хәтта Айдар абый үскән бала арбасы да сакланган!

– Айдарның әти-әнисе авылның атаклы мөгаллимнәре булган, – дип дәвам итте Рәмзия апа. – Алар икесе дә Урта Бирәзә башлангыч мәктәбендә укыткан. Сугыш башлангач, Фәтхрахман абый фронтка киткән. Ашыйсы ризыгы, туасы балалары булгангадыр, сугыштан исән-имин кайткан. Фәтхрахман абый белән Бибинур апа алты баласына да бер дигән тәрбия биргән, аларның һәрберсе баян, гармунда уйнарга өйрәнгән. Фәтхрахман абый үзе дә скрипка, тальянда уйный иде. Бертуган абыйсы Гыйният хәтта скрипкалар ясаган. Күрәсең, җыр-моңга сәләт нәселдән килә. Кызганыч, Фәтхрахман абый озын гомерле булмады, ә менә Бибинур апа сиксәннән узды.

Айдар абый зәвыклы кеше: бу аның иҗатында нык сизелә. Инде җырчының туган нигезенә аяк баскач, моңа шик калмады. Биредә һәр нәрсәнең үз урыны бар. Ә менә артык купшылыкка урын юк монда. Һәр нәрсәдә җан җылысы, иҗат нуры сизелә...

Фәйзрахмановлар йортында безне иң гаҗәпләндергәне музей як булды. Ничек бер гаиләдә шулкадәр күп әйберләр сакланган. Алай гына түгел, алар барысы да төзек, әйтерсең кичә генә сатып алынган! Иске дип, бернәрсәне дә чыгарып атмаганнар бит. Хәтта Айдар абый тугач ясалган сәкегә кадәр матур итеп буяп куелган. Ул бүген дә хезмәт итә. Зыялы, затлы нәселнең олы шәҗәрәсе исә шушы экспонатларның иң кыйммәтлеселәр, мөгаен.

Фәйзрахмановлар йортына җәен килергә кирәк, Айдар абый бакчачы да, диделәр. Аның чәчкәләренә сокланмаган кеше юк икән. Ә ул утырткан агач-куаклар (йөздән артык!) Айдар

Айдар Фәйзрахманов, Татарстанның халык артисты:

– Авылларда мәдәният йортлары торгызыла башлаганнан соң, Татарстан Президентына хат яздым. Аллага шөкер, 2018 елда авылыбыз мәдәният йортлы да булды. Архивларда эзләнгәндә, бабамның әтисе авылда мәчетне зурайту прошениесе белән патшага хат язганлыгы ачыкланды. Мин әйтәм, һаман да шул бер нәсел йөри...

Кырык йортка калган Урта Бирәздә бүген йөздән артык йорт бар. Авыл гөрләп тора. Туган нигезем дә төзек, матур. Үз кулларым белән 100дән артык агач утырттым. Болар барысы да минем өчен зур сөенеч. Туган авылымның яңадан үсүендә район үзәгенә якын булуы да зур этәргеч булды. Юл булса – тәртип. Халык йөреп тә эшли. Европада күптән шулай инде ул: 60–100 чакрымны уйламыйлар да, йөреп эшлиләр.

абыйның тагын бер изге гамәле булып авыл тарихында калыр.

«ҮЗЕБЕЗНЕҢ МӘКТӘП!»

Урта Бирәздә башлангыч мәктәп бар, дидем. Авыл балалары 1921–1922 елларда ук укый-яза белгән, чөнки авылның мулласы малай-кызларга өендә белем биргән. Анда хәтта Гомәр Бәширов та укыткан. Колхозлар оешкач, ягъни 1935 елда Урта Бирәздә өч яклы мәктәп салына. Агачтан, заманасына күрә бер дигән башлангыч белем бирү йорты була ул. Өч сыйныф булып, алтмыш-җитмеш бала укыган анда. (Нәкъ менә шушы яңа бина ачылганнан соң, Фәйзрахмановларның әнисе Бибинур апа авылга мөгаллимә булып килә.)

– Ул өч яклы агач мәктәп бик озак хезмәт итте, – диде Наласа авыл җирлеге башлыгы Илфира Шакирова. – Мин үзем дә 1986 елдан башлап шунда эшләдем. Аннары 1994 елда колхоз яңа мәктәп бинасы төзеп бирде. Шуны гына әйтәм: безнең укучылар беркайда да югалып калмый. Бала башлангычта төпле белем алса, алга таба бара.

Утыз ел элек салынган башлангыч мәктәп бинасының түбәсен алыштырганнар, эчен буяп, карап җибәргәннәр. Белем йортының бер ягына фельдшер-акушерлык пункты күчкән. Узган ел аңа капиталь ремонт ясаганнар. Нәтиҗәдә бик матур, заманча ФАПка әйләнгән! Анда эшләүче кызлар шифалы куллары белән генә түгел, якты йөзләре белән дә дәвалый сыман тоелды. Җылы, якты, дүрт классы булган мәктәптә исә бүген бары тик өченче сыйныф кына бар икән.

– Узган ел беренче класска килүче булмады, – диде мәктәпнең бердәнбер укытучысы Алинә Мөхетдинова. – Дүртенчеләр чыгып китте. Нәтиҗәдә, быелгы уку елында дүрт бала укый. Беренче сыйныфка биш бала керәчәк дип көтеп торабыз. Алга таба бала саны тагын артыр, дип өметләнәбез, чөнки авылда утыздан артык яшь гаилә бар.

Урта Бирәзә балалары бишенче сыйныфка гел Арча шәһәренә йөреп укыган. Хәзер дә шулай. Бер карасаң, Арчадан укучыларны алырга көн саен автобус килә, башлангычлар да абыйапаларына ияреп китсә була. Тик бу уңайдан ата-аналарның фикере катгый: балалар үз авылыбызда белем алсын! Монда һәр бала – игътибар үзәгендә. Хәер, җирле халык кына шулай дип уйлый.

– Авылга читтән килүчеләр, нигездә, балаларын Арчага йөртеп укыта, – диде Алинә Рәисовна. – Шулай өйрәнгән бит инде алар. Ә җирле халык үзе дә Урта Бирәзә мәктәбендә белем алган. Мин үзем дә башлангычта биредә укыдым. Мәктәпнең үз традицияләре, үз кыйбласы бар. Монда гел төпле белем бирделәр. Бүген дә менә шул югарылыктан төшмәскә тырышабыз. Мәктәптә начар укучы балалар юк. Прог-

Утыз ел элек салынган башлангыч мәктәп бинасының түбәсен алыштырганнар, эчен буяп, карап җибәргәннәр.

раммадан артта калган очракта, һәркайсы белән аерым шөгыльләнәм. Арчага киткәч тә, укучыларыбызның билгеләре төшми.

ҖИРЛЕ ШАГЫЙРЬ

Арча ягында мәдәниятле, әдәбиятлы халык яши. Моңа инану өчен белгеч булырга кирәкми. Татар әдәбияты әһелләренең яртысы ук булмаса да, өчтән бере Арча төбәгендә үскән шәхесләр. Әле танылу алмаганнары күпме!

Урта Бирәзәдә Дамир Нуриәхмәтов исемле шагыйрь яши. Арчалылар аны яхшы белә. Соңгы елларда социаль челтәрләр аркылы киң катлам укучысы да Дамир абыйны таный башлаган. Шагыйрьнең дүрт китабы дөнья күргән. Олылар өчен дә, балалар өчен дә язган шигырьләре бар.

– Бердәнбер үкенечем калды – югары белем ала алмадым, – диде Дамир Нуриәхмәтов. – Армиягә киткәнче, Арча автотранспорт предприятиесендә слесарь булып эшләдем. Армиядән кайткач, Әтнә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, «Октябрь» колхозында башта шофер, аннары газ хезмәте буенча слесарь булдым. Соңрак үзебезнең колхозда кырчылык бригадасын җитәкләдем. Югыйсә гомерем буе әдәбиятны яраттым. Шигырьләр язуым да шуннан киләдер.

Дамир абыйның этисе Фәтхрахман ага – Кызыл Йолдыз, Дан орденнары алган кеше. 17 яшьтән сугышка китеп, фронтта зур батырлыклар күрсәткән ул. Әнисе Суфия апа исә укытучы булып эшләгән. Гомер иткән җәмәгате Рәмзия дә авылның данлыклы укытучысы икән.

– Дамир ул бик белемле, акыллы кеше, – дип сүзгә кушылды Рәмзия апа. – Без аның белән танышканда, бу әдәбият укытучысыдыр, дип уйлаган идем. Күп укый ул. Табигатьтә йөрергә ярата, тәмле үлән чәйләре әзерли.

Шигърияттән кала, Дамир абыйның күңеленә якын тагын бер шөгыле бар – умартачы да икән ул. Җәй буе болында, урманда, аерылып чыккан корт ояларын эзләп, алып кайта.

– Хыялый мин, аны бөтен кеше аңлап та бетермидер, – дип елмайды Дамир абый. – Әле менә яңа гына Татарстан китап нәшриятында балалар өчен китабым басылып чыкты. Аңа сөендем инде! Илһам килде дә, бер-бер артлы утыздан артык балалар шигырьләре язылды. Ул авыррак икән, балаларча уйларга кирәк бит. Алланың рәхмәте, шигырьләрем ярыйсы гына килеп чыкты кебек. Оныклар да яратып укый, ятлый. Олы бәхет шул инде ул!

Әти кешенең тагын бер бәхете – улы Ленар. Мәктәпне дә, КХТИны да кызыл дипломга тәмамлаган егет бүген үз эшен булдырган. Гаиләсе белән Казанда яшәсә дә, авылда ат фермасы тота. Атларны карарга туганнары ярдәм итә.

– Ленарыбыз диндә, биш вакыт намазын калдырмый, – диде Рәмзия апа. – Аңа карап, без дә ислам юлына бастык. Бүген улыбызның уңышларына сөенеп, шөкер итеп яшибез.

...Урта Бирәзәдә тагын бер күркәм гамәлне күрдек – бирдә чишмәләр каралган. Үзсалым акчасына да, иганәчеләр табып та, авыл җирлеге һәркайсын карап, чистартып, барлап тора. Юл проблемасы да үзара салым хисабына күптән хәл ителгән. Монда хуҗа барлыгы күренә. Авыл җирлеге башлыгы Илфира Рамазановнаны күптән беләм: ут ханым. Ул белмәгән, катнашмаган дәүләт программасы калдымы икән? Тынгысыз җитәкченең өч баласы да, Урта Бирәзәдә калып, менә дигән итеп яшәп ята. Ә нәрсә, башка авыл җирлеге башлыклары да шундый шәхси үрнәк күрсәтсә, бәлки, чынлап та, авылларда хәлләр үзгәрер иде?!

ФАПта эшләүче кызлар шифалы куллары белән генә түгел, ачык йөзләре белән дә дәвалый сыман тоелды.

Урта Бирәзәнең үз шагыйре бар: Дамир Нуриәхмәтов җәмәгате Рәмзия белән яши.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Урта Бирәзә авылы XVI гасырда барлыкка килгән дип карала. Өчиле авылыннан Богыш исемле удмурт кешесе күченеп килгән, дип фаразлана. Ул нигез бүгенге көндә дә бар, анда яңа йорт салынды.

Авыл атамасы «веризь» сүзеннән алынган, удмуртча «юкәлек» дигәнне аңлата. Бу якларда элек гел юкә урманнары булган. Тора-бара шул урманнарны кисеп, халык йортлар салган. Бүгенге көндә дә зиратта XVII–XVIII гасырларга караган алты каберлек бар. Кыскасы, авылыбыз борынгы, чал тарихлы.

Илфира Шакирова, Наласа авыл җирлеге башлыгы

МАТИСС, ПИКАССО, РЕНУАРҺӘМ ГҮЗӘЛ ЭПОХА (12+)

Belle Epoque, яки Гүзәл эпоха, – Европа тарихының XIX гасыр азагыннан алып 1914 елга кадәрге дәверен шулай атыйлар. Бу дәвер рәсем сәнгате һәм дөнья мәдәнияте өчен аерым үзенчәлеккә ия. Европаның иң бәхетле, гамьсез еллары ул – тынычлык хөкем сөргән, муллык-бәрәкәт ташып торган, иҗат чәчәк аткан чор. Бигрәк тә Франциядә – Belle Epoque атамасының ватаны да ул. «Эрмитаж-Казан» үзәгендә ачылган экспозиция рәссамнар иҗаты, графика, декоратив-гамәли сәнгать өлкәсенә караган иң даһи әсрләр белән танышырга мөмкинлек бирә. Болар барысы да – кешелекнең бөек мирасы. Казан экспозициясендә Камиль Писсарро, Клод Моне, Поль Гоген, Андре Дерен, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Муха, Анри де Тулуз-Лотрек, Эжен Грассе һәм башка осталарның әсәрләре урын алган.

һәр көнне 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга – 11:00 дан 20:00 гә кадәр)
Ял көне – дүшәмбе
«Эрмитаж-Казан» Үзәге, 3 кат, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

афиша

«Миннән еш кына сорыйлар: балачагың, яшьлек елларың ничек узды, ничек җырчы булып киттең, хәзер ничек яшисең? Җыр ничек туа? Аның җаны кайда? Бик күп сораулар бирәләр», – дип яза үзенең китабында җырчы Әлфия Авзалова. Байопик жанрындагы әлеге спектакльне тудыручылар халкыбызның яраткан җырчысы тормышындагы вакыйгаларны күздән кичерергә дә чакыра безне, кеше белән иҗатчы язмышын ваемларга да. Ә бит Әлфия апабыз – татар моңының тере гәүдәләнеше ул. Татар эстрадасы шаһинәсе буларак та күрәбез без аны, авылллардагы салкын клубларда җырлап, халыкка хезмәт иткән фидакарь зат буларак та, буй җитмәс йолдыз рәвешендә дә, һәрберебезгә якын һәм аңлаешлы гади бер кеше халәтендә дә. Нинди генә булмасын, ул милли мәдәниятнең символы һәм феномены – ул Мәңгелеккә юлын дәвам итә. Бу сәхнә әсәре үз заманының бөек затына иҗади баш ию дә, ди иҗат командасы.

22 гыйнвар, 19:00 Зур зал. Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры.
Казан, Татарстан ур., 1 йорт

АВАНГАРД. XXI ГАСЫР АРБАСЫНДА (6+)

Николай Фешин, Василий Кандинский, Александр Родченко, Варвара Степанова, Ольга Розанова... Авангард белән реалистик рәсем сәнгатенең әлеге танылган осталары бөтен дөньяда билгеле. Шуңа да гаҗәп: аларның кайбер эшләре бер гасыр дәвамында диярлек онытылып, күз уңыннан читтәрәк калып килгән икән бит. Сүз 1921 елда Вятка губернасы шәһәрләрендә күрсәтелергә тиешле Өченче күчмә сәнгать күргәзмәсе өчен сайлап алынган өч йөзләп киндер, графика һәм сынлы сәнгать үрнәкләре турында бара. Яранскига барып җитсен өчен, әлеге эшләрне ат арбасында илткәннәр, ә инде алга таба юлсызлык башланган, акча да җитмәгән... Шулай итеп, онытылган картиналар XX гасыр азагына кадәр Вятка губернасы музееның запасникларында тузан җыеп яткан. Бүген аларны «Авангард. XXI гасыр арбасында» күргәзмәсе экспозициясендә күрергә мөмкин. Совет сәнгатенең башлангыч чорында иҗат иткән иң үзенчәлекле вәкилләрне Вятка сәнгать музее, Яранск туган якны өйрәнү музее, Слобода туган якны өйрәнү музее, шулай ук Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее һәм шәхси тупланмалар тәкъдим итә.

һәр көнне 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Кабул итү урыннарының Күргәзмә залы «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, kamalteatr.ru, vk.com/dipi.shmot

АЛТЫН БАЛКЫШЫ ҺӘМ КОРЫЧ САЛКЫНЫ (0+)

Дары белән ата торган һәм салкын корал, көнкүреш предметлары, Златоуст гравюрасы белән бизәлгән паннолари – декоратив-гамәли сәнгатьнең кабатланмас экспонатларын Туп сараендагы күргәзмәдә күрергә мөмкин. Экспонатлар арасында XIX гасыр кылычы – күренекле оста Иван Бушуев эше дә бар. Ә ул нәкъ менә Златоуст мәктәбенә нигез салучы булып исәпләнә дә. Биредә хәзерге һәм совет чоры осталарының иң шәп эшләнмәләрен дә очратырга була. Бүген бөтен дөньяга танылган гравировка мәктәбенә 1815 елда Златоустта ачылган корал фабрикасында нигез салына. Мәктәп үзенең катлаулы сюжет композицияләре һәм осталарының үзенчәлекле, тәэсирле сәнгать алымнары белән аерылып тора.

һәр көнне 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга – 11:00 дан 20:00 га кадәр). Ял көне – дүшәмбе
Туп сарае музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛЛАР АША – ХЫЯЛГА (12+)

«Без кабызган утлар, сүнмәс алар...» – Кәрим Тинчуринның әлеге атаклы гыйбарәсе «Хыялга бер адым» спектакленең лейтмотивы булып тора. Вакыйгалар 1921 елда бара: Кәрим Тинчурин җитәкчелегендәге бер төркем артист, театр курсларын тәмамлаганнан соң, Оренбургка килеп төшә. Труппаның планнары зурдан. Әмма хыялларның барысы да чәлпәрәмә килергә мөмкин: Идел буенда ачлык, тиф котырына. Артистларны, алар белән бергә татар театрының киләчәген дә коткарыр өчен, Кәрим Тинчурин «Хыялга бер адым» пьесасын яза һәм аны... поездда ук куя башлый. Режиссёрның максаты – артистларны авыр юл шартларында иҗат белән мавыктыру да, ачлык белән авыру хөкем сөргән мохиттә рухларын күтәрү дә. «Кешене хыял яшәтә. Ә артистны – сәхнә... Мин труппаны бары тик яңа әсәр белән генә, репетицияләр белән генә саклап кала алам», – дип яза Тинчурин хатыны Заһидәгә...

Спектакль реаль вакыйгаларга нигезләнгән.
23 гыйнвар, 18:30 сәг.
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры
Казан, Горький ур., 13 йорт

БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК ИЛЕННӘН КУРЧАКЛАР (0+)

Чумдырыр өчен хәстәрләнгән озын эчке күлмәктәге бала-курчаклар белән конфирмация өчен иң күркәм итеп киенеп алган кызчыклар, норманд стилендәге туй күлмәкле гүзәл кәләшләр, будуарларында иркәп утырган француз ханымнары... Болар – гамьсез балачак иленә алып кайтырга сәләтле гаҗәеп күргәзмә экспонатларының кайберләре генә. Монда сез уенчыклар белән бизәлгән борынгы кәгазь чыршыны да очратырсыз, классик алман Раштуа Кыш Бабаен да, багучы курчакны да һәм, әлбәттә инде, балаларның иң яраткан уенчыклары – XIX гасыр Раштуа базарында һәрвакыт сатыла торган мут-шаян Полишинельләрне. Рус халык әкияте каһарманнары да бар монда, ностальгия уятып, балачакны хәтерләтеп тора торган совет заманы курчаклары да.

«Курчаклар дөньясы. XIX–XX гасыр уенчыклары, аксессуарлары, курчаклары» күргәзмәсе Уникаль курчаклар музее тупланмасыннан җыелган. Бу – XIX гасыр ахыры – XX гасыр уртасына караган һәм Германия, Франция, АКШ, ГДР, СССР дагы 400 дән артык борынгы уенчыкны үз эченә алган бай музей коллекциясе.

16 февральгә кадәр. һәр көнне 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Ял көне – дүшәмбе. «Эрмитаж-Казан» Үзәге, 3 кат
«Казан Кремле»музей-тыюлыгы

DEPECHE MODE ТРИБЬЮТ-ТАМАШАСЫ (12+)

Depeche Mode фанатлары урамында – чып-чын бәйрәм! Тере тавыш һәм танылган төркемнең барлык хитлары, моннан да зуррак ләззәт тагын кайда бар? Әлеге Яңа ел бүләген җанатарларга Depeche Boat дигән төркем әзерләгән. Меломаннар фикере буенча, әлеге DEPECHE MODE #1 трибьют-төркем Россиядә! Әлбәттә, трибьют-шоу оригиналны бар төсмерләре белән кабатлый алмый, шулай да фанатлар белән музыка сөючеләрне битараф калдырмас, дип ышанабыз. Җитмәсә, Рөстәм Абызов җитәкчелегендәге La Primavera Казан камера оркестры Depeche Mode хитларына өстәмә классик төсмерләр кертәчәк. Димәк, супер-хитлар тагын да яңачарак яңгыраячак, дигән сүз!*

7 февраль, 18:30 сәг.
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73 йорт

** ИГЪТИБАР! DEPECHE MODE (Дэйв Гаан, Мартин Гор) төркеме бу шоуда катнашмый! Билетлар алганда һәм чарага килгәндә, моны истә тотыгыз.*

ИТЕКЛЕ ФЕСТИВАЛЬ ХИКМӘТЛӘРЕ

Аркан тартумы? Итекләрдән! Хоккей? Итекләрдән! Футбол? Анысы да – бары тик итекләрдән генә! Ничек инде алай, диеп тә тормагыз! Чөнки бу – Бөтенроссия «Кукмара итекләре» фестивале! Монда берничек тә башкача була алмый!

Менә ичмасам эссе! 5 гыйнварда Кукмарадагы фестиваль мәйданчыкларындагы атмосфераны әнә шулай гына тасвирлап була. Кызык бит: көн болай үзе салкынча, әмма ул катнашучыларны кыздыра гына шикелле. Алар һәрберсе безгә ата-бабалардан нинди борынгы да, кабатланмас та мирас калганын үз мисалында исбатлап күрсәтә.

Иң эссе урыннарның берсе – футбол кыры. Биредә Кукмара белән Теләче районы командалары уйный... Дөресрәге, көч сынаша. Тизлек, киеренкелек, үҗәтлек рухы. Иң кызыгы шул: аякларда – итек. Менә шушы мизгелдә Роналду белән Мессины, аякларына итек кидереп, уен кырына чыгарып җибәрәсе иде! Нәрсә эшләргә белмичә, аптырап калачаклар, хаталар ясап, капитуляциягә риза булачаклар. Ә безнекеләрнең исе дә китми – уйныйлар! Әле ничек кенә, күз иярми! Әгәр футбол чемпионатларын итектән уздыра башласалар, күр дә тор, безнекеләр беренчелекне бирмәячәк! Хәер, монысы – хыял, билгеле... Ә ул арада фестиваль җиңүчеләре дә ачыклана. Сыбызгы финал тәмамлануын хәбәр итә. Нәтиҗәдә Кукмара районы командасы беренчелеккә чыга!

Мондый атмосфера спорт ярышларында гына түгел, башка мәйданчыкларда да сизелә. Менә, мәсәлән, Комсомол мәйданында жюри итек рәвешендә эшләнгән иң шәп дәү курчакны сайларга тырыша. Янәшәдә генә ярминкә гөрли. Халык һөнәрчелеге эшләнмәләре, кул эшләре тезелеп киткән – ни генә юк биредә! Шулай да иң зур кызыксынуны Кукмара даны булган итекләр уята: зурлары да бар монда, бәләкәйләре дә, төрле төскә манылганнары да, чигелгән-бизәлгәннәре дә, модалы күтәртмәләр белән ясалганнары да, классик вариантлары да. Үзләре гади дә, матур да, уңайлы да...

«Кукмара итекләре» Бөтенроссия халык иҗаты фестивале мәдәни инициативаларның Президент фонды ярдәме белән инде 10 нчы мәртәбә уздырыла. Быел Кукмарага, үзләренекеннән тыш, Татарстанның Әтнә, Балтач, Зәй, Минзәлә, Балык Бистәсе муниципаль районнарыннан командалар килгән. Һәм өч республика – Удмуртия, Башкортстан, Татарстаннан җыелма командалар да. Бу тамашаларны күрергә теләгән туристлар исә дистәләгән республика, төбәк һәм өлкәдән җыелган.

Гаҗәеп соклангыч фестиваль тамашасыннан кала, быелгы кунакларга үзенчәлекле пролог та күрсәтәләр. Ачылыр алдыннан, 4 гыйнварда, катнашучы командалар Кукмара итек заводына экскурсиягә баралар һәм итекнең ничек басылуын үз күзләре белән күреп кайталар. Чын мәгънәсендә халыкчан аяк киемен җитештерү бер дә гади, җиңел эш түгел икән. Ул җылы да булырга тиеш, уңайлы да, чыдам да. Кунаклар үзләре дә кечкенә сувенир итекләр ясап карыйлар.

Менә шулай уза биредә фестиваль. Аның төп максаты – Татарстанда яшәүче халыкларның традицияләрен, мәдәниятләрен саклау, үстерү, киләчәк буыннарга җиткерү.

Фото: ТР Мәдәният министрлыгы, РФ Президентының Мәдәни инициативалар фонды


ПРИ ПОДДЕРЖКЕ ПРЕЗИДЕНТСКОГО ФОНДА КУЛЬТУРНЫХ ИНИЦИАТИВ
ВСЕРОССИЙСКИЙ ФЕСТИВАЛЬ-ЯРМАРКА НАРОД
КУКМ
КИЕ ВАЛЕНКИ

ТЮЛЯЗИ

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан»журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+